

# Равиль Файзуллин

## Избранные произведения

В шести томах

Том 1

*Стихи*

КАЗАНЬ • ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • 2005



# Равил Фәйзуллин

## Сайланма әсәрләр

Алты томда

1 том

*Шигырьләр*

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2005

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ф91

**Редколлегия:**

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин,
И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов,
Р.Х.Корбанов*

**Фәйзуллин Р.Г.**

Ф 91 Сайланма әсәрләр: 6 т./Равил Фәйзуллин; Кереш сүз авт. Ф.Г.Яруллин. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2005.

ISBN 5-298-04201-5

1 т.: Шигырьләр. — 2005. — 495 б.

ISBN 5-298-04211-2

ISBN 5-298-04211-2 (1 т.)
ISBN 5-298-04201-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Фәйзуллин Р.Г., 2005





# *Мөхәррирдән*

*Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин иҗаты — узган гасыр урталарында татар әдәбиятына яңалык алып килгән, үзенчәлекле, киң кырлы бай иҗат. Үзенең кыскалыкка һәм тирән фәлсәфи фикерләүгә нигезләнгән шигырьләре, поэмалары белән дә, чорның әдәби хәрәкәтен күз алдына китереп бастыра торган публицистик язмалары, мәкаләләре, әңгәмәләре белән дә Равил Фәйзуллин әдәбиятыбызда аерым бер урын тота. Яшьли әдәбиятка килеп, үткән гасырның 60 нчы елларында ук бөтенсоюз югарылыгында яңгыраш алган шагыйрьнең иҗаты бу томлыкларда чагыштырмача тулы чагылыш таба. Алты томлыкның беренче өчесендә шигырьләр, поэмалар, диалоглар, монологлар тупланган. Шагыйрь иҗатының аерым бер үзенчәлеген күрсәтүче кыска шигырьләр (бер-дүрт юллыклар) — 1 нче томда. Балалар өчен язылган шигырьләре 3 нче томга кергән. Томлыклар — Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллинның Равил Фәйзуллин шәхесе һәм иҗаты турында уйланулар рәвешендә язылган кереш сүз-мәкалә белән ачыла. Шигырьләр хронологик тәртиптә (1958—2005) урнаштырылган.*

*4—6 нчы томнарда авторның чәчмә әсәрләре — фәнни мәкаләләре, публицистик язмалары, эссе-уйланулары, нәсер-парчалары, әңгәмәләре, сәяхәтнамәләре... Шунысы игътибарга лаек — кырык елдан артык әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайнаган әдип буларак, бу язмаларда шагыйрь шәхесе тагын да тулырак ачылу белән бергә, әдәбиятыбызның соңгы чор тарихы да шактый ук объектив чагылыш таба. Әдәби хәрәкәттәге вакыйгалар, проблемалар белән бергә, бу томлыкларда XX гасырда яшәгән һәм әдәбият-сәнгать өлкәсендә эшләгән байтак шәхесләрнең тормышы, иҗаты турында күп мәгълүмат бирелә.*

*Әдәби портрет яки гомумкүзәтү рәвешендә язылган мәкаләләрнең саны йөздән артык. 6 нчы томда Равил Фәйзуллин иҗатын яхшы өйрәнгән Наис Гамбәрнең поэтик әсәрләрне анализлауга багышланган тәфсилле мәкаләсе, фәнни нигездә эшләнгән библиография һәм күпсанлы фоторәсемнәр томлыкларның иҗтимагый кыйммәтен тагын да арттыралар.*

*Җыеп кына әйткәндә, Равил Фәйзуллинның «Сайланма әсәрләр»е әдәбиятыбызның алтын хәзинәсенә мөһим бер өлеш булып өстәләчәк.*

# *Иясен тапкан бәхет*

Ярсу елганың агышын күзәткән кеше белә булыр: дулкыннар гел агымга каршы йөгерә. Җил көчәйгән саен, дулкыннар кабарына, ялларын җилфердәтеп ирекнә, чиксезлеккә омтылган тайлар көтүедәй, ярсый-ярсый агымга каршы чаба алуларына сөенеп, хәтта бераз горурланып ярларга сикерә, көчсезрәкләре «маңгаен ярып» сүнеп кала, көчлеләре, үҗәтләре тагы да ныграк гайрәтләнеп, елганың уртасына сикерә һәм күкрәге белән агымсу өстенә тирән буразна сызып алга ашкына.

Шагыйрь Равил Фәйзуллинны мин агымга каршы йөзеп баручы әнә шул ярсу дулкынга охшатам.

1960 нчы еллар башы. Сәясәт дилбегәсе корыч кулдан ычкынып, иҗатчылар өчен иркенрәк сулыш алырга мөмкинлек ачылган чор. Г. Ибраһимов, К. Тинчуриннар кебек титаннарны күреп белгән Х. Туфан, И. Сәлаховлар, Сталинның тынчу лагерьларыннан котылып, яңадан әдәбиятка кайткан заман. Сәясәт җилләре тагын кайсы якка исәр икән дип сагаеп калган «карт гвардия» әдипләр як-якларына каранып торган арада әдәбиятка бер төркем яшьләр килеп керде. Алар арасында Рәшит Әхмәтҗанов, Рөстәм Мингалимов, Фәнис Яруллин, Гәрәй Рәхим һәм Равил Фәйзуллиннар бар иде. Соңрак бу төркемгә Мөдәррис Әгъләмов белән Зөлфәт тә кушылды. Һәммәсенә уртак булган яшьлекне санамаганда, бу шагыйрьләр бер-берсенә һич тә охшамаганнар иде. Бу шагыйрьләрдә эчке потенциаль, үз көчләренә, мөмкинчелекләренә ышану көчле иде. Өлкән буынның тәҗрибәсен, әдәбият үсешенә керткән өлешен кире какмыйча, үз тавышлары, үз моңнары, үз гамьнәре, үз стильләре белән шигъриятккә килгән яшьләр бер ритм, бер тирбәлеш, бер юнәлештә салмак кына агып яткан әдәби агымны төрле юнәлешләргә борып җибәрделәр. Яңа заман яңа фикер, яңа форма сорый иде. Шуңа күрә егерменче гасырның алтмышынчы еллар башында мәйданга килгән шагыйрьләр традицион шигырь кысаларына гына сыеша алмадылар. Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим һәм

башкалар «ирекле» шигырьдә үзләрен сынап карадылар. Ләкин аларның «ирекле» шигырьләре С. Рәмиев, Һ. Такташ, Ә. Давыдовларның шигырь алымнарыннан артык аерылып тормаганлыктан, укучыларда да, тәнкыйтьчеләрдә дә әллә ни шау-шу уятмады. Шуңа күрәме алар үз иҗатларын традицион ысулда дәвам иттерделәр. Күп гасырлар буена чарлана, төрләнә барган татар шигыре, вакытлар үткән саен, һәм стиль, һәм форма, һәм эчке структурасы ягыннан үзгәрә-үзгәрә камилләшкән. Татар шигыренең эчке мөмкинлекләре үскән саен, аерым стиль һәм формалар традиция төсен ала барган. Әмма халык авыз иҗатыннан ук килә торган дастаннарда, җырларда, табышмакларда, мәкаль һәм әйтемнәрдә ачылып җитмәгән резервлар байтак иде әле. Алдынгы карашлы каләм ияләре, бу очракта шагыйрьләр, шушы яшеренеп яткан резервлардан шактый оста файдаланып, татар шигыренә яңалыклар кертә килде. Совет чорындагы идеалогия социалистик реализм дигән кысага барлык язучыларны куып кертергә теләсә дә, кыю фикерле яшьләр бу кысаны киңәйтер өчен төрле юллар эзләделәр: берәүләр әйтергә теләгән фикерен тирәнгәрәк яшерде, икенчеләр, метафораларны катлауландырып, символларга күчте, өченчеләр «эзоп теле» белән җанында кайнаган уй-гамьнәрен укучыга җиткерергә тырышты. Күп кенә кыю фикерләр текст арасындагы «юлларга» яшерелде.

Равил Фәйзуллин XX гасырның илленче еллар ахырында яза башласа да, зур әдәбиятка алтмышынчы еллар башында килде. Әдәби этикеттагы сүз булмаса да әйтим: әдәбиятка ул «сөзешә-сөзешә» килде. Әйе, «сөзеште», ләкин ул чит ояда үскән күке баласы кебек, оядаш кош балаларын этеп төшереп түгел, киресенчә, ояда барыбызга да урын җитәрлек дип, үз көченә, үз иманына, үз талантына таянып үсте, канат нығытты һәм, канатлары ныгыган саен, офыкларының киңәя баруын тойды.

Дөрес, иҗатының башлангыч чорында Равил Фәйзуллин, «тәртәгә артык тибенмичә», традицион кысаларда эзләнүләр алып барды. «Миңа унсигез яшь» дигән шигыреннән берничә юл:

Миңа унсигез яшь!
Мин — давылга тиңдәш.
Беләгемдә — көчем.
Күңелемдә дөрли,
Зур эшләргә өнди
тыелгысыз хисем.

«Кайту», «Иртә», «Авылда кышкы төн», «Яланда каен» һ. б. күп кенә шигырьләре традицион кысаларда иҗат ителсә дә, шагыйрьнең фикерләү рәвешендә ниндидер борылыш барлыкка килгәне сизелә.

Әти белән икәү, имеш,
атынабыз таганда.
Гаҗәп: әти гел түбәндә,
ә мин — өстә һаман да...
Уяндым сабый чак—төштән,
унсигез язым үткән.
Тагандагы урыннарны
алышыр вакыт җиткән.

Шагыйрь монда төш кенә булган балачакның үтүен, үзенең җитлегүен, таганны аска басып төшерерлек «авыраюын» белдерә. Сүз физик үсеш турында бармый, әлбәттә. Шагыйрь үзенең өлгерүен, зурлыгын, җитлеккән фикерләр, күңеленә тупланган рухи байлыкның арта баруы исәбенә үсүен сизә.

Әгәр Равил Фәйзуллин үзеннән элгәрләр юлыннан гына барса да, зур уңышларга ирешә алган булыр иде. Ләкин табигатенә, холкына яңалыкка омтылу хас булган шагыйрь эзләнмичә кала алмый. «Кыскалыкта—осталык» дигән гыйбарәне истә тотып, берьюллык, ике, өч, дүртьюллык шигырьләр яза башлый. Ике шигыренә күз салыйк:

Яшь чак
Кесә тулы елан мөгезе!

* * *

Яз! Җан тулы хушаваз.

Берәр юллык шигырьләр. Беренче карашка ниндидер табышмак яки хикмәтле сүз кебек. Ләкин аларда шигырь өчен иң кирәкле нәрсә—образ бар. «Кесә тулы елан мөгезе!». Мондый юлларны телнең нечкәлекләрен, халык авыз иҗатын яхшы үзләштермәгән кеше яза алмый. Ә бит елан мөгезе—бәхет, байлык символы. Шагыйрь шушы берьюллык шигырендә яшь чакның иң бай, иң бәхетле чак икәнен әйтеп биргән. Аңлап ук бетерә алмаслар дипме, шагыйрь төп фикерен-мәгънәсен исемгә биргән. Һәр сүз максималь эшләргә тиеш!

«Яз! Җан тулы хушаваз». Бу шигырьдә язның матурлыгы «хушаваз» сүзендә сурәтләнә. «Кайтаваз»га ияреп

ясалган «хушаваз» яздагы исләрне, төсләрне, тавышларны белдерүче неологизм. Бу сүз җилдә тибрәлеп, тирә-юньгә хуш ис таратучы матурдан матур чәчәкләрне күз алдына китерә, аларның хуш исе үпкәләргә тулгандай була; язда хуш исле чәчәкләр генә түгел, йөзләрчә кошлар тавышы, беренче күкрәү һәм тагын бик күп авазлар-тавышлар бар. Язларга гына хас тавышлар, төсләр, исләр, хисләр симфониясе бер сүз белән әйтеп бирелгән. Берәү булса үзенең табышын бер юлга «әрәм» итмәс, ким дигәндә бу образдан 3—4 строфалы шигырь язар яки ясар иде.

Равилнең шактый шигырьләрендә катлауландырылган метафора, ягъни ассоциатив кабул итү яки нинди дә булса күренешне төсләр, тавышлар аша бирү бар. Бу синестезия алымын әлегә кадәр безнең әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләр тиешенчә үзләштерә алмадылар. Ә бит бу ысул шактый шагыйрьләрдә, шул исәптән бу юлларның авторында да бар. Бездә, күрәсең, әдәби тәнкыйть әдәбиятның үзеннән артта калып бара.

Яшь шагыйрьнең берьюллык шигырьләре үзе бер кыюлык булса, шул берьюллыкларга «хушаваз» кебек неологизмнар кертеп җибәрүе—икенче кыюлык. Һәрбер неологизмны укучы кабул итми. Ә бу «хушаваз»—«кайтаваз» кебек табигый, әмма «кайтаваз»га караганда күп сыйдырышлы. Чөнки аңардан яз тәме аңкый, ул шагыйрьнең эчке халәтеннән, күңел төбеннән бәреп чыккан.

1964 елны «Казан утлары» журналында Равил Фәйзуллинның «Нюанслар иле» дигән исем астында кыска шигырьләре басылып чыккач, шул чор әдәбиятының күренекле вәкилләре Хәсән Туфан, Нәби Дәүли, Нурихан Фәттах кебек шагыйрь һәм прозаикларыбыз, Хатип Госман, Флүн Мусин кебек галимнәребез аптырашта калды. Нурихан Фәттахның «Шигырьме, әллә башваткычмы?» (Тат. яшьләре. —1965. — 17 июнь), Х. Госманның «Ачыклык кертәсе бар» (Соц. Татарстан. —1965. —31 декабрь), Ф. Мусинның «Аларга тугрылыклымы без?» (Соц. Татарстан. —1965. —26 сентябрь) Н. Дәүлинең «Поэзиянең ватаны—җир һәм тормыш» (Соц. Татарстан. —1966. —8 май) һ. б. мәкалә-рецензияләре шул хакта сөйли.

Атаклы шагыйребез, күп кенә яшьләрнең кумирына әверелгән Хәсән Туфан «Нюанслар иле»ндәге шигырьләр турында» дигән мәкалә-рецензиясендә мондый фикерләр әйтте: «Барыннан да битәр «Нюанслар»ның типик эчтәлеге,

«фәлсәфә»се гаҗәпләндерә. Иске дөнья белән яңа дөнья арасында, идеология мәйданнарында канга – кан, җанга – җан диярлек кискен көрәш барган заманда, давыллардан-өермәләрдән бер читтә, ерак тылның кырыйдагы тын, аулак бүлмәсендә калейдоскоптагы кызык күренешләрне күзәтеп утыруны чамалап, дөньяны шаккаттырачак яңалыклар эзләп ятуны чагылдыра әлеге шигырьләрдәге фәлсәфә...»

Шул рецензиядән тагын бер өзек:

«Нюанслар иле»ндәге шигырьләрнең җитмеш бишләбен бу циклга ялгыш кына кергән дип әйтергә мөмкин: ул әсәрләргә «яңачалык» җене рәтләп кагыла алмаган, күрәсең. Алардан бүлмәдән чыгарга теләү, халык күңеле иленә килергә омтылу, илнең шатлыгы, кайгысы белән дулкынлана башлау күренешләре чагыла».

Монда олуг шагыйребез үз-үзенә каршы да төшә кебек. «Халык күңеле иленә килергә омтылу, илнең шатлыгы, кайгысы белән дулкынлана башлау күренешләре чагыла» дигән сүзләр яшь шагыйрьнең талантын күрү булып аңлашыла.

Хөрмәтле шагыйребез, Сталин лагерьларының тынчу һавасын иснәгән шагыйребез, әлбәттә, саф һавага сусап кайткан. Алтмышынчы елларда әдәбиятка килгән яшьләргә бераз сагаеп булса да, өмет белән карый. Равил Фәйзуллинга шикләнебрәк каравы, безнеңчә, Равилнең талантын танымаудан түгел, киресенчә, яшь кенә егетнең үз стиле, үзенчә генә әйтелгән образлары барлыгын; татар шигъриятенә күптән яңалык кирәклеген җаны-тәне белән тоюын, ләкин бу яңалык нәрсәдә: эчтәлектәме, формадамы, яңача әйтелгән фикерләрдәме икәнлеген үзе өчен ачыклап җиткермәгән бер вакытта Равил Фәйзуллин «Яңалык менә болай була ул!» дигән кебек, татар шигъри дөньясына чакыру ташлавы олуг шагыйребезнең, күрәсең, күңелен күпмедер «чеметкәндер». Хакыйкать күп вакыт ачы була, аны «йотып җибәрү» беркемгә дә җиңел түгел. Ләкин моны Равил Фәйзуллин иҗатына кизәнү дип кабул итәргә ярамый. Олуг шагыйрь зур талантлар эзли. «Талант»лы сүзен теләсә кайсы шигырь язучыга ашыгып такмаска, «чын талант – әдип яки шагыйрь буларак, халык күңеленең ышанычлы вәкиле» булып өлгергәч, ягъни Тукайлар, Такташлар, Җәлилләр биеклегенә күтәрелгәч кенә кулланырга ярый дигән фикер әйтә.

Таләпне шулай зурдан куюы белән Хәсән Туфан хаклы иде, әлбәттә. Шагыйрьдә талант күргәндә генә аңа шундый зур таләп куялар.

Хәсән Туфанның тәнкыйди мәкаләсенә үпкәләми Равил, чөнки олуг шагыйрьнең сүзләрендә күпмедер хаклык барлыгын аңлый. Х. Туфанга җитмеш яшь тулган көннәрдә «Тынгысыз җанлы олуг шагыйрь» дигән мәкалә яза: «Хәсән ага—нәфис интеллектуаль тоемга ия, шигъриятнең формаль һәм мәгънәви хасиятләрен бик яхшы белгән, аларны үзенчә беркадәр фәнни нигезләгән шагыйрь. Шигырь төзелеше турында аның махсус теоретик хезмәтләре дә бар. Аның фикерләре белән килешергә яки килешмәскә мөмкин. (Мин, шәхсән, аның 60 нчы еллардан башлап татар шигъриятендә үзен актив раслаган сөйләм шигыренә, уй-хис агышына карап төрлерәк, үзгәрәк һәм беркадәр ireклерәк форма алган шигырьләргә карашы белән килешеп бетә алмыйм.) Ләкин шунсы хак: Хәсән ага һәрчак халык хәзинәсе үрнәкләреннән чыгып хөкем йөртә, һәр сүзен әдәбиятыбыз тагын да бай булсын, Тукай, Җәлилләр калдырган мирасның яхшы формалары дәвам итсен, дип, чын күңелдән хуҗаларча кайгыртып әйтә. Минемчә, һәр чын шагыйрьдә Хәсән агадагы байтак күркәм сыйфатлар булырга тиеш». (Сайланма әсәрләр. — 4 том. — 34 — 35 б.).

Хәсән Туфанга карата Равил Фәйзуллинның ошбу сүзләре аның тәнкыйтьне дөрес аңлавын, олы йөрәкле булуын күрсәтә. Бер сөйләшеп утырганда, ул: «Мине тукмамадылар»,—дигән иде. Хәзер ике-өч кенә шигырь язган һәм инде үзен «бөекләр» рәтенә куйган «шагыйрьләргә» Равилгә төшкән тукмак җиле генә тиеп китсә дә, «үтерәләр, коткарыгыз!» дип кычкырыр иде. Равил Фәйзуллин тәнкыйтьне егетләрчә кабул итүе белән дә үсте.

Әдәби җәмәгатьчелектә шау-шу кубарган менә шушы «Нюанслар иле» белән Равил Фәйзуллин тәнкыйтьчеләрнең һәм каләмдәшләренең игътибарын җәлеп итте. Аның турында күп яза башладылар. Кемнәрдер аны аңлады, кемнәрдер аңламады; кемнәрдер хуплады, кемнәрдер кабул итә алмады. Ләкин шунысы хак: аны хупламаучылар да татар шигъриятенә үзенчәлекле, кыю фикерле, хәтта гасырлар буе калыпланган шигъри форманы «ватарга» батырчылыгы җиткән бунтарь йөрәкле шагыйрь килүен танырга мәҗбүр булды.

Һәр әдәбиятның башлангычы халык иҗатына барып тоташкан. Без һәммәбез, язучы-шагыйрь буларак, халык хикмәтеннән яралган. Равил Фәйзуллин моны бик яшьли аңлаган дип уйлыйм мин. Заманында тикмәгә генә халык иҗаты буенча аспирантура тәмамламагандыр.

Шушы юлларны язганда, Фатих Урманченың «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь» дигән китабы (Казан: «Школа» нәшр., 2002) кулыма килеп керде. Анда халык иҗатына кызыклы караш бар. «Поэзиянең барлык уңай сыйфатлары, барлык атрибутлары барыннан да элек халык иҗатында формалаша. Борынгы шәрык үрнәкләре — ташка күчерелгән мифологик хикәятләр, төрле изге йолалар һәм тантаналы вакыйгалар белән бәйләнгән ритуаль гимннар, мәкаль-әйтемнәр, дастани-эпик формулалар... Һәм, ниһаять, бихисап дини догалар. Шулай булгач, халык иҗаты белән турыдан-туры бәйләнеш чыннан да язма поэзиянең тәүге, иң борынгы һәм безнең көннәргә кадәр уңышлы дәвам итеп килгән бердәнбер һәм тотрыклы сыйфаты» (10 б.).

Равил Фәйзуллинның кыска шигырьләренең нигезендә, дөрестән дә, халык иҗаты, аерым әйткәндә, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, тапкыр яки кинаяле сүзләр ята. Берничә мисал:

*Р.Фәйзуллин:* «Акчаң булса — гөл сибәрләр йөзеңә,
акчаң бетсә — көл сибәрләр күзеңә».

*Фольклорда:* «Кем кулында иллелек,
аның сүзе иң элек».

*Р.Фәйзуллин:* «Вакыт кына мәңге тантанада».

*Фольклорда:* «Гомер бит ул каш белән күз арасында».

Мондый мисалларны шагыйрь иҗатыннан күп китерергә мөмкин.

Бу язмада Р. Фәйзуллинның кыска шигырьләренә киңрәк тукталуның сәбәбе шул: чөнки шагыйрь шул кыска шигырьләре белән татар әдәбияты мохитендә зур резонанс тудырды. Равил шигырьләрендә, кабырчык эчендәге энҗеләр кебек, фикер тирәнгәрәк яшерелгән, аны аңлар өчен башта кабырчыкны ачарга, аннары кабырчык эченә кергән комнар арасыннан энҗене эзләргә кирәк иде. Кайберәүләрнең кабырчыкны ачып утырасы килмәде, кайберәүләр ачып та, аннан энҗе түгел, ком гына таптылар. Нигәдер Равилнең иҗаты, фикерләү рәвеше, тормышның, яшәешнең бер мизгелен берничә шигъри юл белән белдерү осталыгының тамырлары халык иҗатына барып тоташуын күрергә теләмәделәр. Дөрес, һәр кабырчык эчендә энҗе генә ятмый иде. Ләкин яшь шагыйрьнең эзләнүләре максатчан, һәм ул үзенең татар шигъриятенә яңа

бер сулыш алып килүенә нык инанганлыктан, максатыннан чигенмәде.

Моңа кадәр татар шигъриятендә, нигездә, сюжетлы шигырьләр хакимлек итте, һәм алар баштан ахырга кадәр бер ритмга корылган була иде. Сюжет бар икән, димәк, аның экспозициясе, кульминацион ноктасы һәм чишелеше була. Кыскасы, шигырьдә ниндидер вакыйга ята иде. Равил менә шушы традицияләрне инкяр итте. Аның кыска шигырьләрендә табигатьнең, тормышның яки кешеләрнең ниндидер бер халәте иң кабарынкы  урыныннан тотып алынды.

Күпме халык күрә ат күзендә
үз язмышын, үз моңын. *(«Күз»)*

Бу шигырьне «киңәйтеп» ат күзенә сеңеп калган язмышларны, атларның сугышчылар белән утка керүен, гомер буе колхозны атлар тартып баруын; күтәрмәгә калган атларны сабанга җиккәндә иң каты бәгырьле ирләрнең дә күзләре яшьләнүе һәм тагын бик күп нәрсәләр турында сөйләп булыр иде. Ә Равил Фәйзуллин шушы ике юлны язып куйган да дәвамын укучыларның үз хөкеменә калдырган. Күп шигырьләрдә автор үз позициясен белдерми. Чөнки шигырьне укучы төрле: кемдер зур интеллектка ия. Андыйлар автор әйткән фикерне фәлсәфи яссылыкка күчереп, шигырьне үз күңелләрендә үстерәләр, тирәнәйтәләр. Ә кемнәрдер үзенең аяк астындагын гына күрә. Мондыйларга ат күзендәге язмыш, моң автор уйлап чыгарган нәрсә генә. Димәк, шагыйрь генә түгел, шигырь укучылар да талантлы булырга тиеш.

Менә тагын бер мисал:

Кыны тулы кан.
Тышында – чәчәк сурәте. *(«Тарих»)*

Биредә дә фикер тыгызландырылып, катлаулы метафора хәленә җиткереп бирелә. Шушы ике юлга яшәешнең олы мәгънәсе сыйган.  Әгәр бу шигырьне озынайтып, кынының канда, ә тышында ни өчен чәчәк сурәте икәнен шәрехли башласаң, шигырь шигырьлеген югалтыр иде.

Кыска шигырьләр турында үземчә шактый тәфсилләп язганнан соң, йомгаклабрак болай дип әйтер идем: татар поэзиясендә кыска шигырьләрнең төрле формалары теге яки бу дәрәҗәдә кайбер шагыйрьләрдә элегрәк тә бар иде, әмма алар, аз һәм эпизодик характерда булу сәбәпле, әлеге авторлар иҗатының төп юнәлешен һәм әчтәлеген билгели алмадылар.

Шагыйребез Равил Фәйзуллинга килсәк, ул иҗатының саллы гына өлешен кыска шигырьләргә багышлады. Фәкать кыска шигырьләрдән генә торган китаплар, җыентыклар чыгарды һәм алар төрле телләрдә басылдылар да. Равил Фәйзуллин татар поэзиясендә кыска шигырьләргә тулы гражданлык хокукы биреп, аны аерым жанр-форма дәрәҗәсенә күтәрде, үз мәктәбен булдырды. Игътибар итсәгез, хәзер күп шагыйрьләр, олысы-кечесе дигәндәй, кыска шигырьләргә еш мөрәҗәгать итәләр.

Равил Фәйзуллинның таланты яшьтән ачылды. 1963 елда Татарстан китап нәшрияты «Җырчы чишмә» дигән шигъри җыентык чыгарган иде. Анда 12 яшь шагыйрьнең, шул исәптән Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов һәм әлеге юллар авторының шигырьләре дә бар иде. Әйе, без олы әдәбият мәйданына Равил Фәйзуллиннар белән бергә килеп кердек. Һәркем үз юлыннан китте. Менә шушы җыентыктагы дүрт шагыйрь Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, ә шулардан икесе, ягъни Равил Фәйзуллин һәм Фәнис Яруллиннар, «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исемгә лаек булды. Димәк, бу күмәк җыентыкны төзүчеләр (Ж. Тәрҗеманов һәм К. Миңлебаевлар—урыннары җәннәттә булсын!) талантларны башлангыч чорында ук күргән. Шагыйрьне яшьтән күрү—шагыйрь өчен зур бәхет. Сибгат Хәким Равил Фәйзуллин турында: «Үз буыным шагыйрьләреннән башлап шушы көнгә хәтле күзәтеп киләм, безнең поэзиягә Равил Фәйзуллин кебек иртә керүчеләр аз… яшьтән, әзерлек белән килүчеләр аз. Иртә килде, вакытында килде, шау-шу белән килде». (С. Хәким. Халык язмышы, шагыйрь язмышы. —Казан, 1977. — 345 б.). Әйе, Равил Фәйзуллинның шигърияткә яшьтән килүе хак һәм бу турыда күп язылды. Ләкин С. Хәкимнең «иртә килде» дигән сүзе белән килешеп бетеп булмый. Шагыйрьлекне, образлы фикерләүне пәйгамбәрлеккә тиңләргә мөмкин. Мөхәммәт пәйгамбәргә 40 яшьтә Коръән сүрәләре иңдерелә башлый һәм бу 23 ел, ягъни пәйгамбәр үз миссиясен үтәгәнче дәвам итә. Шагыйрьләрнең яшьли (ләкин иртә түгел!) өлгерүе күп факторлардан тора. Нинди мохиттә үсүе, кемнәр белән аралашуы һ. б., һ. б. Җөмләдән М. Җәлилнең дә 13 яшьтән үк шактый өлгергән шигырьләр язуын истән чыгармаска кирәктер. Шулай ук Ш. Бабич, Н. Исәнбәтләрнең дә бик яшьтән һәм җитлеккән шигырьләр язуы билгеле. Кайвакыт без, кемнеңдер иҗатын бәяләгәндә, объективлыктан читләшәбез.

Мәсәлән, Гариф Ахунов «Яңарыш» дип аталган мәкаләсендә Равил Фәйзуллинның иҗаты турында болай дип яза: «Үзгәртеп кору еллары һәр иҗатчыны, шул исәптән Фәйзуллиннар буынын да, янә бер кат сынады. Байтак кына тезмәчеләрнең калын һәм юка китаплары, кайберләренең хәтта бөтен иҗаты, китап киштәләреннән убылып төшеп, билгесезлек упкынында югалган чорда, әлеге яңа буынның язганнары үзләре яулаган биеклектә кала алдылар». (Г. Ахунов. Яңарыш // Р. Фәйзуллин. Заман. Иҗат. Шәхес. —16 б.).

Равил Фәйзуллинның талантын һәм әдәбияттагы ролен һич киметмәстән, яңа буын һәм үзгәртеп корулар килү белән «кемнәрнеңдер калын яки юка китаплары, кайберләренең хәтта бөтен иҗаты китап киштәләреннән убылып төшүе»н күз алдына китерү кыен. Әлбәттә, искелек белән яңалык көрәше бара. Бу көрәш әдәбиятта гына түгел, тормышта да чагыла. Ләкин, без ничек кенә теләмик, искелекнең тамыры тирәндә була. Урмандагы агачларга күз салсак та, корыган агачларның давылларда да аумыйча үрә катып торуын күрербез. Чөнки аны тамырлары тота, ә тамырлар тиз генә череми. Хәтта әллә кайчан киселгән агач төпләрен кубарып алу да күп көч сорый.

Инде татар шигъриятендә шундый шау-шу кубарып, күкрәк киереп, үз юлыннан тайпылмыйча, максат итеп алган кыйбласына ашкынып баручы Равил Фәйзуллинның биографиясенә дә бераз гына кагылып үтик.

Равил Габдрахман улы Фәйзуллин 1943 елның 4 августында Татарстанның Балык Бистәсе районының Юлсубино (халык телендә—Балтач) авылында туа. Котлы Бөкәш урта мәктәбен тәмамлый. 1960 — 1965 еллар — Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый, армия хезмәтендә була, соңрак аспирантура тәмамлый.

Бер сөйләшеп утырганда, Равилдән: «Сезнең яктан язучылар, артистлар, гомумән, күренекле шәхесләр күп чыккан. Мәктәптә укыту көчле булдымы, табигатегез бик үзенчәлекleme? Нилектән икән бу?» —дип сораган идем. Ул: «Һәр як үзенчә матур инде ул. Мин туган якларны алай ук экзотик дип әйтмәс идем. Татарстанга хас гадәти җир-су... Ә укыту, китапка мәхәббәт тәрбияләү мәктәптә чыннан да көчле булды. Талантлы шәхесләрнең күп булуы, мөгаен, тарихи тамырлардан киләдер. Явыз Иван Казан ханлыгын басып алгач, җиңелүне кичерә алмаган байтак гаярь затлар, башкаладан чигенеп, безнең якларда оборона тоткан. Соңрак көчләп чукын-

дыруга каршы булган дин кардәшләре белән берләшеп, урыс гаскәрләре һәм миссионерлары белән гасырлар буе көрәш алып барган алар. Безнең авылдан 10—15 чакрым гына ераклыктагы борынгы Чаллы шәһәрчеге ныгытмалары күп тарихи вакыйгаларны искәртә... Җан хөрлеге, ирекккә омтылу буыннан буынга, каннан канга күчеп, шул гаярьлекнең, башбирмәслекнең күпмеседер безгә дә күчкән булуы ихтимал», — дигән иде.

Бу чынлап та шулайдыр. Һәрбер төбәк фикерләү үзенчәлеге, телнең, диннең, гореф-гадәтләрнең, йолаларның ничек саклануы белән бер-береннән күпмедер дәрәҗәдә аерылып тора.

Равилне бәхетле язмыш баласы дип санарга була. Сугыштан соңгы авырлыкларны күрсә дә, хәерчелек-фәкыйрьлек аңа кагылмаган. Әтиле-әниле тигез гаиләдә үскән. Әтиләре булган балаларда, аеруча малайларда, эчке бер горурлык ята. Ятим балалардагы кимсенү, тормышка рәнҗү кебек тойгылар ата-анасы тигез булган гаилә өчен ят нәрсә. Әти кеше гаилә башлыгы гына түгел, ул сине яклаучы, кайгыртучы, киләчәк юлыңны сайларга ярдәм итүче дә. Менә шушы горурлык Равил Фәйзуллинның кан тамырларында ага һәм шул хис аның шигырьләрен дә сугара. Урта мәктәпне тәмамлауга, Казан дәүләт университетына укырга керә. Инде мәктәптә укыганда шигырьләрен газеталарда бастырырга өлгергән егеткә яңа юллар ачыла. Һичшиксез, болар өстенә яшь шагыйрьнең тырышлыгы, эшчәнлеге дә аңа тиз үсәргә, яшьли мәйданга чыгарга мөмкинлек биргән. Университетта укыганда ук (Равил көндезге бүлектә укый) «Яшь ленинчы», «Ялкын», «Казан утлары» кебек мәртәбәле газета-журналларда эшләве, студент елларында ук китаплар чыгаруы, егетнең тырышлыгын гына түгел, максатчанлыгын да күрсәтүче дәлилләр.

Шагыйрьгә, иҗат офыкларын киңәйтер һәм шәхес булып өлгерер өчен, дөнья күрергә, кешеләр белән күбрәк аралашырга, уй-фикерләреңне башкалар фикере белән чагыштырып карарга, кыскасы, Җирне, Күкне вакыт һәм пространство дигән фәлсәфи категорияләр белән эш итә белергә мөмкинлекләр ачыла. Үзеңнең туган ягың никадәр матур, кешеләре ничек кенә акыллы булмасын, әгәр дөньяң шул мохит белән генә чикләнә икән, шагыйрь иҗаты масштаблы була алмас. Зур Дөнья белән танышу өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдаланырга тырыша Равил. 60—70 нче

елларда чит илләргә бик сирәкләр генә чыга ала иде. Бигрәк тә рәсми делегацияләр составында. «Тимер пәрдә» заманында ук Равил Европаның һәм Азиянең дистәләрчә илендә булырга өлгерде. Бу факт күп нәрсәне аңлата. Ул елларда мондый мөмкинлеккә Мәскәүнең аерым бер даирә язучылар гына ия иде.

Равил Фәйзуллинны бәхетле шагыйрь дип атыйм мин. Әдәбиятка үзе белән бер чорда килгән каләмдәшләреннән аермалы буларак, аңа өлкән әдипләр тиз игътибар иттеләр. Кемнәрдер «артыгын азма, егет!» дигән кебек бармак янасалар, икенчеләр, мәсәлән, С. Хәким, М. Әмир, Ф. Хөсни, М. Мәһдиев, А. Гыйлаҗевлар Равилнең иҗатын хупладылар, аңа ышаныч белдерделәр, үз буынының лидеры итеп таныдылар.

Әгәр дә бер шагыйрьнең иҗатына ике төрле караш була икән, бәхәс купмый кала алмый. Бәхәстә һәркем үз карашын яклый. Бәхәсләр, дискуссияләр тудыруга сәбәпче булган шагыйрь яки язучы тиз популярлаша. Чөнки күп кенә укучыларның үз күңелләрендә дә шагыйрьлек ята бит. Алар да теге яки бу стильнең тарафдарлары булып китә. Тик шунысын әйтергә кирәк: бәхәс буш урында туа алмый. «Һәр новаторлыкның күпмедер дәрәҗәдә кайбер традицияләрне инкяр итүе табигый хәл, шулай булмаганда әдәбият күгендә яшеннәр уйный алмый... Озынга сузылган кышлардан соң кеше җаны җилгә-давылга, күкрәүле-яшенле яңгырларга тансыклый. Равил Фәйзуллин, сизгер күңелле шагыйрь буларак, моны яхшы тоя. Һәм, һәр чын шагыйрьгә хас булганча, поэтик дөньяны кузгатырлык (кемнәрнедер сискәндереп, кемнәрнедер сокландырып) шигырьләр яза башлый. Бу очракта «яза» сүзе бик урынлы да түгелдер, бәлки. Равилнең кыска шигырьләре кыядан умырып алынган чуерташларны хәтерләтә. Аларны эшкәртеп бетерүне ул укучының үзенә калдыра. Шуңа күрәдер, ахрысы, аның шигырьләре төрлечә кабул ителә һәм төрлечә интерпретацияләнә.

Ничек кенә булмасын, шигъриятkә яңа талант килүен таныйлар. Укыган вакытта ук университетның әдәбият иҗат түгәрәгенә, бераздан «Татарстан яшьләре» газетасы каршындагы әдәби берләшмәгә җитәкчелек итүе, беренчедән, иҗади яшьләр белән турыдан-туры аралашырга ярдәм итсә, икенчедән, аның җәмәгать эшләренә тартылуы һәм илдә барган иҗтимагый-сәяси тормышның тирәнрәк катламнарына үтеп керәсе килүен күрсәтә. Бу очракта Г. Тукайның «Мин коеп

куйган шагыйрь генә түгел, общественный деятель дә» дигән сүзләре искә төшә.

Равил Фәйзуллинны, әле 25 яше дә тулмаган шагыйрьне, Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге җитәкчесе итеп сайлыйлар. Анда биш елга якын эшләп кайткач, Татарстан Язучылар союзының җаваплы секретаре (хәзергечә әйтсәк, берлекнең рәис урынбасары) вазифасын башкара. Җаваплы урыннарда эшләү, табигый, аның иҗатына йогынты ясамый калмый. Җитәкче буларак РСФСР, СССР язучыларының җыеннарында – съездларда, пленумнарда, төрле конференцияләрдә, әдәбият көннәрендә катнаша һәм чыгышлар ясый. Гадәттә съездларга язучыларның иң абруйлылары, исемнәре илгә, дөньяга таралган, заманы өчен әдәбиятның терәк баганалары булган әдип-шагыйрьләр җыела. Съезд мөнбәрләреннән сөйләнгән докладлардан төрле милләт һәм халыкларның әдәбияты нindирәк үсеш юлы үткәнлеге чалымлана…

Равил Фәйзуллинның яшьли олы шигърияткә килүе һәм күп кенә өлкән әдипләрнең игътибарына лаек булуы, аны зур тормыш юлына алып керергә, әдәбиятның зур казанында яшьли килеш кайнарга ярдәм итә. 1970 елда ул Россия язучыларының чираттагы съездында иң яшь делегат буларак катнаша һәм шунда ревизия комиссиясе әгъзасы итеп тә раслана. Соңрак берничә мәртәбә РСФСР һәм СССР Язучылар союзының җитәкче органнарына сайланды. Кайбер язучыларның җитәкче урыннарга сайлангач, иҗатлары икенче планга күчә башлый, урындык биегәйгән саен иҗат түбәнәя. Әмма, бәхетебездән, Равил Фәйзуллинга «бөеклек» чире йокмый (бәлки, бу чирнең кайбер микроблары канына үтеп кергәләгәндер…). Ни генә әйтмә, мактау, дан, хакимият кешене күпмедер дәрәҗәдә үзгәртми калмый. Ләкин Р. Фәйзуллин иҗатында «бөеклек» һәм боеклык сизелмәде. Күрәсең, яшь тән, яшь канда шөһрәткә иммунитет көчле булгандыр. Шагыйрь, мактау-сүгүләргә, ыгы-зыгыларга исе китмичә, җиң сызганып дигәндәй, эшли бирде, максатына ирешә барды. Ул 1970 елны Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды.

Равил Фәйзуллинның мондый шигъри юллары бар:

> Шагыйрь булсаң, дөнья өчен
> даның, януың кирәк.
> Януыңны халыкларның
> күмәк тануы кирәк.

Бик дөрес әйтелгән сүзләр. Ничек кенә эчкә яшерергә теләмик, без барыбыз да шигырьләребезнең күбрәк күңелләрне яулавын телибез. Нинди генә талантлы әсәр язма — ул синең куен дәфтәреңдә генә кала икән — аның кыйммәте булмаячак. Равил Фәйзуллин үзенең «януларын халыкларның күмәк тануы»на ирешә алды. Шагыйрь бер әңгәмәсендә: «Мин ул чорның бик күп язучылары белән аралаша идем. Шулардан күп нәрсәгә өйрәндем. ...Иң әүвәл, фикерләүгә. Микола Бажан, Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Эдуард Межелайтис, Василь Быков, Давыт Көгелтдинов, Мостай Кәримнәр үзләрен дә, халыкларын да күтәрәләр, үз әдәбиятларын дөнья әдәбияты белән бәйли беләләр иде. Безгә шул җитеп бетмәде». (Ышаныч зур, хыял көчле иде... Р. Юныс белән әңгәмә//Идел. — 2003. — 8 сан).

Чыннан да, шагыйрь атап киткән әдипләр үз халыкларын дөньяга таныта алдылар. Чыңгыз Айтматов, Василь Быков, Рәсүл Гамзатов әсәрләренең әле дә искергәне юк. Чөнки аларның әсәрләрендә Кеше язмышы беренче планга куелган иде. Ә бездә?..

Безнең Муса Җәлилебез дөнья аренасына чыккач, хөкемдар даирәләр татарга шул җиткәндер дип уйлаганнардыр, бәлки. Ул кимәлдән безнең Тукаебыз да бар бит әле. Ул да заманында дөньяның кайбер телләренә тәрҗемә ителде. Бу урында шул заманның әйтелмәгән, әмма гамәлдә булган бер принцибын әйтеп узу кирәктер: совет чорында һәр республикадан берәр язучы яки шагыйрьне генә рәсми рәвештә үстерделәр. Бу исемнәр СССРда милли әдәбиятларның чәчәк атуын күрсәтү өчен дәлил буларак кирәк иде. Бу рәткә керә алган язучыларга, әлбәттә, бөтен шартлар тудырылды. Әсәрләре язылып бетүгә диярлек, Мәскәүнең көчле тәрҗемәчеләре, аларны рус теленә тәрҗемә итеп миллион тиражлар белән бастырып, укучыларга җиткерә торды. Күпләр хәтерлидер, ул вакытта укучыларга кытлык юк иде. Китап киштәләрдә аунап ятмый. Табигый, әсәрләре укылгач, язучы тагын да популярлаша. Китаплары дәүләт казнасына саллы гына керем кертеп тора. Сайлап алынган, назлап үстерелгән язучыларга дан-дәрәҗә килә. Ленин премиясе, Социалистик Хезмәт Герое, Югары Советта депутатлыклар. Шундый исемнәргә ирешкәч язмый кара син! Сөләйман Стальскийлар, Җамбул Җабаевлар укый-яза белмәгән килеш тә зур дәрәҗәләргә ирештеләр. Үзләре яза алмаса, алар өчен башкалар язды. Хәтта нинди талантлы Рәсүл Гамзатов та әйтергә теләгән

шигъри фикерен тәрҗемәчеләргә подстрочник формасында гына язып җибәрә торган булган, диләр.

Төп-төгәле ничек булгандыр, хәзер әйтүе кыен. Шунсы хак: әле әйтелгән әдипләр һәркайсы талантлы язучылар, кабатланмас язучылар иде. Юкны, булмаганны, күпме генә теләсәң дә, бик үк югары күтәреп булмый. Моны гына яхшы аңлаганнар инде ул партия кешеләре! Сорау туа: ә ни өчен безнең татарлар арасыннан ясалма рәвештә булса да берәрсен үстермәделәр соң? Моның, күрәсең, без белми торган сәбәпләре булгандыр. Бәлки, татарлыгыбыз зыян китергәндер. Күп гасырлар элек буйсындырылган халык булсак та, татарда дәүләтчелек каны сакланган бит әле. Бәлки, үзебез «өлкән агаларга» яраклашырга тырышып, милләтебез гамен, халкыбызның борчу һәм уйларын бер яктарак калдырып, йөзәр мең тонна нефть кудырган «Дуслык» торбалары, КамАЗ машиналары, нефтехим комбинатлары, гомумән, гигант төзелешләр белән мавыгып, милләтебез язмышына кагылышлы проблемаларны җайлы һәм кискен итеп куя алмаганбыздыр.

Ә Равил Фәйзуллин?

Равил үз иманына тугры калып иҗат итте. Аның һәр ел саен әле Казанда, әле Мәскәүдә китаплары чыгып торды. Рус телендә дөнья күргән китаплары гына да дистәләгән. Гадәттә башка милләт язучыларының тәрҗемәдә чыккан китапларына рус тәнкыйтьчеләре игътибар итмәскә тырышалар. Бу яктан да Равил Фәйзуллин бәхетле булды. Аның китапларына В. Солоухин, О. Шестинский, Ф. Васильев, В. Туркин, Л. Щепахина, В. Дементьев, Р. Солнцев, А. Веян, А. Губарь һәм тагын үзебездә яшәүче Р. Мостафин, Р. Кутуй, Й. Нигъмәтуллина кебек зур язучылар һәм тәнкыйтьчеләр мәкаләләр, рецензияләр язып чыктылар. Һәрберсе үзенчә Равил Фәйзуллинның иҗат асылын ачарга тырышты. Шагыйрь О. Шестинский, мәсәлән, болай дип язды: «Чем привлекает меня поэзия Р. Файзуллина? Духовной силой, нравственным здоровьем. Его поэзия не замыкается в узком мирке сиюминутных переживаний – перед нею распахнут весь мир. Лирический герой Р. Файзуллина живет в мирное время, но автор рисует его как личность с героической душой...» (О. Шестинский. Убежденность поэта // Правда. – 1979. – 13 февр.).

В. Дементьев Р. Фәйзуллинның кыска шигырьләренә карата мондый фикер әйтә: «Краткость, на первый взгляд

кажущаяся легкой, требует от художника духовного напряжения, умения в 10-15 словах дать философское осмысление действительности. В малой форме, как солнце в капле, ярко проявляется индивидуальность поэтического мышления» (В. Дементьев. Путь к слову // Волга. —1981. —№ 3).

Күренә ки, Мәскәүдә күп кенә халыкларның, шул исәптән русларның да йөзләгән, меңләгән китаплары чыгып торганда, Р. Фәйзуллин китаплары эзсез югалмаган. Аларны бәяләгәннәр, татар шагыйренең үзенчәлекле якларын күргәннәр, аны фәлсәфи фикерле, дөньяны үзенчә күрә һәм күрсәтә белүче зур шагыйрь дип санаганнар. Үз вакытында Равил Фәйзуллин иҗаты турында рус, украин, латыш, башкорт, яһүд, удмурт, балкар, гарәп, эстон һ. б. халыкларның танылган әдипләре зур фикерләр әйткәннәр. Яхшы бит!

Табигый, шундый сорау туа: ни өчен соң Р. Фәйзуллинны Рәсүл Гамзатов, Давыт Көгелтдинов, Мостай Кәримнәр дәрәҗәсенә күтәрмәделәр? Ә бит аны үзебездә дә күрмәделәр түгел. 27 яшендә М. Җәлил, 34 яшендә Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, 1985 елда РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булу бездә башка бер генә шагыйрьгә дә эләкмәгән бәхет. Шулай икән, ни өчен соң ул Парнас тавының түбәсенә менеп җитеп тә, алда атап кителгән шагыйрьләр рәтендә санала алмады? Безнең карашка, моның сәбәпләре шактый тирән. Бары фаразларга гына кала. Әлеге дә баягы безнең Тукайларыбыз, Җәлилләребез дөнья киңлекләренә чыкканнар иде инде. Икенчедән, Хәсән Туфаннар, Сибгат Хәкимнәрнең поэзиядә ат уйнаткан чагы. Аларның да тәрҗемәдә әсәрләре басылып тора. Сибгат Хәким инде РСФСРның М. Горький исемендәге премиясенә дә лаек булды. Тагын бер омтылыш, рәсми Олимп тавына менеп җитәргә ерак калмаган иде. Бәлки, татарда талантларның артык күп булуы да комачаулагандыр. Лаеклылар күп, ә Олимп тавында һәр республикага бер генә урын. Ә бер урындыкка берничә кешене утыртмыйлар. Мисалга ерак барасы түгел: Башкортстанда Нажар Нәҗми Мостай Кәримнән һич тә ким язмады. Нажар Нәҗминең популярлыгы гына түгел, иҗат биеклеге дә Мостай Кәримнекеннән түбән түгел иде. Әмма ул рәсми Олимпта саналмады. Чөнки билгеләнгән югары тәхет инде биләнгән иде.

Алда әйтелгәнчә, совет чорында «Без барлык халыкларга да тигез карыйбыз, әдәбиятларын-мәдәниятләрен үстерәбез» дигән фикерне сеңдерер өчен алып барылды андый сәясәт.

Ә үзебезнең җитәкчеләребезнең дә: «Бездә шундый-шундый талантлар бар—аларга лаек бәя бирергә кирәк дип, Кремль алдында чаң кагып дәлилләргә батырчылыклары җитмәде.

Әмма рәсми рәвештә Олимп тавына менгереп түшенә биш чатлы алтын йолдыз такмасалар да, Равил Фәйзуллин халыкта барыбер әнә шул «йолдызлар» рәтендә йөрде, үзе дә алар белән үзен тигез куя алды, иҗат итте. Татарлыгы өчен кимсенмәде һәм башка милләтләргә дә кимсетеп карамады. Биш томлык сайланма әсәрләренең 5 нче томында (2001) Р. Фәйзуллинның мондый сүзләре бар: «Үзен татар дип йөрткән, үзендә милли үзаң бар дип исәпләгән һәркем бер нәрсәне онытмаска тиеш: дәүләтчелек идеясе теге яки бу формада иң әүвәл сүздә—гыйлем ияләренең, шагыйрьләрнең, әдипләрнең язма яки басма хезмәтләрендә сакланды. Байтак гасырлар буенча, дин, беренче чиратта, милләтне таркатмаска булышса, әдәбият иң мөкатдәс эшне—азатлык, бәйсезлек, мөстәкыйльлек идеясен, йә ачыктан-ачык, йә эзоп теле белән эчтән саклап үстерә килде» (19 б.).

Шигъриятендә «милләт» сүзен еш кулланмаса да, Р. Фәйзуллин чын милләтпәрвәр шагыйрь.

Вөҗданым белән сөйләшәм,
Шул минем шигъриятем,—

ди ул.

Шагыйрь иҗаты белән таныш кеше белә: шагыйрьнең вөҗданы милләт йөрәге белән тоташкан. Әле авызны бик чамалап ачарга туры килгән заманда ук: «Космополит түгел... Татарныкы диеп төртеп күрсәтмимен ал таңга»,—дип, шовинизм белән исереп, агачларга, ел фасылларына, аййолдызларга кадәр «үзенеке» итәргә теләүләр янында татарның олы җанлылыгын күрсәтеп язган иде. Кырым татарлары фаҗигасенә бәйле рәвештә язылган «Колонизатор әлифбасы» тагы да көчлерәк яңгырый. 70 нче елларда язылган бит бу әсәр! Торгынлыкның пик чорлары... Мисал өчен, «Гөмбәзләре—кояшмыни!», «Татарстан—Төтенстан», «Шайтан каласы»ннан КамАЗларга карап», «Елан тавыннан карадым», «Белая горячка», «Кафтау. Сугыш. Таулар егълый...» һ. б. Р. Фәйзуллин иҗатында ул вакыттагы сәясәткә карата ачык текст белән язылган мондый шигырьләрне байтак күрергә мөмкин. Ул үз фикерен шигырьләр аша белдерүдән тыш, Югары Совет (хәзергечә әйтсәк, Дәүләт Советы) депу-

таты буларак (1990—1995) югары трибуналардан да җиткерергә тырышты.

Әйе, шагыйрьнең тырышлыгы бушка китмәде: аны күрделәр, аңладылар, бәяләделәр. 1999 елда Татарстанның халык шагыйре дигән мактаулы исем бирелү халык таныган, үз иткән һәм биеклеккә күтәргән шагыйрьнең олылыгын рәсми рәвештә тану иде.

Равил Фәйзуллин зур шагыйрь булу өстенә үткен каләмле публицист, җәмәгать эшлеклесе дә. Бу урында «Мәйдан» журналында (2003 елның 10 нчы саны тулысынча шагыйрь иҗатына багышланган иде) Факил Сафин мәкаләсеннән берничә җөмлә китереп узасым килә. Аның фикере минем күңелемдәгегә бик туры килә: «Беренче нәүбәттә Равил Фәйзуллинны татар шигъриятен күп сүзлелектән, арзан тезмәләрдән «коткару» эшенә керешкән табиб ролендә күрәм. Ул рациональ романтизм шагыйре, татар шигъриятендә борынгыдан килгән образлы, кыска сөйләм традицияләрен уңышлы үстерүче әдип... Шагыйрьләр, ахыр чиктә, халык күңеленә берничә юл, берничә строфа белән булса да «кереп калырга» хыялланалар. Андый юл, строфалар Равил Фәйзуллинда йөзләрчә. Тукайдан кала кайсы шагыйрь андый бәхеткә тиенгән татарда?! ...Равил Фәйзуллинның шәхесе иҗаттан, иҗаты шәхес биеклегеннән аерылгысыз. Әдипнең тормыш һәм иҗат юлын күздән кичергәч, шагыйрь иңсәсе күтәрергә тиешле Тукайлык йөге—шагыйрьлек өстенә дипломат та, сәясәтче дә, җәмәгать эшлеклесе дә, егерменче йөз ахырында татар демократик матбугатын оештыручысы икәнлегенә дә инанасың». (Күк чикне беләмени! // Мәйдан — 2003 — 10 сан — 13 б.). Уйлансаң, чыннан да шулай бит. Матбага эшчәнлеген генә алыйк: ул 1989 елдан бирле халкыбызның иң яратып укыла торган журналы—«Казан утлары»ның баш мөхәррире. Аның мөхәррирлегендә 200 сан (2006 елда журналның 1000 нче саны чыгачак, гомум санның биштән бере дигән сүз) чыккан. Димәк, күпме әсәр укылган, күпме авторлар белән мөнәсәбәткә керергә, кемгәдер әсәренең йомшак икәнлеген аңлатырга, үпкәләш-бәхәсләргә керергә туры килгән. Тик ул зарланмый, эшеннән тәм табып, яратып эшли. Менә ничә ел инде ул Язучылар берлегенә Яңа әгъзалар кабул итү коллегиясе рәисе дә.

Күп йөргән, күп күргән, күп эшләгән Равил. Аның үзенчәлекле таланты турында йөзләрчә мәкалә һәм рецензияләр

тикмәгә генә язылмаган. 2002 елда шагыйрь Зиннур Мансуров төзеп «Мәгариф» нәшриятында чыгарган «Заман. Иҗат. Шәхес» дигән китап үзе бер докторлык диссертациясенә торырлык. Бу коллектив җыентыкта Р. Фәйзуллинның күпкырлы иҗаты төрле позициядән чыгып карала. Шуңа өстәп, Р. Фәйзуллин иҗатын тикшереп, төрле гыйльми хезмәтләр, монографияләр, диссертацияләр язылуын да әйтсәк, шагыйрьнең иҗаты дөрестән дә зур икәненә ышанырбыз.

Сүзебезне Р. Фәйзуллинның «Иясез шатлык» дигән шигыре белән тәмамлау урынлы булыр шикелле. Анда мондый юллар бар:

Мин дә куна алыр идем
кемгәдер аклык булып!
Җирдә күпме җаннар йөри
иясез шатлык булып!..

Әйтергә кирәк, Р. Фәйзуллин теләгенә иреште. Ул күпләрнең күңеленә аклык булып керде. Иясен эзләгән шатлык — бәхеткә сусаган җаннарны эзләп тапты. Шул җаннарны бәхетле итүе белән шагыйрь үзе дә зур бәхеткә — халык мәхәббәтенә иреште.

***Фәнис Яруллин,***
*Татарстанның халык шагыйре*
*2005*

# *Кыска шигырьләр*

*«Нюанслар Иле» —*
*юаныч багым!*

*...Кыска шигырьләр —*
*куаныч багым!*



# *Берьюллыклар*

**Бүләк**

Көнемнең таҗы — Син китергән Төн.

**Җыр яз!**

Яз! Җан тулы хушаваз! Яз!

**Аучы истәлеге**

Болан мөгезе — тармаклы хәтер.

* * *

Вакыт кына мәңге тантанада.

**Хәсрәтле чакта**

Күңелгә иш — ертык болытлар...

* * *

Безнең күзләр — Кояш көзгесе!

**Гаиләдә бер бала**

Бил каешын кочаклап яткан улым...

**Сөю елы**

Җыерчыклар язылды язында.

**Сөюсез ел**

Елады кан Елан елында.

* * *

Үл генә — күбәер дусларың...

* * *

Бәхетнең тәхете юк, имеш.

## Карак еллар

Күпме күз нурларын алып киттеләр!

* * *

Тынлык ул — иң бөек илаһи музыка.

## Яңгыр

Толымланып салынып төште Күк сагышы.

* * *

Җирдә ятмый, кайда ятсын яхшылык!..

**Балачак**

Җил бик тиз актарды әкият китабын.

* * *

Катакомбалар өстендә ал роза.

**Сукыр**

Күптән, бахыр, Күккә күмелгән...

**Кышын**

Алмаларда калган җәйге таң.

## Яшь чак

Кесә тулы елан мөгезе!

## Иделдәге шәфәкъ

Дулкын иңнәрендә кабынды учаклар...

## Кызыл китап

Яңа бите ачып куелган... Кем чираты?..

## Ирек яулаганда

Күзәнәкләремнең исеме — ренессанс.

* * *

Каберләрнең бар тик туган елы...

**Җәй**

Шәфәкъ белән Таң кочаклаша аҗаган булып.

**Кар яктысы**

Күзләр чагыла яшисе килүдән!

**Миңнәр**

Йөзеңә сибелгән — йолдызлар шәүләсе!..

**Без аерылгач**

Болытлар ак әләм күтәреп чыктылар.

* * *

Еллар юка чакта — уй биек.

**Язалганда**

Тергәлде көймәм Алтын ярга!

**Нәсел бүләге**

Аһ, аеклык! Ярты хәсрәтем...

**Дустым әйтте**

Ихласлыгым — күңелем сые.

**Яңа шәһәр**

Яшь зират өстендә карт карга.

* * *

Җан җанлана тән суынуга.

**Бер түрә**

Хурлык кебек зурлыкларда хозурлана.

**Нишләргә соң?**

Соңыннан бөтен кешегә соң...

# *Икеюллыклар*

## «Нинди юл яхшы?» дип сораучыга

Бер башында — дуслар озатканы,
бер башында — ярың көткәне.

## Очрашкач

Өметемнең күзе шундый зур!
Керфекләре генә ябылмасын!..

## Хурлык

Таудай эшләр төртеп уята.
Кәрлә эшләр эретеп йоклата...

* * *

Гомер шундый кыска!
Әллә ...яшәү рәхәт?

* * *

Кешенең иң зур иреге —
сөюе, сөелүе.

**Кыз**

Ай нурын да куштым чигешемә.
Чиккән яулыгым — сөйгән кешемә!

**Үз-үзеңне танып айну**

Күреп суда ямьсез, ватык бер йөз,
сискәнеп киттем.

**Тарих**

Кыны тулы кан.
Тышында чәчәк сурәте...

## Язгы кәеф

Беренче тере чебен!
Ничек кул күтәрәсең!..

## Үрмә гөл

Читән башына җителде.
Кош канатларына уралсаң иде!

## Хушлашыр алдыннан

Менә ишек ачылыр да хәзер —
мине суырып алыр салкын юл...

## Күз

Күпме халык күрә ат күзендә
үз язмышын, үз моңын...

## Карадым да текәлеп...

Җыерчыкларыңның болары — минем борчулардан...
Ә болары — үз бәхетең көннәреннән.

### Улы энисен күчәргә димләгәч

Сөякләрне чәчеп йөрмим инде!
Китсәм, атаң гүре рәнҗер...

### Кырымда

Зәңгәр күктә ап-ак болытлар!
Ватаным, дип баккан күзләрем...

### Перронда ишеттем

«Акчаң булса — гөл сибәрләр йөзеңә!
Акчаң бетсә — көл сибәрләр күзеңә...»

* * *

Гөрләвекнең гөре —
Күкне сагынып үксеп елавы...

### Кама. Боз киткәндә

Күккә кара!.. Бозда — безнең эзләр... Авыр...
Бозга ятып ага болытлар!..

## Кабыну

Кулыңда чуерташ кына.
Ә миндә инде дулкын!

## Диңгез кичәр кошның...

Бер канаты кабартма майлый,
икенчесе — тузан сыпыра...

## Учак

Үрсәләнә, бии ал яфраклар!
Тамырлары тибә җанымда!!

* * *

Тоннельдә бер үптең!
Поезд, һай, тиз үтте...

## Искәртү

Каршы төшсә дус дуска,
«Тел — озын, гомер — кыска!»

* * *

Батырлыгың — матурларның матурына!
Матур җырың — батырларның батырына.

**Яшьлекнең абага чәчәге**

Яктырткыч бөҗәкләр җыйдык та
чөйдек учлап төнге урманда!

* * *

Рәшәләнеп торган күңелдә
оча Хәтер күбәләге.

* * *

Ил мантырга теләмәсә,
халкыннан дошман эзләр.

**Тегермәндә**

Дөньяны яктыртып, агартып,
мөшкәдән җылымса он ага.

### Күпер киткәч...

Очып йөри арлы-бирле
ярдан ярга ак күбәләк.

### Урын

Штык булып этеп тора үткән еллар.
Борылып карап була, чигенү — юк...

### Авылда. Мич акшарлау

Күңелләр дә яктырсын өчен,
таш суы чыгарган яшь кызлар.

### Яңа елдан соң, көннәр озая башлагач...

Синең профиль аша тагын-тагын
язга карый башлады Кояш...

### Искә төшерү

Мисхордагы Ай күләгәсен
танып алдым күлмәгеңнән!

## Уразлыда бер көн тордым

Һәр өянкенең тамыры —
нәселегез бәгыре сурәте.

## Сары йорт

Йота бу төс, ирек куйсаң,
акны да, караны да...

* * *

Гел бер телдә язылган Тарих —
«әнисенең уңган кызы!..»

* * *

Аралашу — аң өчен.
Яралашу — җан өчен.

## Тугайда

Әй, маллар!
Көмеш койрык, укалы яллар!

## Ике чир

Сугыш та... рак.
Дөнья табалмый әмәлен...

## Завод янындагы паркта

Йөри кайгы агач башларыннан —
кеше башларына сикереп...

## Иске Кырымда

Сөрелгәннәрнең җирен сөрәләр.
Ә тургайга барыбер — өздерә!..

## Шаяру

Маңгайдан сыйпап сөя
эмансипация.

## Күперләр

Дусларның күрешкәндәге
кулларының күләгәсе.

## Кояш

Кара урман куелыгында
бер уч алтын кисәге.

## Чакты бал корты

Чәчәкләр бүләген китереп бал бирде.
«Дөньяда үч тә бар!»ны раслап җан бирде.

## «Карт-Аю»ның көндәлегеннән

Йокысызлык дигән каравылчы
саклап тора еллар көтүен.

## Тагын бер мәртәбә Сиңа

Картайсаң да, яшәрсәң дә
матур булуың ошый!

* * *

*Әйтте берәү:*
*«Үзем түгел микән?»*

Күземнән яшем кипмәде.
Кулымнан чүпрәк китмәде...

## Сайлауларда...

Дөньясын бөтереп тыгар идем
сызлаган теш арасына!

## Бер яшь каләмдәшкә

Минем хәлгә төшәр өчен
Сиңа менәргә әле!

## Шулай була минем еш кына

Офыкка төбәп мылтыктан аттым.
Аяк арамнан куян чыгып качты.

* * *

Уйнаш-көлеш, көлеш-уйнаш!..
Соңы була — җанны кыйнаш...

## Бу заманда

Хакыйкатьнең күзенә карап,
Күңелдән чәчрәп яшь чыга!

## Үземнеке!

Икәү фотога төшкәнсез...
Син — барыбер уртада!

* * *

Эшләмәгән кешенең
башы — шайтан конторы.

* * *

Бу дөньяда күпне күрдем.
Күрмәгәнне генә күрмәдем!

## Хәер бирмәгән айларда

Чәнчеп бозлы яңгыр явадыр күк
һаман-һаман әнием йөзенә...

## Ахыр заман

Дөнья шундый тар булыр,
ардан калган яр булыр.

## 90 нчы елларда

Җир күрке — бодай.
Ил күрке — Дудай.

## Рәхмәтсезләр Илендә

Ашый, эчә, укшып коса...
Һәм мылтыктан ата берочтан!

* * *

Ир-ат, егет — бөтенебез —
хатын-кыз ятиме без!

* * *

Җирең түгәрәк булганчы,
Илең түгәрәк булсын!

## Өлеш

Кешенекен урлагансың —
шуңа китек күмәчең...

## Гомер — челем…

Вакытымны тартып торам.
Газраил кабызып бирде…

## Болын

Яшькелт печән чүмәләсе.
Күләгәсе — сөт чүлмәге…

* * *

Тиреслеккә тимә — пары чыга.
Җанкаема тимә — ары чыга…

## Шулай язган

Минем кимчелекләр байтак…
Синең дә үләсе бар!..

* * *

Күк исеменнән кемдер кисә кебек
миңа тигән бәхет юрганын.

* * *

Булсаң икән адәм рәтле,
булганчы кодрәтле.

* * *

Сәрхүш илнең кайгысы юк —
халкының айныйсы юк.

## Нишлимме?

Мәңгелекнең бишмәтенә
төймә тагып утырам!

## Вафирә

Минем бөркет чагымдагы
Вакытым сандугачы!

## Деградация

*Оят качып бетмәгән бит әле...*

Әйтә иде элегрәк

Акчасы да, ояты да юк.
Хатыны да, аты да юк...

* * *

Кизәнгәнче уйла төптәнрәк! —
Мәхәббәт Нәфрәттән өлкәнрәк.

* * *

Бу сагыш нинди төстә соң?
Нигә баксаң—шул төстә.

**Гомер**

Күзләр ачылып килгәндә
ябар вакыты җитә.

**Бөек**

Ул баскан төштә чәчәкләр үсә.
Төкергән җирендә гөл шыта.

* * *

Көч чыкмый, көч кермәс.
Баемый кеше бөлмәс.

## Сабый улым йоклап ята

Күз туймас көләчем син!
Сөенеч күмәчем син!

## Максат

Халык хәтеренең почмагында
энә очы кадәр бер урын.

# *Өчьюллыклар*

## Көзге яңгыр

Торналар китеп бара.

Кош канатлары орынгач,
болытларның күңеле тулды.

## Натюрморт

Тәлинкәдә — Кояш.
Тастымалда — Икмәк.
Телем күзләренә нур тулган.

## Хәтер

Яз җитүгә,
беренче булып
таудагы кабер ачыла.

## Үҗәтлек

Кырмыска, саламны сөйрәп,
түмгәгенең очына менде.

Кояшка тәки якынайды!

## Көн уртасында үлгән солдат

Көнбагышка ябышып үлгән.

Ачык күзләрендә
икешәр Кояш…

## Иҗат

Скульптор өтергесен куйды.
Каршысында гүзәл яшь кыз.

Көнләшерлек бәхетле таш!

## Омтылыш

Йолдыз атылды.

Сабый бала форточкадан
кулын сузды!

## Дөнья!

Пәһлеван кабере өстендә
яфраклары калтыраулы
кәкре, зәгыйфь усак үскән.

## Онытылмый

Күңелемдә нәфрәтем чиксез иде.
Сыймаганы йодрыгымда йөрде.
Уч төбендә эзләр калды.

## Туган йорттан аерылгач

Тамчылы гөл — нәкъ әнием!

Элегрәк
танымый да идем гөлләрне.

* * *

«Мәңге онытмам!» — диде.

Оныкларының оныкларын
уйлап куйдым.

## Сәбәп

Аерылышалар.

Аяк бармагындагы
миңе ошамаган.

## С.Волжская-Гыйззәтуллина үлеменә

Нинди халык! Нинди холык!
Тукай язган аңа шигырь,
ә без — некролог...

## Сынау

Аз вакыт та безне тетте! —

Аҗаган булып килдең дә,
тычкан уты булып киттең...

## Ерак җирләрдә чакта

Мәрткә китеп үткәр идең бу айларны!

Уян идең
синең белән очрашыр көнне!

## Мөһаҗир

Бөртекләп җыйдым хәтердән
бәхетле көннәремне.

Ярты уч та тулмады.

## Улым

Ята сабый израп мендәрендә.
Зәңгәр күзле бөркет каурые!
Ничек итеп язар үз гомерен?..

## Авылда

«Биргәнеңә шөкер!» — диде агай.

Идәндәге икмәк валчыгын
иелеп алды.

## Көнләшүме?

Элеп куйган чалгы йөзенә
бер чыпчык кунган.

Кош җиңел шул!

## Җуясы килмәгән экият

Абагалар шау чәчәктә, имеш!

Ел да төнен барып карыйм, димен, —
һаман вакыт тими...

## Таулар илендә

Яралы кыялар...
Яшеннәр оясы...
Бөркетләр очыра баласын!

## Җирәнү

Табынырсың горур йөзенә!

Өстеннәр алдында
йөри тезендә...

## Кайту

Инеш яңа юл алган.

Иске эздә миңа таныш
бер таш калган...

## Юану

Күләгә. Кысан дип тормаган наратлар —
биеккә ничек шәп үскәннәр!
Бәлки...

## Син

Искә төшерүе дә бер ләззәт!

Гомер китабымның
гел ачасы килгән бер бите.

* * *

Нинди генә түшәмнәр күрмәдем,
иртәләрен йокыдан уянгач!

Йолдызларны капламады ниләр генә!..

* * *

Төркем-төркем кошлар күктә!

Шуларның берәрсе
минем телдә сөйләшәләр күк...

## Күңелдә йөргән бер автограф

*Т-гә*

Балачактан саклап килгән
зәңгәрлегенә күңелнең
килеп кунган нәфис ак болыт.

## Әй гомер!..

Нинди генә яңгырлар,
яшь белән кушылып,
акмады бит буйлап!..

* * *

Юк ла ул әбиләр чуагы!

Камыллы кырларны тутырган
безнең өзек сөю җепләре...

## Үтеп баручы таныш түгел бер ханымга

Рәхмәт, Сиңа! Мә кулдагы бу чәчәкне!
Бүтән әйберем юк бүләккә...
Бик кадерле бер кешемне искә төшердең.

## Төштәге хыял

Җыелган да ирләр Кояш астына,
төрле телдә сөю җыры җырлый-җырлый
бомба сүтәләр!

## Яңару

Әниемә килеп егылгандай,
Балачакка кайтып сыенам.

Йөрәгемә шифа кан сава.

* * *

Мин күргән иң чын матурлык —
хатын-кыз бәхетле булганда
йөзенең тулышып балкуы!

## Этюд

Су төбендә көмеш тәңкә
камыш аша якты сузган
Ай йөзенә.

## Балалар

Хыял агачлары корымаган,
өмет куаклары киселмәгән,
ышаныч бөреләре кипмәгән...

## Көткәндә

Әй, быел кыш озын булды!

Тәрәз арасына куйган
мамыкны да эретер идем!

## Кыр

Камыл табанымнан
Йөрәгемә кадәр чәнчеде.

Әй, син, икмәк!

## Горурлык

Таз эчендә орчык малай.

Пар эчендә — ата елмаюы:
«Арка ышкырга кешем бар!»

## Идиллия

Балык чистарткanda
маңгаеңа тәңкә кунды.

О, болай син нинди матур!

## Соңгы ләгънәт

Табуты шулай куелган:
аяк табаннары
Кояшка тиеп тора.

## Тулай торакта

Кызлар күптән йоклый.

Кефир шешәсендә гөлләр
таңны көтә.

## Әсир

Тын бүлмәдә, шәп вазада җикән камыш.

Ханым күлмәк салгандагы җил
ул бик аз шул...

## Йорт нигезенә субай сугалар

Ни әйтәсең башкага! —
җирдә нигез-тамыр кирәк
хәтта җансыз ташка да...

## Күз

*М-кә*

Учак урыннары... күлләвек.

Төннәрен анда йолдызлар яна,
җилләр искән саен, дерелдәп.

## Ә иң чыны...

Кочаклап ятам. Сөйләшәбез...

Ә иң чыны —
яшь чагыңны күргән төшем!

* * *

Күңелеңнең
изгелек китапларын һәммәсен укыдым.

Явызлык тулганнарына көчем юк...

## Рухи сукыр

Гомер буе кирәклене күрмәмешкә салышты ул.
Үлгәч, күзе туры карап шар ачылды.

...Бакыр акча белән яптылар.

## Бер генә аз...

Бер йолдыз аз — күк гөмбәзен җанлар өчен.
Бер гомер аз — син гүзәлне данлар өчен.
Бер тел аз — шул чын тарихны аңлар өчен.

## Кышкы бакчада

Көянтә-кар — ботакларда,
каян килгән кызыл алма?

Бәс эчендә кызылтүш икән!

## Ләйсән явып үткәч. Урманда

Бөреләрдә челтәр калфаклар!

Зәңгәр күктән... агачлардан
керфекләргә коела энҗе бәс...

## Урын

Түрдәме, йә ишек катындамы, —
урыным минем
вөҗданы булганнар янында.

## Теннис кортында

Мин — аҗаган уртасында!

Синең яктан килгән һәрбер ак шар —
күңелеңнән килгән йолдыз күк!

## Яшьлек

Алда, артта, ян-янда,
аста-өстә — һәркайда
Теләк ярлары.

## Һаман тора...

Инде апрель!

Елка булып чыршы кәүсәсендә
кисәк мамык һаман тора...

## Төнен Симеизда

Ай-Суфия* манарасымы!

Кипарис икән ич!
Очында яңа ай...

## Ялгыз чакта

Төнен учак яктым сәхрәдә...

Күктә ярый бер сүрән йолдыз
мине аңлап җемелди әле!

* * *

Йолдыз яңгырына кулыңны куй!

Учың тулмас (үпкәләмә дөньяга!),
бер-икесе төшсә — риза бул!..

## Күзге кыр

Камылларда каурый мамыклар.

Нәни-нәни ак әләмнәр җилдә
тибрәнәләр, кышны сиземләп.

* Ай-Суфия — Истанбулдагы мәшһүр мәчет.

* * *

Җан очты күк бушлыгына.

Кабыгы калды Җирдә
кабер-түмгәк булып.

* * *

Кыя ауган. Җәя сынган.
Канлы җәйран — үләндә...

Үз-үзен «җиңә» бәндә!

**Сугыш соңы еллары бу...**

Букча аскан теләнче карт,
көртләр ерып,
Айга карап юл саба...

* * *

Күзләре — диңгез! Чәчләре — кылган!
Курай эчендә — нечкә елан!
Түз, Шагыйрь! Елмай...

## Автошарж

Атланган агач атка!
Үз-үзенә даһи да ул,
үз-үзенә меценат та!

## Сабантуйда яки үч

Әтисе егылган җиргә
орчык малай, йөгереп чыгып,
«черт» төкерде!..

## Гел туудан торган дөнья...

Мәхәббәтне күмгәнсең икән —
Нәфрәт дигән түмгәк булса да,
туа барыбер.

## Уйлап чыгармадым, ишеттем...

Үлдеңмени?
Котлыйм!
Исән бул!

* * *

*Берәүгә*

Буралар бурамабыз...

Мич-морҗасы булмаса да,
төтенли урамавыз!

## Бәлки...

Гөнаһ тулы дөньяда
бер гөнаһсыз
яшәү үзе, бәлки, гөнаһтыр?..

## Хыянәт

Төенләнә-төенләнә
ап-ак таңда
кара кан косты.

* * *

Еллар арта. Үзем чүгәм...

Янәшәмдә һаман биекләнә
Үкенечләр манарасы.

# *Дуртьюллыклар*

## Берлек

Йолдызлар, күктән сикереп,
диңгез төбенә чумган.
Ә болытлар — дәрьяларның
күләгәләре сыман.

## Кайтаваз

Кыш буена яуган ак карларның
ташыйсылары бар быел яз.
...Нык рәнҗеттең мине үткән елда,
шуңа хәзер сиңа сүзем аз.

## Бер генә!

Туган җирең чүл булса да,
күңелдә ул гөл генә!
Ватан катлы-катлы булмый,
Ватан була бер генә!

## Дөнья куып...

«Бәхеткә!» дип чапты янып,
тормыш-ат ялында.
Бер бакса: бәхет-үр үтелгән,
упкын-яр — алдында...

* * *

Шомлы үкереп очты күктә
корыч очкыч.
Ә артыннан — ук-карлыгач.

...Поэзия искә төште.

## Искәртү

Дуслык җырым бүлеп, чукынма!
Тарихи ярамда тукынма!
Каһәр ташы булып татарның
бугазыңа кереп ятармын!

## Метаморфоза

Нинди шома! — мылтык сабын
ясаганнар өрәңгедән.
Шау яфраклы агач чагында
кыз яңагын куйган иде аңа.

## Һәркем атлый

Ялгызлыктан килеп — ялгызлыкка...
Туа кеше, яши, таркала.
Һәркем атлый үз ялгызлыгына
Гомер дигән күпер аркылы.

## Парсыз таҗ чәчәге

Сирень чәчәге таҗының
таптың да бишлесен,
капылт әйттең: «Мин юк чакта
ялгызың нишлисең?»

## Кайчак килә...

Кайчак җир сөрүче буласы килә.
Кайчак галәм белән юанасы —
йолдызчы галим булып. Кайчак килә —
гомер ярың булып уянасы...

## Көз башы

Җәй — яшел кош.
Очты китте!

...Күләгәсе булып канатының,
калды җирдә көмеш кырау.

* * *

Гомерем минем — авып барган шәм.
Ялкынлана ике башы да!..

Кемдер әзер, өстәп, уртасына
кызган тимер белән басарга...

## Беркөнне

Уйнашханә ясап, зиратлар өстендә
сикерәсең, төкерәсең, кикерәсең!..

...Әрвахлар рәнҗеше нәселеңнең күзендә
беркөнне сызлавык булып күпермәсен!..

* * *

Туа кеше —
Күккә эләр мәшәкатьләр.

Үлә кеше —
Җиргә күмәр мәшәкатьләр.

## 26 апрель, 1978

Без дә бер көн (бер көн!) — көн батыры булдык.
Төн батыры булды бүтәннәр!

...Җан ярасы инде төзәлә алмастыр, —
хет саулык бир, Ходай, бу тәнгә!

* * *

Арысландай басып үләндә йөр!
Һәм лачындай оча ал, җилпенеп!
Нужаларны күтәр сулар кебек!
Хәсрәтләрне йота ал, җир кебек!

* * *

Әйтәләр: котыплар җылына,
ихтимал туфаннар кузгалу!
Ә чыны — отыры гел арта
кешеләр күңелендә бозлану...

* * *

Кызыкмыймын биек түрәлеккә.
Исем китми алтын көшелгә.
Гомерем буе табынып килдем
Саулык белән Яхшы исемгә.

**Каян чыга бу сугышлар?**

«Аек бул»мы? Бар да аек түгел, җаный!
«Юләр бул»мы? Бар да юләр түгел, җаный!

...Айный да тилерә, тилерә дә айный!
Кешелек үз хәлен юньләп аңлый алмый...

**Чынлык**

Чия чәчәкләре пышылдашты иртән:
«Түшәлергә иде зәңгәр күккә!»

...Төне буе кара туфракка
яуды нәни-нәни ак йолдызлар...

## Маяк

Бер мизгелгә кабынып алды.
Күзләргә очкын алырга,
җанга ышаныч салырга
ул да җитә!

## Кипкән инеш

Ком да җил. Су түгел... Кая
чылтырап аккан чакларың?
Кая багыйм? Алда — яр да
үги ана яфраклары...

## Кредо

Шул зур кеше — кем үзенә
Һәм Вакытына үзе Алла.

Шул бәхетле — кем ирегән
Һәрнәрсәдә тоя ала.

## Әгәр җиңсәң...

Елан — яман! Күрсәтмәсен!..
Үлемгә иш агу!
Хикмәт: җиңсәң, дошманыңның
агуы да дару.

## Гел арта...

Дәрман кирәк еллар алда.
Ә алтын чак — артта!
Күзәнәкләр үлә бара.
Ә бурычлар арта...

## Бер банкетта

Бар сөйләнгән «кызыл» тостлардан
мәгънәлерәк иде ал шәраб.
Тагын истә калган бер сылуның
күзләрендә күргән ишарә...

## Аңладым да…

Акыл белән чаманы гел аңладым.
Тик шуны Хисемә аңлата алмадым.
Чеби чакта филне екмак булып йөрдем.
Арыслан чагым җиткәч, чебен ауладым.

## Нишлим?

Нишлим? Күңелең — тар,
җаның вак булгач…
Гәүдәң — шәп! — дия алам,
ансы хак булгач.

## Булыр иде…

Һәркайда, һәрнәрсә
асылынча аталса —
Хаклыкка һәркемнең ачкычы
булыр иде ләса!

## Сау кешегә...

Галәм бар — омтылырга.
Шәраб бар — онтылырга...
Омтылу да, онтылу да
җыр тудыра.

## Җиңел димә

Шатлыкны бик җиңел димә.
Кайгыны бик авыр алма.
Һәр икәве — олы сынау
кешелеге булган җанга.

## Бер җавапка дүрт сорау

Очкан килеш калырмы кош күк йөзендә?
Гел торырмы буй җиткән кыз ата нигезендә?
Менә алырмы һәр теләгән — шәп ияргә?
Бер гомер җитәрме сине сөяргә?

## Эфемерида

Шундый кыска булды әкият!
Серле рәшә эреп таралгач,
моржа кебек утырып калды
тотып карап булыр чынбарлык...

## Шик

«Кичәге инде — үткән, киткән...
бәхет алгы көндә икән!»

Вакыт җиткәч, ул көнгә дә
шулай селтәнмәссең микән?

## Мин ашыкмыйм

Рәнҗеттең син бүген, бик рәнҗеттең...
Тик ашыкмыйм хөкем итәргә.
Яхшы чакларыңны уйлар өчен
гомер бар бит әле иртәгә.

## Ялгыз карчык

Әле дә ярый бетмәс эшләрем бар!
Әле дә ярый юрар төшләрем бар!
Эшләремдә — кайтмас елларым,
Төшләремдә — кайтмас улларым...

## Нәсыйхәт

Биш җәүһәрең булса,
башта берсен күрсәт.

Бар бишесен берьюлы ачсаң —
ышанмаслар...

## Гаҗәп

Күңелең синең тар,
энә күзе икән...

Гаҗәп: шуннан күпме
мәкер-хөсет үткән!

## Барыбер үзгә...

Сәердер, бәлки, чарыктан
кире чәчрәгән тамчы.

Агымдагы мең тамчыдан
Ул — барыбер үзгә тамчы!

## Миңа никтер...

Бар да китә, бар да үтә икән!
Хәер, кемгә тансык бу сүз-үгет!

...Ярына ашыккан һәр егет хәзер
миңа, никтер, әкрен атлый кебек.

## Имеш, күктә фәрештә...

Юк ул күктә фәрештә!
Безнең хыяллар анда —
Җирдә ашмаганы эшкә
ашкандыр шулай өскә...

## Җиңел түгел

Нахактанмы, пычактанмы —
җиңел түгел яра.

Гөлнең дә, багананың да
күләгәсе кара.

## Кызыл гөл итеп

Барханнарда йөрдем — көймәдем.
Өшемәдем бозлар иләндә.
Чөнки сине, кызыл гөл итеп,
үзем белән йөрттем күңелдә.

## Әүвәл дә булганнар...

Бөекләр булган. Җуйганбыз.
Гасырлар — ерак ара.
Кайта-кайта: «Тукай!» — дибез, —
ул шул яңарак яра...

## Бу заманда

Шагыйрь булсаң, дөнья өчен
даның, януың кирәк.
Януыңны халыкларның
күмәк тануы кирәк.

## Ә шулай да...

Җире уртак, дибез, эше, таңы...

Ә шулай да
һәр кавемнең
аерым-аерым каберстаны.

## Ил өчен

Инешләрнең башы чишмә булыр.
Яхшылыкның асылы — тугрылык.
Яшәү — бәхет: илең — синең өчен,
син ил өчен булсаң горурлык.

## Бәхетле булсаң...

Кошлар китә. Саулык, байлык китә.
Карлар китә. Ярлар... Бар да китә.

Бәхетле булырга —
язганы җитә.

## Яшәп кара...

Яшәп кара бер маяксыз!
Йөз җыерып Хаклыктан!
Фикерең илтсәң сатлыкка —
кол булырсың ваклыкка.

## Төш кенә...

Зур кануннар, сөйгән ярлар, уенчыклар,
режиссерлар — бар да искерә...

Торган саен матурая бара
балачакта күргән төш кенә.

## Михайловскоеда

Йолдыз, Кояшларны күрми торып,
ничек белмәк кирәк бу Айны!

Мин, Пушкинның торган җирен күреп,
бөеклеген тойдым Тукайның.

## Ирдәүкә

Каты, кырыс бу, дим, кайчак сине,
хисләрендә эри белми!

...Йомшак булсаң, син ялгыздан дөнья
нәрсә ясар иде, белмим...

## Эзләр

Дулкыннарның эзе бармы?
Дулкыннар эзе — комда.

Еллар эзе кайда димсең?
Алары — маңгаемда...

## Кабатланмый!

Кылдың исә, — инде үкенмә, —
мәхәббәттә, эшләрдә.
Бу дөньяда, гомер түгел,
кабатланмый төшләр дә.

## Йокы алмаган төннәрдә

Ак Кремль диварына
ант итеп язган сүзләргә —
без уйган исемнәргә
яңгыр гел бәреп ява күк...

## Төнге Иделдә син йөзгәндә

Кара суда
яңа ак дулкын!

Көнләштереп мине
маяклармы ешрак җемелди?

## Бер сыныйм...

Йә, бер бизән, ясан, ки затлысын!
Күрсеннәр синең гүзәллекне!
Сыныйм: шул матурлыкны йөртергә
син ныкмы, түзәрлекме?

## Рәхмәт!

«Иң матур кыз! Иң сөйкемле!»
Нинди матур ялган!
Ул ялганга рәхмәт. Мине
бәхетле итә алган.

## Кыенрак...

Кыен бәхет кошын тоту,
оя кору.
Кыенрак — тоткач, коргач,
саклап тору.

## Сиңа

Син Алмазга кара, күзләренә,
мине сагынганда.
Күңлең керсез булса, күралырсың, —
чагылырмын анда.

## Бәлки…

«Хәзер — сулган. Элек күрсәң,
имәнеп торыр идең!»
Мин ул чакта аны, бәлки,
сөймәгән булыр идем!

## Бергә чакта

Очрашкач — сүз онтыла.
Аерылышкач — килә сүз.
Бергә чакта тын тору да
сүздән артык, күрәсең.

* * *

*Янган еллар, янган еллар,*
*утларда янган еллар...*

Корыч канатмыни бу мускуллар!
Офыклар чигенә бүгенгә!
...Ә сагынам — авыру, хәлсез килеш
очкан чакны синең күгеңдә.

## Ә ник тамды...

Әйттең: «Рәхмәт! Нинди хозур!
Нинди бәхет бу яшәү!»
Ә ник тамды балдагыңа
ике бөртек күз яше?

## Яме!

Нык тораммы, чайкаламмы,
Күккә ашаммы, аваммы... —
Хурлыгымның ахыры бул,
Зурлыгымның дәвамы!

## Борчылма!

Син — тормыштан сугышып алган
илаһи минутларым!
Кайгырма — начар уйламам,
борчылма — онытмамын!

## Белсәм дә...

Син биргән бөек мизгелләр!

Кабатлыйм исемеңне —
Мизгел өчен гомрем белән
белсәм дә түлисемне...

## Сагыныр дип уйласаң да...

Җан ярсуын басмас сыман
Иделдәге сулар да!
...Сагыныр дип уйласаң да,
ялыныр дип уйлама.

## Шөһрәтсез юл

Көликме без, елыйкмы, —
Ни дип әйтик бу эшкә?

Шөһрәтсез юл үттек икәү:
Сөюдән — үкенечкә.

## Бер чәчәктән ике балкыш

Кавышусыз мәхәббәттән
Берәү җыр калдырмакчы.

Берәү, Кояшка үч итеп,
дөньяны яндырмакчы.

## Теләсәң нишлә...

Җир чәчәкле. Җилләр талгын.
Күкләр аяз. Кемнәргәдер дөнья — иртә яз.

Теләсәң нишлә: көл, ела язга карап.
Вакытка барыбер, ул — битараф.

## Гомер агачы

Озынмы гомер агачы?
«Кем белгән аны?!» — дисең.

Яшәвең — җил. Яфрак — көннәр.
Очалар... сизмисең.

## Хыял атлы нәфис нәфес

Төнбоеклы тыныч күл дә,
балкыр ут та,
гөл бөресе дә буласы килә
бер үк мәлдә!

## Туры килер...

Теләсәң күрсәтергә гел
алма күк кызыл ягың —
туры килер борылырга
Кояш әйләнгән саен.

## Еш кына…

Күп күрдем сандугач оясын.
Берәүләр кұралмый гомергә!
Әнә шул берәүләр еш кына
өйрәтә — кай төштә күрергә.

## Икәү

Ялгыз туу, ялгыз китү…
Күмәклек — уен икән!..

Чиктән чиккә сугылабыз
Ялгызлык белән икәү.

* * *

*Аполлинердан*

Борча-көч, дуслар, сөяркәләр
мәрхәмәтсез: безне — сөяләр.
Сөяләрме, димәк, тешли алар,
башың ашый… Сак бул, ир адәм!

## Төнге самолетта Казан өсләп

Утлар гирляндасы бер дәрья!

Иллюминаторга ябышып,
чын-чынлыклап эзлим
Синең тәрәздәге шәм яктысын…

## Җәйге төндә авыл өендә

Әй, аҗаганы!
Яктысында күренеп калды
күбәләк кагынганы.

Кайткан кем җаны?

## Өздем…

Кайгылы чагымда килмәде.
Авыр булды. Түздем.
Шатлыклы чагымда килмәде.

…Арабызны өздем.

## Йолдызлар

Йолдызларга йодрык күрсәтмиләр.
Сокланып, таң калып багалар.
Аларда миллиард кешеләрнең
күзләреннән күчкән нур яна.

## Китәр алдыннан

Кочагыңда килеш
инде сагына да башладым!

Алда — юллар,
биткә бәрер бозлы яңгырлар...

## Картлар сүзе

Ике хәзинә бар дөньяда: саклагыз!
Каберстан аның берсе. Гел гөлдә булсын!
Китапханә икенчесе. Күңелдә булсын!
Базар болай да калыр...

## Гашыйклар

Бәхеттә янган икәү!

Утыралар яшел чирәмдә,
бөтен дөньяга нур чәчеп,
Кояш күләгәсе астында.

* * *

*А. истәлегенә*

Арысланнар йөрми көтү белән.

Йолдызлар да
бер күч кебек
күренә генә.

## Яшьлек

Кай якка барсаң да сукмагың кояшлы!
Ишекләр — алдыңда үзләре ачыла:
Кайда да кирәксең, кайда да көтәләр!
Баскан төшең — җирнең кыл уртасы!..

## Кайда да...

Эльбруска, Витошага, Чатырдагка*
менеп кычкырдым.
Кайтаваз булып һәр чакта
Синең аваз ишетелде.

* * *

*Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов,*
*Тукай — өч йолдыз ул.*

Ул заман — «түбән» булган.
«Түбәсе» кыек булган.
Ә шулай да шагыйрьләре
зур булган, бөек булган.

## Гел юлда...

Кошлар оча бер кыйтгадан бер кыйтгага —
бала чыгарырга.

Без килгәнбез ниндидер бер
исем калдырырга...

* Эльбрус, Витоша, Чатырдаг — тау исемнәре.

* * *

Атылды бер йолдыз
Киек Каз Юлыннан.

Матур китү турында уйлану
беркемгә дә иртә түгел.

* * *

Төнге күбәләкне харап итә
утка сарылу.

Шагыйрьләрне үлемсез итә
халкы өчен яну.

**Егылып айныгач килгән уй**

Тайгалады минем йөрәк тә
шома күзләрдә.

...Күпме акыллы баш ярыла
матур тезләрдә!..

* * *

Белми генә күпләр:
без бит — Сак-Сок!..

Әкияттә түгел, чында булгач,
тик исемнәр генә бүтәнчә.

## Казан

Кем белгән ул түккән кан-яшьне!
Кем белгән ул туган ел-яшьне!

...Әләмдәй чайкала агачлар —
ямь-яшел.

## Туган якка кайтышлый

Бөтен тәрәз тулы гөлләр
Имәнкискәдә!

Күңелләре гөлдәй булсын
Сездә үскәннең.

## Халәт

Гел генә тау менәргә дә
Җан ашкынып тормый.
Һичкем әйдәп кул изәми,
беркем ашыктырмый...

## Апрель

Егет шундый кочты каенны!
Кәүсәсеннән мөлдерәп яшьме чыкты?..

...Судан кайтучы кызга ул
бер гүзәл сүз әйтәчәк!

## Авыр хәл

Гозерем бар иде, килгән идем,
эчемне бер бушатырмын дигән идем...
Күзләрен гел яшерде миннән.

Кире кайтып киттем өемә.

## Уяндым да...

Уяндым да, бер шомлы гамь
качырды йокыны.
Гомер — бер. Яшәлгән шактые
кердееле-чыктылы...

* * *

Күрче, Кояш нурын ташып,
карлыгач оя кора!

...Офыкта — аны тузгытырга
зилзилә болыт тора.

* * *

Еллар, туган, сиздермичә оча гына!
Көннәр җәяүле җил кебек йөгерә!

Тик сәгатьләр генә, текелдәп,
мыштырдый күк...

* * *

Әле болай дөнья, әле алай...
Гел үзгәреп тора бәя дә.

Фронтовиклар кими барган саен,
сугыш батырлары күбәя...

## Сабырлык

Сабыр савытлары сары алтын!..
Кайчак хыянәткә тиң алтын!..
Кайчак сабырлыкның иң чыны —
җанның шашып-шашып ярсуы...

## Елмаюың...

*М-гә*

Гомер буе серле елмайдың син...
Булдым, димим, моңа гел риза.

Кемдер, бәлки, аңлый алыр булган
минем Мона Лизам!

* * *

Мин сагынып килдем.
Ул киенеп чыгып китте.

...Өзгәләнеп ул кайтканда,
мин еракта идем инде.

**Искә төште үткән язда әйткән сүзең...**

Тик бер кылда сызылып үткән кебек,
үтәр уйлар, үтәр бу яз да!
Әгәр җаның бәхет тойган булса —
шатлык моңы калдырыр беразга...

**Бер яшь шагыйрьгә**

Кикрик — зур.
Күкрәк — тар!

Шәп ояда...
бер күкәй бар!

* * *

Зур кайгылар баса кичерәген,
олы ялкын каплый күмерне.
Аңлар җанга — һич төзәлмәс яра —
зая үткән көне гомернең.

## Яшьлек үткән өй нигезен ташлап киткәч...

Ник туйганчы чана шумадым
Әмәт тавында?..

Кул изәгән сылулар инде
бүтән табында...

* * *

*Елан аждаһага әйләнсә,*
*аны Дәрья уртасындагы*
*утраудан килгән кара*
*болыт суырып ала, имеш...*

Халык риваятеннән

Аждаһаны узган залимнәр бар.
Ә болыт тик тора.

Кайчак йолдызларның үзен
Җир йотып тора...

* * *

Намус — җанның сакчысы.
Еллар — гомер баскычы.
Кылыч — күкрәк ачкычы.
Шигырь — йөрәк ачкычы.

* * *

Диңгезләр — кораблар зираты.
Офыклар — чардуган.

Кемдер бәйләп киткән өскә
Ай белән Кояшны...

**Ачулану, имеш...**

Беткәнмени сиңа
алтын комлы диңгез ярлары,
паркларда якты сукмаклар... —
керфек очларымда йөрмәсәң!..

## Күләгә

Сөттәй ап-ак карабодай кыры.

Зәңгәр күктә нәни ап-ак болыт
ябып йөри бал кортлары канатына
соры яулык...

## Җинаять

Болында мин ялгыш өздем
тамыры белән бер ал чәчәкне!..

Салават күперендә бер төс
тоныкланып калгандай булды.

## Чегәннәр

Юл читендә чатырлары.
Башкалада — театрлары!

Сәнгате чыкмаса юкка —
үлем юк халыкка!

## Портрет

Җирдән гел яхшылык җыймакчы иде,
ике кулларына ышанып.

...Шәфәкъ батуына карап тора —
ике күзкәенә яшь алып.

* * *

Мендем дип шәп атка, иярдән
таянып сөйләшмә бөергә!

...Килмәсен беркөнне, «ярыйм!» дип,
чүгәләп-чүгәләп биергә!

## Әле...

Төз сыннарны безнең сыгылдырыр
җилләр йөри булыр бик ерак!

Әле үлән булып үсеп тора
беркөн тәнне басар туфрак...

* * *

Без яшәүдән нинди билге
калыр җирдә — еллар әйтер!

Ә бүгенгә шунсы анык:
үтә гомер, кала хәтер...

**Учак яки охшату**

Утынны мул салган саен —
төтен ялкынны буа!

...Гаҗәпләнмәдем моңа —
Мәхәббәтем иш шуңа.

* * *

Яланнарга чыксаң, ялгыз чыкма, —
дус-ишләрең булсын юлдашың!

...Иптәш булып якты йолдыз янсын,
япа-ялгыз калгач бер башың...

* * *

«Улым!» диючеләр кими, кими...
Иртә китте бабай-әтиләр...
Тик бер өмет: лаек булып, бәлки,
Ил «улым» дип дәшәр ятимгә...

* * *

Ялгышлыклар, яманлыклар
каршылыклар аша бара.

...Байтак күңелсез уйларым
тормышка аша бара.

* * *

Дуслар тыныч: кирәктә дә дәшми, —
карап тора, аңлап тора...
...Ятлар сизгер, сак: колак шомартып,
ялгышыңны аулап тора.

* * *

Мин Ирекне тойдым, татыдым тәмен,
Татыган саен... сусадым гына!

Баер дип күңелем, коендым Сөюдә —
бушандым гына...

## Ашыкма!

Җаны чыгып, тән суынмый торып,
күрәк сабын ашыгып тотма син!
...Кызып казыганда, йөрәк туктап,
ләхет сине үзе тотмасын!

## Ирешү

Акбүз атта. Иңдә — җилән. Башта — бүрек.
Киттем тауга — үзәннәрдән качып.

...Мендем. Торам. Ялгыз. Атым — үлде.
Тауда — җилләр. Яланбашмын. Күкрәк — ачык...

## Шаяру

Гашыйк Гарип... Гашыйк Гомәр...*
Гашыйклары белән данлы ил!

Шул гашыйклар арасына
сыймас дисез мәллә бер Равил!..

## Яшенле төн

Болытның йөрәге шартлады.
Иманнең ботагы чатнады.

...Сабый кыз керфек тә какмады.
Әнисе бүген дә кайтмады...

* * *

Атылды ук. Балкорт кулны чакты.
Җәя керешен мин ник тоттым?

...Әллә гомер, әллә кызыл шәраб —
касә төбендәге бер йотым?

* Гашыйк Гарип, Гашыйк Гомәр — Шәрекъ дөньясының мәшһүр шагыйрьләре.

* * *

*Яуланган һәр рәхәт биеклек*
*түләүне сорый җан белән!*

Бәхет диңгезендә йөзәсең!
Бәһасен белмисең кебек.

...Тузганак башларын җилләргә
сатарга йөрисең кебек.

* * *

Алып киттеләр челләдә. Җәйнең
чык та төшмәгән бер таңында.

...Еллар үткәч әйттеләр: югалды
теге еллар бураннарында!..

**Әрлән**

Чаба-йөгерә. Казый. Ташый.
Йөгерә-чаба. Ята. Ашый...

...Күмеп китте бөтен гәүдәсен
бөркет канатының шәүләсе.

* * *

Үги ана яфраклары
Җиргә үги түгелләр!
Илнең үги улы булсаң —
боек була күңелләр...

* * *

Сәясәттән ераклашкан саен —
Табигатькә ныграк елышам.

...Тәгәрәде кызыл кыргый алма
елан үтеп киткән юл аша.

## Идел буе. Иртә яз

Ярымкорган алмагачын
бер карт йөри акшарлап.

...Калын дулкыннар өстендә
оча ябык акчарлак.

## Язгы күбәләк

Нинди сары чәчәк соң бу
ап-ак чиядә?

...очты китте касә-канат,
тотыйм дигәндә!

## Уяну

Сихри төндә йөрдек икәү ак атларда!
Ал офыкта җуйдым сине таң атканда!..

...Ярым айный төшкәч, чыксам өйалдына, —
тышта суык яңгыр ява талгын гына.

## Бер күзәтү

Таяну кыен ятим үскәнгә, —
сынаган бар яшен-картын да:
җил кая иссә — ул шул якка ава,
кайда җылы — шуңа тартыла...

## Ачыну

Шыр яланда ничек күшекмисең —
өстән явып торгач кар-яңгыр.

...Эчләренә шәмнәр куйыйммыни —
күңелләре булгач караңгы!

## Тургай

Бак та уйла: гыйбрәт бу —
шагыйрь белән җырчыга!
Җыр белән күтәрә Җирне
гаугасыз-даусыз гына...

## Юктыр, димсез...

Куе томанлы күкләрдә юктыр, димсез,
адашкан, яралы бер-бер кош җаны?

...Кояшлар уйнаган чалт аяз күземдә
юктыр, димсез, сагышларның куе томаны?..

* * *

*Кышкы урманда офтандым да,*
*юатты бер өмет-уй...*

Вакыт япты. Карлар күмде... —
җәйге сөю-яраны!

Яшь бөреләрдә яңасы
килә бугай ералып...

## Вакыт үткәч, иясе киткәч...

Әй, килә соң тапкыр сүзләр бәхәс тынгач!..
Кайчак ачык күренә дөнья — күзне йомгач...
Күпме сөю уты каба яшьлек үткәч!..
Күпме даннар йөри артта, иясе киткәч!..

## Бер карт сүзе

Картайдым, өем тулды —
җиһазны җиһаз тартты...

Баедым: ишек төбендә
юлдашым — таяк артты!..

* * *

Җилне җигеп буладыр да,
тик җилне җиңеп булмый!

Илдән чигеп буладыр да,
тик илне җиңеп булмый!

**Үз-үзеңне...**

Үз-үзеңне кыйнау яхшы
мунчада чабынганда.

Үз-үзеңне мактау ярый...
зур эшкә кабынганда!

* * *

Шаккатам мин түрәләрнең вакытына!

Катып калган ватык сәгать тә бит
тәүлегенә ике тапкыр
вакытны бик төгәл күрсәтә!..

## Килде заман!..

Халык аңы ташымый калмас,
бар дөнья чаң какканда!
Милли маңкортларга көн юк
«Идегәй»ләр кайтканда!

* * *

Илдә — шом.
Җирдә — шым.
Гарип көй,
сәрхуш моң…

## Сиңа!

Артыңда — салават күпере.
Гомерең — көянтә…
Егыла калсаң —
кем күтәрә, ә?

* * *

Кош булалмады. Сызланды
очканнарын күреп, тоеп...

Хәзер йөри, көнләшүдән
еланнарга канат куеп!

* * *

*Килгән икән сиңа картлык*
*үрмәкүч сурәтендә...*

Күз төпләреңә сарган да
нечкә үргән җәтмәләрен,
ята үзе җәйрәп кул арканда,
тамырларың буйлап таралып...

* * *

Син юк чакта уянасы килми!
Һич керәсе килми чынлыкка...

Син бар чакта, вакыт йокыга әрәм.
Гүзәл төш тә чыга гел юкка!

## Кышкы бакчада

Мәк чәчәге балкыр җирдә
бер кызылтүш
канат кага,
кар уйнатып!

## Бер...

Башың биш булса да,
яулыгың бер.

Нәфсең ун булса да,
саулыгың бер.

## Үткәнгә бер борылып карау

Язмыш булды микән? Ялгышмы?..
Сиңа бәйле байтак яшь гомер.

...Ул елларга хәзер ни дип карыйм?
Каш җыерып куйсам — син кичер.

* * *

Быелгы беренче күк күкрәү авазын
ишеттем мин Туган якта!

Кайда гына яхшы сүз ишетмим —
колакта әлеге күкрәү аһәңе...

* * *

Әй коя яңгыр, дөньяга үткәзеп!
Миңа ни: барыбер өем юк...

Гөнаһлы аяклар сөйрәлә Җир буйлап...
Күкләргә менелми. Чөнки анда үлем юк.

* * *

Өстәлемдә — хәләл икмәгем.
Күңелемдә — ирегемне тойган горурлык.
Кешеләрнең күңелендә —
азмы-күпме җыйган яхшы атым.

* * *

Өстән торып карыйм: син бит әле бөре!
Ә мин инде күптән яфрак!

...Беркөн аста көтеп каршыларммын:
икебезгә дә мендәр — туфрак.

**Берәүнең вафатын ишеткәч...**

Күпсенеп яктысын дөньяның,
кешегә яманлык теләмә!

Нәфесең чиксез зур булса да,
мәңгегә килмәгән берәү дә...

* * *

Әгәр Ватаның җуелса —
гадел үч һәм көч телим.
Әгәр сөйгәнең җуелса —
кавыштырыр төш телим.

## Бер популяр җырчыга

Аның хәтта күләгәсе дә юк!..
Төрле яктан прожекторда!

...Дансыз көннең кара шәүләсе
әле аулакта көтеп тора.

## Юлда

Артта — яндырылган күперләр.
Былбыллы назлы таңнар!
Алда — билгесезлек рәшәсе.
Һәм... сынаулы Синең күзләр.

## Бер кичтә...

Хаста җан иң соңгы кат керфек какты.
Кактус гөл беренче кат чәчәк атты.
Берәүнең газизе чит иңдә ятты.
Күк, ярсып-ярсып, йолдызларын атты...

## Бер ветеран сүзе

Асты өскә, өсте аска
әйләнде дөнья безгә!
Колмак бата, таш йөзә...
Йөрәк тузды, баш түзә.

## Күк

Күк — зәңгәр сандыгым минем.
Бик күп серләрем — шунда!

Ачам кайчак. Ачкычы аның
сөйгәнем куенында.

## Бар иде...

*Анда туташларда ымлар,*
*Күз кысулар бар иде!..*

Дәрдемәнд

Әйтә иде «гусар!» диеп кызлар-дуслар!
Уч төбемдә сайрый иде асыл кошлар!
Таңнар ата иде. Алар кочагында!
Назлый иде Гөлләр шәфәкъ-кич чагында!..

* * *

Киштәләрдә арта китапларым.
Маңгаемда — җыерчыкларым...
Башта — чәчләр сирәкләнә бара...
Күңел дә зирәкләнә бара!

* * *

Җелеккә үтте уйнакчан ярлар!
Шуңа якын булдылармы?..

Кемнәр бәгърен көйдерер икән
уйнап язган бу җырларым?

* * *

*...ханымга*

Йолкышланып, «дан!» дип, «мал!» дип,
кем — бик биек үрелгән,
шуның — кешеләр көләрлек
итәге күтәрелгән!

* * *

Гел «мин! мин!» дип сөйләнгән җан
беркөн үзен югалтыр...
Без — күбрәк «без!» дип әйтсәк —
җирдә бердәмлек артыр!

## Кышкы Кама

Киртләч көртләр — ак дулкыннар.
Чана-ат — фарватерда!
Ерак ярдагы көймәләр —
акчарлак канатыдай!

## Кояш астында яшим дисәң...

Максатың булсын да хәтерең булсын!
Сөйгәнең булсын да ирлегең булсын!

...Тәпи басарга һәм күмелергә
тәгаенләнгән җирлегең булсын!

## Күзләрең

*Эзләдем. Таптым. Югалттым.*
*Бүтән табылачак түгел...*

Карадым да күзләреңә —
яшьләрем тыялмадым...
Күп хәсрәтләр сыйды аларга,
бер бәхет сыялмады!

* * *

*С.Батталга*

Бу дөньяда шуыша да
белми бит ул, «булмаган!..»
Ул — очар өчен туган шул,
сөйрәлергә тумаган!

## Теплоходта үтеп барышлый...

Ярлардагы сыр-сыр катламнар —
ерак гасырларның эзләре.

«Үткәннәр гел өнсез түгел!» дигән кебек
атылып чыкты ярдан карлыгач!

## Яшенле яңгырдан соң...

Күк катында алиһәнең
ялтырады алкалары!

Югалды үзе. Аллы-гөлле
көянтәсе калды бары...

## Сагыну

Бер-ике юл ямансу шигырь...
Хатирә — ул татлы көннәрдән!

Шәфәкъларда, алсу болыт булып
тибрәнә Синең көләгәң!..

## Язгы халәт

Күктә күренеп алды сөйгәнемнең зәңгәр яулыгы!
Килеп китте җилдә җир җиләге исе!
...Үзләренә бакмасам да, шәүләләреннән күренә
яшь җаннарның наз теләгән дәртле көче.

## Мал җанлылар җирдә арткан саен...

Үлән-яфракларга төшкән чыктан күбрәк хәзер
адәмнәрдә — алтын бөртек, җәүһәр, асылташлар...
Мал җанлылар җирдә арткан саен Рух саега,
кадерсезрәк була бара асыл башлар.

## Төнге бер уй

Үрмәләүләр, бәлки, төшүләрдер?
Егылулар, бәлки, менүдер?..

Тыныч халәтләргә кайтыр юлны
якынайтып йолдыз җемелди.

## Еллар үтеп, яшь барган саен...

Сабыйлыктан һаман ерагая
гомеремнең бу як очы!

...Еллар үткән саен арта бара
кешеләргә бурычым.

## Акмулланы укыгач

«Йорты Болгар улса улсын —
йортны болгар улмасын!»
Исеме татар булса булсын,
җанны сатар булмасын!

* * *

Ага суда төз бер нарат.
Салдан аерылганмы?

...Нарат үскән төптә ята
аккош каурыйлары.

## Июнь

Кыңгыраулы сабан туе
сандугачлы таң алды!

Синме, аҗаганмы үпте?
Җанда матур җыр калды!..

## Карадагта кызыл* җыйганда

Безнең якның чияләре кебек
якут җимеш сарган ботакны!

Ул куш бөртек каян килгән дисәм, —
Синең иреннәрең икән!

## Сагындыра...

Диңгез шавына кушылган
назлы авазлар!..
Сине уйлап, таулар менгән
хыяллы язлар!..

## Күктүбә комлыгында

Һәр дулкынның үз исеме бардыр кебек.
Ә бу дулкын — Синең исемдәдер!

...Дулкынныкы кебек ак яллы атта
Сине урлап очтым төшемдә бер!..

* Кызыл — русчасы — кизил. Җылы якта үсә торган җимеш.

* * *

Көнләшүдән бигрәк, соклан, туган!
Акны барыбер: «Ак ул!» — диярләр.
Хак сүзне гел бал димәсәләр дә,
Хөсетлекне: «Агу!» — диярләр!

## Халәт

*Агыйделнең арьягында ак болыт тора.*
*Яңа ярлар иске ярны оныттыра...*

Берен назлап, күккә чөйсәң,
бере — җирдә таптала...
Бер күздә — нур, берсендә — яшь:
җанда утлы гөл яна!..

## Шундый чагым!

Уемда — яраткан эшем.
Куенда — сөйгән ярым.
Дөньяга һәм кешеләргә
гел рәхмәт әйтер чагым!

## Май

Ялтыраулы сабан тәрәнендә
биеп алды тургай шәүләсе!

Кояш борылып торган арада
яңгырады язгы күкрәү!

* * *

Миндә, ахры, җәйге кошлар рухы —
кыш кермәгән, тизрәк яз кирәк!

Миндә, ахры, артык тиле йөрәк:
тузган саен күбрәк наз кирәк...

* * *

Бәйрәмнәр күп... Сабантуйга
җитә сирәге!

Матурлар күп... Ә күңелгә
Син — иң кирәге!

* * *

Һай бу гомер!.. Көтеп-көтеп,
туган кадәр дә юк!

Яшәү дәвер — таңда төшкән
томан кадәр дә юк!

* * *

Җан тынычлыгын бозып дау булдым.
Үзәннәрдә торып тау булдым.

...Килде көн: Син яннан үткәндә —
иелеп калыр өчен тал булдым!

## Бу күңел...

Күптән бер атар иде бу ярсу күңел —
мичкәнекедәй кыршавы булса!
Шартлап өзелер иде, — камытныкыдай,
урап-урап алган бавы булса!

## Сиңа

*Гомерем буе Сине сөйдем.*
*Гомерем буе ят булдың!..*

Таң иде... Бәхетле йөземә
Син булып беренче нур кунды.
Ә кичен — ал шәфәкъ нурында —
яралы киек күк хур булдым.

* * *

*Альпинист Н. истәлегенә*

Болытлардан да югары
җырлап аккан чишмәләр бар.

...Мәңгелек кар эчләрендә
өшеп яткан йолдызлар бар.

## Тегермән урынында

Бер-ике учма арыш башы...
Калган үлән — алабута.

...Зур ипи кыерчыгы күк,
җиргә батып ташы ята.

## Апрельдә. Урманда

Язгы бөре! Бизәнеп кал
кар сулары көзгесендә!

...Шул ук төштә ятасың бар
яфрак булып көзге көндә!

* * *

Чит илләрне, ят якларны күрәм —
Туган җирне аңлар өчен.

Һәйкәл, каберләргә баш иям —
исәннәрне санлар өчен.

## Гөлдәге чык, җырга әйлән...

Бу — чык түгел, шатлык яше —
сөйгәнем яңагында!

Гөлдәге чык, җырга әйлән
сандугач тамагында!

**Вакытның хәтере шәп аның...**

Тиз чигәбез телдән, тарихтан...
Чүккәнбез Бүгеннең тезенә...

Вакытның хәтере шәп аның! —
бик тиз онытырлар безне дә...

* * *

Сөю безне көчле итә.
Ә шикләр — җанны тетә...
Ваклыклар килеп өстәлсә,
кеше... бетә!

* * *

Олы шатлык килсә, сагаямын.
Китәчәге авыр буласы...

«Алтын алма!» диеп үрелгәндә,
Карыйм аска: кая егыласын...

* * *

Кош бит мин! Шуңа егылмыйм, —
имгәнми генә авам...
Кеше шул мин: күккә генә
сыймаслык йөрәк ярам.

**Күчеш**

Агач иде... Ялкын булды, —
нуры күңелгә төшә.

...Кеше дә яна. Исеме —
ил хәтеренә күчә.

**Чаба балта тамырларны...**

Чаба балта тамырларны!
«Нихәл, туганым! — диеп, —
агачтан юнылган бит
Минем дә сабым!» — диеп.

## Кызылтүш

Карлы дугалар өстендә
кызыл кыңгырау!

Кышкы урман уртасында
язгы яңгырау!

## Авылда

Бала әйтә: түтенне әнә
бәйләгәннәр морҗага!
...Тау читендә бәйсез-нисез
кинәнеп туйлар чаба...

* * *

Картайгач тал бөгеләме?
Бөгелми ул! Ул — сына...

Нужаларында бөксә дә,
җан яшь чакны юксына!

* * *

Хәләл дими, хәрам дими,
җыя гел: «Ашым!» — диеп.

...Дөнья да гадел усал —
костыра, баш идереп.

* * *

Күтәрер әләмең булмаса,
ышаныр адәмең булмаса, —
күңелеңдәге ил турында
сузып җибәр җыр, булмаса!

* * *

Кем — явызлыгыннан кибә.
Кем — изгедән сагая.

...Көнләшүдән күгәргәнче,
сагынудан саргаям.

**«Кайда ятасың?» — дигәч...**

Ятар җир шул:
Бөеклек чыбылдык корган
Бәхетсезлек бишегендә
тиле-миле тирбәлү.

* * *

Чәчәкле май чагым үтте.
Хәзер — җәйге мәлемдә.

...Батыр калыр көч тоеп та
көрәшмәгән хәлемдә.

* * *

Көч бир Син миңа, мадәт бир!
И Аллам — Бөек хуҗам!

...Ник тыныч түгел бу күңел,
ник тыныч түгел бу җан?..

* * *

Кызыгыр идемме, белсәм —
меңе белән түләсен!

Агачның ничә катлыгын
кискәч кенә күрәсең...

* * *

Алда язмыш ни күрсәтер...
Үткәненә — мең рәхмәт!

...Гомер буе юлдаш булды
Саулык белән Мәхәббәт!

* * *

*М.Ә-ка*

Юнәлеш — бер.
Аралар гына бүтән.
Сызлану — бер.
Яралар гына бүтән.

* * *

Кешеләрне зурлап сөйләү —
хикмәт булыр.
Җансызларның иң җанлысы —
икмәк булыр.

**Алда әле...**

Уңсалар да, шактый гына,
күзем үткер калды әле!
Сүзләремнең чын бәясе
Алыныр көн алда.

**Безнең көннәргә штрихлар**

Урылмый калдылар игеннәр.
Кыраулар өшетте мул кырны.

...Базарның чатында угрылар
гармунын «суктылар» сукырның.

* * *

Булган заман: рух өстәп авылга,
осталар утырткан манара.

Булган заман: менгән биеклекне
имгәкләр арканлап аударган...

**Боз сөңге**

Өркетеп карады биектән:
«Теләсәм, бу Җирне тишәм!» — дип.
Белми шул, төшлектә эрегәч,
үзен үк чыпчыклар эчәр дип.

* * *

Балдак киясе бармакка
чыкты сөял.

Кая барып сөялим?
Менә сөаль!

## Төн

Шакал үләксәдән лакыл булгач,
Айга карап сузып улады...
Ә тегесе Күктә
тулышып балкып тора!

* * *

Без бу дөньяда бары кунак кына...
Ә кунак рәхәттә яшәргә тиешле!
Тик шунсы бар: Вакыт-чамаңны бел! Җирдә
артык булып әрсез яшәү һич килешми!

## Кара ел...

Апрельдә җәй булды.
Талантлар — кырылды...
Берничә бөртек калды
Шигърият кырында.

* * *

Син мине бүтән каргама!
Каргасаң — җаным туңа.
Каргышыңнан үзеңә дә
яңа борчулар туа.

* * *

Имәннәр соңарып яшәрә.
Яшеннәр эриләр үлгәндә.
...Кендеге ярыла ахмакның
бер бөек «мәхлук»тан көлгәндә.

* * *

Син күргәндә яшен инде үлгән була.
Без күргәнне Яшьлек күптән күргән була...
Эч пошырып янда: «Мин яшьмен!» — дип,
маймылланып Картлык йөргән була...

* * *

Өметләндек: җырыбыздан
илләр куаныр, диеп.

...Комга рәсемен ясадым —
җилләр юаныр инде!

## Бу дөнья...

Капка — читәннән тора,
рәхәт — читеннән тора,
башың — к...цнән тора,
үлем — китемнән тора.

## Бу көн...

Еланнар терелгән көн...

Сират күперен чыкмый гына
акчалыларга җәннәткә
юллама бирелгән көн.

* * *

Урыска рәнҗеп туелган.
Төреккә — ерак...

...Кош булып, күңелем аша
елый туфрак.

* * *

Ялгызлык гаҗәп нәрсә ул —
өметең исән чакта.
Иш яралган ялгыз берәү
уйласа синең хакта.

* * *

Дошманыңнан гөл алсаң син,
артык гаҗәпләнмә!

...Дусларың агу бирсәләр —
әзерме син, бәндә?

* * *

Алдагысын беркем белми…
Алдагысы — Аллада!

Кочак хәсрәт, кушуч сөенеч
бардыр, шөкер, алда да.

**Килешә**

Акбүз атка көмешләнгән
кара йөгән килешә!

Дөнья күргән бай-сау иргә
яңа ярлар килешә!

* * *

Күммәсәм дә,
Бәхетемне куйдым киртәләп.
…Яшәргә соң…
Ә үләргә әле иртәрәк!

* * *

*Үпкән-кочкан —*
*җилгә очкан...*

Очуын очкандыр да...
тик җилләр кире китереп
янә бәгъремә сипкән!
Хәтеремә янә чиккән.

* * *

Хөкемдар булган бит әле,
ата угыры булып...
Бөкредән тугандыр ул,
бу кадәр «туры» булып.

## Ятим

«...Минем бернәрсәм дә юк!
Мин гел — «юк»тан торам...»

Кайдадыр бүреләр улый.
...буран котыра.

* * *

Уйладым — минем гомерем
ике-икең — биштән тора...
«Тудым-үлдем» дигән фигыль
сиксән килештән тора!

* * *

*Моннан Әби патша үткән...*
Ишеткәннәрдән

Җиңгәннәрне хәтерли халык.
Җиңелгәнне — сирәк.
Алганнарны үрнәк итәләр.
Биргәннәрне — сирәк.

## Ретро

*(XX гасыр)*

I

Солдат атлары
бигрәк мескеннәр!
Ашарга сорап
шинель тешлиләр!..

II

Машиналылар
бигрәк күбәйде!
Төтеннәреннән
Күк түбәнәйде...

III

Рәсәйдә халык
бигрәк бәхетле!
Эчеп үләләр —
әҗәлне көтми...

## Бозылыш

Февральдә яшен күренде.
60 тагы 16 яшьлеккә үрелде.
...Октябрьдә салават күпере?!
Оялып күземдә эреде...

## Кыш алды

Авыл өйләрендә эч-баш, карта исе!
Чемодан эчендә кипкән җир җиләге!
Җәй буе тик яткан гармуннар биешә!
Яшь киленнәрнең яңа әти-әниләре.

## Күз уңу

Яшәмәдек, дисәк, алар әйтсен —
еллар, ярлар, диңгез-атаулар...
Дөнья камиллеге кимегәнме? —
ниндидер бер төс җитми ал таңда...

* * *

Яхшылык эшлә дә, —
яманлык көт!

Акмы, карамы —
Эт — барыбер эт!

* * *

Һәммәбез — вакытлы сау кеше.
Һәммәбез — бер Кулда, бер Юлда.
Мәңгелек Сәфәрдә — Изгегә
күңелең нурларын тот уңда.

* * *

Кадерсездән — кадерсезгә.
Кара көздән — ай юлына...

Калам, ахры, «җан дуслар»дан
Киләчәкнең ак кулына.

* * *

*Әй, замана, замана!..*

Ураза да тота. Зина кыла.
Дога катыш әче сүгенә.
Өстәвенә җырлап салып бирә:
«Мәхәббәтем только син генә!»

## Кем ул?

Сәдакалар өләшкәндә
өлешсез калган җанмы?
Әллә... үз тиешен бирми
калган каруннарданмы?

* * *

Һәр юбилей саен бер «бөек».
Һәр ел саен — алар берничә...
Тик... укырлык шигырьләр тапмыйм,
Башны кашыйм, «шуны белмичә...»

* * *

Киләчәкме? Ансы хәл ителгән!
Язмаганны көтмим.
...Дөньяны бет басса да,
Мин барыбер бетмим!

* * *

Ялгызстан патшасында
Вәзир булдым мең еллап.

Киңәш кирәкме? Белешмә?..
Язып бирәм... бер юлдан!

* * *

Загс. Аерылу. Суд. Киңәшчеләр...
Нәтиҗә дә яхшы: шәп карар!
...Тәрәзәгә кара: урам тулы кызлар
Һәммәсе дә аякланалар!

* * *

*«Их, милай!» — дип әйтә иде дәүәнием.*

Минем өчен борчылма Син!
Аңа хакың булу кирәк.
...Җисми тәгәрәшү бер хәл,
рухи туган булу кирәк.

* * *

Тимер ишекләр дә куелыр ул...
Гарнитурлар торыр өелеп...
Бер моң йөрер, урын табалмыйча,
иркен бүлмәләрдә, илереп...

* * *

Бер карыйсың — Алып.
Бер карыйсың — сарык...

Дөньяның олтанына
ярый торган халык.

* * *

Чалкан ятып, күзләреңне йомып,
күкләр зәңгәрендә очып кал!

...Сазлыкларга кереп батасым бар,
чиста чакта тәнне кочып кал!

* * *

Кайдадыр сугышлар бара.
Кемнәрдер — бетчә сыта...

Нишлисең?! Кайчак амеба
тау хәтле филне йота!

* * *

Әкиятләрен тыңлыйсың,
хәшәблеген күрмисең.
Кичерәсең ялганнарын,
уйгач шигырь өлгесен.

## Триптих

I

Туган җирең чүл булса да,
күңелдә ул гел генә!
Ватан катлы-катлы булмый,
Ватан була бер генә!

II

Акыл да бар, каләм дә бар...
Юк шул билдә... балтасы!
...Өтек шул шартнамәне дә
Турамакчы мең кайчы!

III

Кылычтан качып, «дуслык»ка —
(коллыкка) юл — иелү...
Тарих белми Ирек өчен
кан түкмичә җиңүне.

**Гәрәмәчкә. Солы кырында.**

Язган чакта каләм тиеп алды:
бәллүр савыт — төнге бер зеңләү!
...Рәшә булып Икәү тибрәнгәндә,
балкорт торды өстә безелдәп!..

* * *

Кирәксә әйт: «Ташладым!» — дип.
Мин ташларга ирендем.
Алма үзе өзелеп төште.
Кемдер әйтте: «Җил!» — диде...

* * *

Минем кочакта эрисең...
Илнеңме — куеныңда?
...Җаным оча, бәргәләнә
кемнеңдер уенда.

* * *

Күңелгә шик иңде...

Мәхәббәт югалды,
тынлыкта йотылган
авазым шикелле.

* * *

Якыным да Син минем!
Ерагым да Син минем!
Зинданыңнан чыгар юлга —
чырагым да Син минем!

**Хастаханәдә**

Ике халыкның баласы.
Соңгы сулыш — җан авазы.
Һаваларда чәкәләшә
азан белән чаң авазы.

* * *

Һәркем үз чикмәнен ябынган.
Ефәк корты кебек төренгән.
Кысык күңел, тишек җиң аша
«Коммунизм кыры күренә!..»

* * *

Күңелдә иман булмаса —
мәчет ни дә, азан ни!

Җәһаләт белән сәрхүшлек
безне әле озак җәзалар...

* * *

Утыз биштә. Өйләнгән. Алкоголик. Теләге юк.
Алма пешкән. Өзелеп төшкән. Череп ята. Кирәге юк.
Шигырь яза. Тамак туймый. Ил укымый. Тирәге юк.
Дөнья кайный. Эре-вак бергә. Аерып булмый. Иләге юк.

## Ичкерия

*(Триптих)*

I

Кавказ дәрьялары — кан елгасы.
Тау бозлары яшькә манчылган.
Каргыш болытларын сөйрәп йөри
күген җуйган бөркет-лачыннар.

II

Төннең — ае, көннең — кояшы юк...
Шомлы бер өн: иңри «ах-вах!..»лар...
«Җирдә нинди мәхшәр туе?» — диеп
кубарылып баскан әрвахлар...

III

*Юктырсың ла, Алла...*
М.Г.

Язмыш итеп, вәхшиләргә — җиңү,
ватандарга — үлем язасың?..
Җәннәт җирен тәмуг ясаганнар
нигә алмый Күкнең җәзасын?

## Ул төннәр истәлеге

Син чәпәгән черки эзе —
рамларлык сурәт!

Мәхәббәтнең сукырлыгына
тагын бер гыйбрәт.

* * *

*М.Хәсәневне уйлап*

Ятам ромашкалар диңгезендә
кулларымны җәеп чалкан!
...Ничек икән пәһлеван Мәхмүткә
корт та үтмәс цинк табутта?..

* * *

Диңгезләрне кичеп, ярга чыккач,
Томаннарда каласы иттең.
Синең-минем язмыш әле бер хәл, —
Дөньяны ямансу иттең...

* * *

«Ике икең дүрт» кебек хакыйкатьне
белеп бетермибез — кызганыч!

...Атасына карап, улын ярат,
анасына карап, кызын коч.

**Бигайбә!**

Аттылар — атылмады.
Саттылар — сатылмады...
Мәгънәсезлек ярышында
тилегә пар булмады.

**Сәясәт**

Күмдек Тегене,
Тудырдык Моны.
...Тарта тегермән —
юк кына оны.

* * *

Яралар, төзәлсә, үзе куба.
Язган бәхет иңгә үзе куна.
...Очарга йә егылырга Кеше
канатларны үзе куя.

**Була кайчак...**

Суда сусап, су эчелми,
Утта өтелеп, пешелми.
Гайрәт чиксә, бернине дә
күңел кичерми.

**Үзгәреш**

Авыл инде чит. Әмма таныш...
Мәчет тә буш, клуб та буш.
Өй борынча экраннарда —
ату-үтерү, секс-тавыш.

* * *

Иркен идек — тар калдык.
Күмәк идек — таркалдык.
...Бер көн килде — таң калдык! —
парлы-парлы так калдык.

* * *

Кешегә сан булса, көн була.
Көн булса — кояшлы ил була.

...Шәхесең, милләтең тапталса,
яшь тамган туфрагың көл була.

* * *

*Каргавың карга башына.*
*Карга синең башыңда!*

Кем белә бит, кара кайгыларның
кайчан килеп җанны айкасын...

Кайнар сумалалы канат булып,
каргышларың үзеңә кайтмасын!

* * *

Алтын кайчы — ал кисә.
Көмеш кайчы — гөл кисә.
Кылны ярып җил искәндә,
угъры патша Ил кисә...

* * *

Уртаклашкан кайгы — ярты кайгы.
Уртаклашкан шатлык — ике шатлык.
Кайгы-хәсрәтне үрчетмәсенгә,
шатлык чәчмәк булып, угълан таптык.

* * *

Күпме генә казганса да,
Һәр теләгән Алып булмас.

Җанда ялкын көчәйсә дә,
янган кадәр янып булмас...

* * *

Төкереп бир, кемсәләрнең
өерелеп өрүенә!
Тормый алар сабыеңның
бер ертык көлүенә!

## Кулъязма тапшырган көн

Бүген мин — җен!
Хәтта — кабахәт!..
Әмма — рәхәт!!
Киләчәктән өмет — рәхмәт.

* * *

*Шахта өсләрен каплаган*
*көзге сары яфрак.*
*Өстә микән, аста микән*
*безгә язган туфрак?*

Шахтер җырларыннан

Күмер базларында күмелеп калган
күпме татар моңы, күпме сүз!..
...Күгең булса гына җирдә казган.
Күккә күмелгәннәр генә үлемсез!

* * *

*Бюджеттан аракы исе килә.*

Дәүләт сәясәте — эчү.
Табышын шуңа корган.
Халык — сәрхүш. Ил — махмырда.
Саулыкка — «тишек юрган»...

* * *

Канунсызлык канун икән —
булмас Кеше кадере.
Исереклек — фетнә башы.
Аракы — ил кабере.

## Аңлашыла...

Тартария —
Татария —
Татарстан...

«Стан» өчен генә китте
күпме халык җегәре!
«Мөстәкыйль Татар иле»нә —
күпме җелек кирәге!..

* * *

Каркылдый карга ашыкмый гына...
Очына күбәләк онытылып!

...Үлеп киткән, йөрәге тотып,
утыз яшьлек геронтолог*.

* * *

Сары йортта «Наполеон»нар,
«Ленин»нар нотык тота!
«Мин — Тукай!» дип йөрүчеләр
очрыйлар Шигырь-Йортта...

* * *

Ага су. Әйләнә чарык.
Тегермән тарта тора.

Бабай акылы чыга тора,
оныкның арта тора.

* Геронтолог — кеше гомерен озайту фәне буенча белгеч.

## Бер үк көнне...

«Армия көне — бәйрәм!» дип
ир-атларны тәбрик итте.
...Улын солдаттан йолсынга
бер түрәгә ришвәт илтте.

* * *

Җылы шалашка да риза
ачлы-туклы торганда.
Пирамидалар салына
фиргавеннәр булганда.

## Безнең арадан...

Кара мәче йөгердеме?
Ак мәчеме?
...Корымлы күләгә
күңелдә.

* * *

«Хатын-кыз кем? Елан? Алиһә?
Тик... Кеше түгел!» —
диде берәү.
Сагайды күңел.

## Кем белә...

Офыкта торган болыттан
нинди яшен туасын?
...Беркөн килеп Илбашың
Ил ахыры булмасын!

## Начар хәл

Дөньяда начар нәрсә бик күп.
Начар уйдан да начары юк!
Белә торып, сиңа юлыктым.
Шунсы начар: качар чарам юк.

* * *

Алдан ук төртенмә!
Күрмиләр... Саналмый.

...Сасуы җитмичә,
иттә корт яралмый.

* * *

Табигать Җир ямен җәйгә генә бирә.
Хөкүмәт акчаны чәйгә генә бирә.
Кешеләргә күпме байлык калдырсаң да,
алар сиңа кәфен-җәймә генә бирә.

* * *

*Тиле шатлык чәчәкләре —*
*мәге дә, киндере дә...*

*Безнең өчен кызлар иде —*
*тиле шатлык чәчәкләре.*

Күпме халык, Чәчәк җанын алып,
үз җаннарын сата Иблискә!
Кеше — Чәчәк. Табигатьтә кайсы
ия булып чыга чын көчкә?

**Киңәш бирәләр...**

Аптырама эт-көчеккә!
Тешләсә дә үчекмә!
Геракл сабыйлык белән
елан буган бишектә...

## Спонсор эзләү

*Н.авызыннан*

Ах, читен җиде ятлардан
буй сонып теләнүе!..
Җиңелрәк — карт, бөкре
карчыкка өйләнүең.

* * *

Вакыт-талкый... Уй-гамь, исәп баса...
Тәңресе шулай яралткан.
Ата ялкау, пошмас наданның да
башын олпат итеп чал яткан.

* * *

Ләйсән яңгырда, күзләрне йомып,
учларымны суздым, «тамсын!» дип.
...Кемдер учыма тиеннәр салган.
Дөньяда тагын бер ятсындым.

## Тәгәрәштек Думада

Без гел үстек! Һәм үсәбез! —
Юл юк безгә башкача! —
Дәрдемәнд, Максудилардан —
Ахмакыйханнаргача...

## Дәрья

Давылланып, ярсып ташып,
Җиһанны куркыта ала!
...Йомычканы батыра алмый,
корабларны йота ала.

* * *

Бу дөньяның аръягында
өч гөнаһка бер савап!
Яшәү дигән табышмакка
табалмадым мин җавап.

* * *

Юньсез илнең синдә эше юк.
Умартасы булса, күче юк.
...Тиленәр йортына чират зур.
Акыл базарында кеше юк.

## Гомерем көзендә

Сабантуйга барган күңел белән
кайткандагы кәеф бер түгел.

...Шәфәкъ чакта таңлы куанычым:
нәни улым—өмет бөртеге.

* * *

Ата-анадан
яр якын...

...Күпме кала
Ил хакы?

* * *

Ботарлаша ике кош күктә.
Берсе — доган, берсе — каргышың?

Соң теләгең ниләр булгандыр? —
Каурыйлары коела башыма.

* * *

Укылмаган китапларда
бөек хикмәт ничаклы!

Парадокс: кайчакны
Ипи эзли пычакны!

* * *

Авгейныкымы, бүтәнме —
абзарлар көрәп йөреш,

Яңа гасыр укучысын
шәм тотып эзләп йөреш!..

* * *

Икәү бер сулышны бүлербез дип,
кавышкан иделәр бер таңда!

...Судта сулышлары кабып (бер булып!..),
бер бүлмәле фатир бүләләр...

**Картлык**

Таулар сөзәкләнгән иде...
янә текәләнде!

...Тигез җирдән баруың да—
бары мүкәләвең.

* * *

*Безнең картлык туры килде*
*Ил каны бозык чакка.*

Медальләр-орденнар түшенә сыймыйлар...
Тик... хәл юк йөртергә. Карт авыр көрсенә...

Булса да тирәндә ягылган учаклар,
тик барып җылына алмассың берсендә...

## Шулай да була...

Хикмәт сые бездән булды.
Кабул кылу—сездән булды.
Кайтавазы—гайбәт сүзе—
тездән булды...

## Бер дә юкка утырып чыккан берәү сүзе

*Калмады бер хатам да,*
*Калмады чабатам да!*

Анда бер төсле бурлар.
Монда бер төсле бурлар...
Яшәсен барсын көйләгән
судья-прокурорлар!

* * *

Салават күпере—
Пәйгамбәр кушагы.

Җирдәге җәннәтем—
Сөйгәнем кочагы.

* * *

Террор-суеш — көнгә җәрәхәт.
Фәхишәлек — рухи һәлакәт.
Оят җәяүләп качкан шул илдә
Ничек була алсын бәрәкәт.

* * *

Альп тауларын да күрдем.
Алып тауларын да...

Илаһ бер Биек Чик — Үлем —
Һәркем алларында.

## Хәл

*(Бала тугач)*

Бер аптыраган елаган, ди,
ике аптыраган — көлгән...
...Аптыраулардан гаҗиз булып
уртак гөл шытты көлдә.

## Кабынса...

Үтәлер иде ул
хыялың-теләгең —
халкыңда кабынса
Батырша йөрәге.

* * *

Саегасы җире саеккан.
Калкынасы җире калыккан...
Ияк җиргә кадәр иелгәч,
ни күтәргә инде халыктан.

## Сөенмә дә артык, көенмә дә...

Янәшәдәш исем-атамалар —
Көн-төн, ут-су, ир-хатын...

Шатлык килсә, шашып Күккә ашма,
Кайгың йөри булыр бик якын.

## Аптырама!..

*В этом прекрасном и*
*яростном мире…*

Кар астында гөл тамыры.
Яшәрергә өмет исән!
Аптырама! — картлык көндә
берәр көндәш «Дөмек!» дисә.

* * *

Булмагач анык
тарафлык —
халыкка сеңгән
битарафлык.

* * *

Төп башына утырттылар!..
И, шәп!
Урманда кәнәфи булмый…
И, ишәк!

## Корып барган агач

Су сипсәң дә тамырларына
дымы китә әрсез үләнгә...
Җан кысыла — беркем укымаган
өем-өем китап күргәндә.

* * *

*Раздели и властвуй!*

Атомны таркаткан кебек,
Татарны таркаталар...

Стратегик чимал кирәк
«Русь» дигән «ракета»га.

* * *

«Без — бар! Без — мәңгелек!» Тавышымның
яңгыравы кайта: «юк!»

...Төпсез тәхеттән «Мин дә бар!» дип
көлеп тора Карт Аю.

* * *

*Чайкала-чайкала*
*Иделдә ай кала...*

Безне озата баралар...
Яшь кыз чишенеп кала!

Бу юлы юньләп яшәлмәде, —
киләсенә кала.

* * *

Төбенә хәтле эч син Мәңгелекне!
Шәүлә-узгынчылар ялмансын!

...Корыр чам да шулай торадыр күк,
гел яшь, яшелмен дип алданып.

* * *

Беләсеңдер, җил шәп иссә —
яфрак тизрәк коелганын.
Сүз мулрак булган саен,
гөнаһ күбрәк җыелганын.

* * *

Керфекләр тирәли
картлыгың рәшәсе...

Бирсен сиңа Ходай
толлык дәрәҗәсен.

* * *

Киләчәк дигән алышта
Акча батыр баш калган!

Өмет-балдак кашы булып
эчтән чыккан таш калган.

**Авылга кайткач**

Каян танысыннар инде! —
күп җир үзгәреп беткән...

Яшь чактагы этләр беткән.
Болар бит бүтән этләр!..

**Әбүталип та әйткән, ди...**

«Мин әйттем!» дип әйтә берәү.
Әйдә соң, әйт!
Кешеләр сиңа ни дип әйтә? —
шунда хикмәт!

* * *

*Әй яшь чаклар! Яшь чаклар!*

Бүрәнә ярыгын күреп тә,
шаркылдап көлгән чаклар!

Зәңгәр түтенгә тотынып,
күкләргә менгән чаклар!

* * *

Барыр юллар ачык.
Күзләр генә ябык.

Дәүләтемне җуйдым —
булмый гына табып...

* * *

Кырыкка кадәр
азып-тузып була.
Алтмышка җиткәч
шигырь бозып була.

## Янә бер нәсихәт

Кәеф-сафа... Азу-тузу...
Нәфесле күңел!

Саулыгыңны бүген кайгырт,
иртәгә түгел!

* * *

Тавышым минем бар көченә
яңгырап бетмәс, беләм...
Чөнки тулган тирә-ягым
бик күп саңгыраулар белән.

* * *

Әйтер сүзләр әкеренләп бетә...
Булды заман, әйттек ихласын.
...Күз яшьләре кипте... Яңгыр булып
хәзер инде еллар еласын.

# *Үсмерчак дәфтәреннән*

*Шагыйрь булып,*
*китабыңны тотып,*
*кайтсаң иде туган ягыңа.*



## ВАКЫТ

Алай үтелгән вакыт...
Болай үтелгән вакыт...

Яшәп үтелгән вакыт,
яшьнәп үтелгән вакыт —
бүтәннәр бәхете өчен
сарыф ителгән вакыт!

*1958, февраль*
*Юлсубино*

## ЯЗ

Уята арган җаннарны
җылы нуры Кояшның.
Бөре яшел күзен ача,
сулышын тоеп язның.

Гөрләвекләрдә тибрәнә
күкнең зәңгәрлекләре.
Тургай җырына коена
кыр-басу киңлекләре.

Язның һәр көне, сәгате
дөньяны ямьләләтә.
Бу яз көнне яшь булуың
бәхет бит икеләтә!

*1958, март*
*Юлсубино*

## БАЛАЧАК ТУПЫЛЛАРЫ

Яр буенда тупыл, таллар...
Утырткан икән кемнәр?
Шул тупылларның иңендә
калды балачак көннәр.

Кәүсәләрендә тора күк
чебиле аяк эзем.
Менмәгән агач башлары
калмады бугай безнең.

Күлмәк җиңнәрен күпертеп,
өстә җил исә иде.
«Тарзан» булып, агачлардан
агачка күчә идек.

Тимәсәк тә ояларга,
күз атмый калмый идек.
Юлда очраган ташларны
кузгатмый калмый идек.

...Акты сулар. Күчә тордык
елларның яңасына.
Их, кайтып аунарга иде
шул таллар арасында!

Иске су тегермәненең
ташлары шомарган шул...
Тупылларга үрмәләргә
без инде соңарган шул.

*1958, апрель*
*Котлы Бөкәш*

## АВЫЛДА КӨЗ

Күңеле көр авылның —
уңышлар мул булды.
Кырларда игеннең
чыгышы зур булды.
Җайга-җай: урманда
чикләвек бик уңды.
Халык та тиенде.
Тиенде тиен дә!
Җылылык һәм муллык
һәркемнең өендә!

Үзгә бер җыйнаклык
бакчада, ындырда.
Күңелдә иркенлек —
хисләргә, моң-җырга.
Шаулап каз өмәсе
үтә өй борынча.
Эштән соң керергә
ягыла ак мунча!

Ак күмәч. Сөтле чәй,
Чикләвек — табында;
Читләрдән кунакка
кайталар авылга.

*1958, август*
*Юлсубино*

## КАПКА

Капка алдында —
курчак кебек
сөйкемле кыз.
Бөртек-бөртек
сипкелле кыз.

Капка иске:
кадаклары
черегән гел.
Такталары —
тимгел-тимгел...

Тубын бәреп
уйный кызый
шул капкада,
сыйпап ала
такталарны.

Белми сабый:
берзаманны,
терәп монда,
кешеләрне
атканнарны...

*1958, август*
*Юлсубино*

## КАЙТУ

Рәхәтләнеп аунадым бер
туган як карларында!
Кулларымны куеп тордым
чишмәнең парларына.

Рәхәтләнеп таптап йөрдем
балачак сукмакларын,
искә төшереп гомеремнең
татлы төштәй чакларын...

*1958, октябрь*
*Юлсубино*

## ИРТӘ

Алсуланып таң атты,
бар дөньяны җанлатты,
чирәмдә — көмеш чыклар...

Җил исте йомшак кына,
тибрәнделәр чак кына
күлдәге төнбоеклар.

*1959, июнь*
*Түләк*

## АВЫЛДА КЫШКЫ ТӨН

Балкый тышта — баганада
электрик фонарь.
Корт күчедәй, шул яктыда
бөтерелә карлар.

Нәни ут — Ай-йолдызларның
барын алыштырган.
Бар дөнья яктысын гүя
берүзенә җыйган!

...Җилләр — чыбыкларны сарган
бәсне коеп тора.
Күгәрченнәр кыекларда
посып, оеп тора.

*1959, ноябрь*
*Туләк*

## ЯЛАНДА КАЕН

Тирбәлә каен,
чайкала каен
җил искән саен.
Ничекләр түзә?
Ачы җил өзә
яфраккаен.

Суыклар алда,
төшкәли кар да, —
кырыс кыш килә!
Сызгырып, улап,
кош-кортка янап,
куркыныч килә...

Нишләр яшь каен,
чайкап башкаен,
һәлак булырмы?
Тузлары тузгып,
иелеп, сынып,
сызып корырмы?

Әллә һаман да,
шып-шыр яланда
җиргә ямь биреп,
горур, нык басып,
куенын ачып
торырмы көлеп?

Юк, үлмәс каен!
Алалмас аны
салкыны кышның.
Ул тоеп яши, —
(шуңа бирешми), —
җирнең сулышын.

Тирбәлә каен,
чайкала каен
җил искән саен.
Түзеп барына,
яшәү хакына
көтә май аен!

*1959, декабрь*
*Котлы Бөкәш*

## БУРАННАН СОҢ КЫШКЫ УРМАНДА

*(Сурәт)*

Кара карга оясы —
ап-ак кар бүрке.

Яшел чыршы ышыгында —
кызыл төлке.

*1960, ноябрь*
*Балык Бистәсе*

## КАНИКУЛГА КАЙТЫР АЛДЫННАН

*Дәүәнигә*

Кайтам тиздән,
Сагындырды йөзең,
сөйләшүең,
            йөрүең,
                ырымың...

Күз алдымда — сының, кыяфәтең,
сәке түрендәге урының.

Утырырбыз бергә. Инде син дә
көткәнсеңдер шәкерт улыңны.

Син бәйләрсең оек. Ә мин каршыңда
уйлап яңа туар җырымны,
сабый чактагы күк, аяк бөкләп,
йомгагыңны тотып торырмын.

*1960, февраль*
*Түләк*

## МИҢА УНСИГЕЗ ЯШЬ

Миңа унсигез яшь!
Мин—давылга тиңдәш.
Беләгемдә — көчем.
Күңелемдә дәрли,
зур эшләргә өнди
тыелгысыз хисем.
Һәр көн — миңа яңа.
Сөенәм һәр таңга.
Яңа хыял туа.
Кояш — миңа көлә,
тузан — биттән үбә,
яңгыр — кайгым юа.
Күкрәк тулы сөю
изге Туган җирне —
шатлык-кайгы татып,
күңелем тулган җирне.
Кояш белән бергә
ташу ерган җирне.
Миңа унсигез яшь!
Мин — диңгезгә сердәш.
Аның ярсу давы
гүя минем давым.
Аның тынмас шавы —
тибеше күк җанның.
Барыр юлым — аклык,
күңелемдә сафлык.
Яшен булып яшьним,
лачын булып яшим.
Гомеремнең язы —
ул унсигез яшем.

*1961, май*
*Балык Бистәсе*

## ОНЫТЫЛМАС БЕР КЫШ БУРАНЫ

Ундүрт яшьме аңа, унбишме икән?
Малаймы ул, әллә егетме?
Дәрестән соң, мәктәп чатында ул
беренче кат бүген кыз үпте!

Кыз кызарды, сулышына кабып,
әй йөгерде өе ягына!
Ә шулай да борылып әйтә алды:
«Буран тынгач, кое янында...»

...Икенче көн инде буран тынмый.
Кызый чыгып күккә карый да
өзгәләнә: «Монда — мәхшәр! Бәлки,
басылгандыр кое янында?..»

Егет каргый буран бабаларын:
«Ник ярсыйсың безнең авылда?!
Минем юлда котыр, сыртлап көрт өй,
тик туктап тор кое янында!..»

Ә буранның туктар исәбе юк.
Котыра гына!..

*1961, ноябрь*
*Казан*

## ТӨШ

Әти белән икәү, имеш,
атынабыз таганда.
Гаҗәп: әти гел түбәндә,
ә мин — өстә һаман да...

Уяндым сабый чак — төштән,
унсигез язым үткән.
Тагандагы урыннарны
алышыр вакыт җиткән.

*1961, декабрь*
*Казан*

# *Яшьлек дәфтәреннән*

*Җыр тулы тынгысыз күңелем*
*яшәргә, яшьнәргә ашкына!*



## ЭРМИТАЖДА ЙӨРИМ...

Иркенәеп,
күк сыярлык сарайларда йөрим,
атлыйм келәм җәйгән идәннән.
Гаҗәпләнеп,
мәрмәр сыннар сынап карап тора:
«Адаштыңмы әллә?» — дигәндәй.

Әй, сез —салкын йөзле таш кешеләр!
Ялгышмыйсыз,
мин — беренче безнең нәселдән.
Нәни йодрык чаклы сабый йөрәк
бабамнарның
теләк-сусауларын яшергән.

Мин кычкырам.
Тавыш җепселләрем корыч кыл күк —
заллар җавап бирә калтырап!

Люстралар —
тир һәм яшьтән койган кояш булып,
юл ачалар миңа ялтырап.
Эрмитажда йөрим җиңүчедәй! —
сынатмыйлар
элек камыл ерган табаннар.
. . . . . . . . . . . . . .
Алар белән,
монда гына түгел, бар дөньяны
урап чыгарга да чамам бар!

...Ышаныч һәм өмет күзе белән
гасырлардан
карап тора кебек бабамнар.

*1962*
*Казан*

## КАРАҢГЫДА БЕРӘҮ КАР КӨРИ

Әле иртә,
әле караңгы,
әле буран шыңшый, тынмаган...
Сыңар куллы берәү урам көри,
таң атканын көтеп тормаган.

Киленнәр дә әле уянмаган,
morжалардан чыкмый төтеннәр.
Саулар мендәрләрдә изриләрдер...
Фронтовикка озын шул төннәр!

«Улы торыр, мәктәбенә китәр,
капка төбе булсын көрәлгән...»
Җил уйнаклый.
Нидер әйткән сыман,
көнбатышка буш җиң төбәлгән.

*1962, июль*
*Балык Бистәсе*

## БАЗАРДА

Шау-шу иле.
Ридикюльләр
кәрзин белән сатулаша лотокларда.

Кәтүк кадәр малай тора.

Бер кулына
капчык бавын кысып тоткан,
берсендә — алма.
Каш астыннан карап ала:
Кешеләр.
                Алма.
Кешеләр.
                Герләр.
Кешеләр.
                Алма...
Аның өчен —
яхшы,
                гүзәл,
                        кызык
                                бар да.

Дөнья әле —
мәңге кортсыз кызыл алма.

*1962, август*
*Балык Бистәсе*

* * *

Киләчәгем хыялымда
кыңгырау чәчәк, имеш.
«Тәүбә! —дидем,— нинди яшәү
башың гел игән килеш».

«Бул абага!—диде хыял,—
кара тиңсез бизәкне!»
Бер тапкыр да чәчәк атмый
яшәү миңа кирәкме?

Әйтте хыял: «Бул төнбоек!
Төнбоекка ни җитә!»
Шул да яшәү буламыни
җил-давыллардан читтә!

Хыял, җитәр! Яшәвемә
үрнәк эзләмә бүтән.
Ничек яратылган булсам —
нәкъ шулай җиргә китәм.

*1962, август*
*Балык Бистәсе*

## ИКЕ КҮПЕР

Яңа күпер,
тимер-бетон, —
җимерелмәс
күк күкрәткән
Алла төшеп
биесә дә!

Яңа күпер.
Ыгы-зыгы.
Машиналар.
Юлаучылар.
Очрашалар.
Күрешәләр.

Ә читтәрәк —
иске күпер.
Мәет илткән
кабыкмыни...
Хәзер аннан
беркем йөрми.

Юк! Ялгышам:
төнлә монда
бер чал чәчле
ана йөри.
Күзенә аның
йокы керми.

«Белми бит ул
яңа күпер
салынганын!
Киткәне күк
моннан кайтыр
минем балам...»

Ничәнче ел
ялгыз ана
сугыш кырын
кабер иткән
улын шулай
каршы ала...

*1962, сентябрь*
*Балык Бистәсе*

## КОШЛАРГА

Бездә кыш. Җир-сулар
капланды ак карга.
Әй, кошлар, сезнең хәл
ничек ул якларда?

Җылы як илләре
торганнармы күтеп,
безнең күк сөенеп,
оялар беркетеп?

Бездәге кебекме
ул җирнең таңнары?
Исләргә төшәме
туган як таллары?

Кайчакта шундый уй
шом сала күңелгә:
кошкайлар, сез анда
кадерсез түгелме?

Талчыккан канатка
сыеныр җир бармы?
Очарга — тыныч күк,
ашарга — җим бармы?

Картадан карыйбыз
сез киткән якларга.
Бар анда дуслар да,
бар анда ятлар да.

...Бездә кыш. Туңмыйбыз.
Уйныйбыз. Күңелле.
Кошкайлар, сезгә анда
күңелсез түгелме?

*1962, сентябрь*
*Казан*

## ДИҢГЕЗ ТАШЛАРЫ ТҮШӘЛГӘН ЮЛГА...

Үтәләр шиннар, табаннар...
йөзләренә баса-баса!

Җил чыкса, болыт кузгалса,
тузанланган, коргаксыган
чуерташлар пышылдаша
шыгырдаша-шыгырдаша!..
Күзләре ялтырап китеп,
яшьләнәләр, яңгыр яуса!
Һәрбер тамчы — дулкыннарның
сәламе бит — болыт аша!

Их, яңадан туфан басса!

*1962, ноябрь*
*Казан*

## ӨНДӘ

Үтерешләр фәне яши дөньяда,
үтерешләр фәне.
Трибуналардан сөйләмиләр:
үбәргә яралган иреннәр
ул турыда сөйли алмый.
Манифестлар белән чыкмыйлар:
икмәк тотучы бармаклар
ул турыда яза алмый...

Үтерешләр фәне яши дөньяда.
Методлары һаман камилләшә:
асу — Кеше + элмәк = үлем,
ату — Кеше + ядрә = үлем,
куыру — Кеше + ток = үлем,
ыслау — Кеше + газ = үлем...

*1962, ноябрь*
*Казан*

* * *

Галәм кораблары ясаган затларга,
шаккатып һәм горурланып:
«Нинди акыл! Нинди көч!» — диям.

Нәни балаларга
очыргыч шар ясаганнарга,
бер сүз әйтми генә,
баш иям.

*1962*
*Казан*

## КАДАК

*Инглиз халык иҗатыннан*

С. Маршак буенча

Тимерчелектә
кадак булмады:
дага югалды.

Юлның тайгагы —
дагасыз атның
сынды аягы.

Ат баралмады.
Командир ауды —
нык яраланды.

Командир үлгәч,
солдатлар качты.
Дошман ут ачты.

Гаскәр җиңелде.
Күп халык үлде.
Шәһәр — көл килде!..

Никадәр каза,
һәлакәт чыккан —
бер кадак юктан!

*1962, ноябрь*
*Казан*

# ПРУЖИНА

Пружина!
Бишектәге
сабыйларны
юатасың;
аларга син —
кызык гармун.

Син чәчкечтә
зыңгылдыйсың,
пышылдыйсың
орлыкларга
туфракта да
тормыш барын.

Будильникта —
пружина
укучыны
мәктәбенә
уятырга
әзер тора.

...Әнә бала,
көлә-көлә,
пружиналы
машинасын
«кабызырга»
ачкыч бора.

Пружина!
Ышанасы
килми минем
ятуыңа...
үлем-мылтык
затворында.

*1962, ноябрь*
*Казан*

* * *

Үзенә үзе кул салган шул,
үз сулышын үзе кискән,
кыскасы —
ул туйган,
киткән...

Кешеләр аптырашкан:
пышылдашалар, йөренәләр.
Йөзләрендә курку катыш сәерсенү,
ахры, җирәнәләр дә...

Үзе теләп килмәгән ул.
Килүе кирәк булганмы?
Бәлки, юктыр!

.........................................

Бәлки, начарлыгы да тимәгәндер дөньяга,
киресенчә,
бәлки, игелекле эшләр калдыргандыр...

Кешеләр аптырашкан,
кешеләр риза түгел:
йөренәләр,
пышылдашалар...

*1962, ноябрь*
*Казан*

## АВЫЛ КАРТЫ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

— Кояш турында язганга да түлиләр диң, ә?
Күк турында,
җил турында язганга да...
Шулай да, энем, бушка яз син җырларыңны!

.........................................

— Ирек һәм көрәш җырлары
бушка язылмыйлар шул!
Шагыйрьләр еш кына
үзләре түлиләр бик кыйбат!..
Кайчак гомерләре белән...
Байрон,
Җәлил,
Лоркалар кебек...

*1962, декабрь*
*Казан*

* * *

Кар бөртеге кунды тәрәзәмә.
Табигатьнең бер бәләкәй могҗизасы.
Гөнаһсыз,
          чиста,
                    ап-ак!

Безнең өчен хәтта
артык пакь...

Тәрәз аны сыендырды,
яңагында тотты һәм...
                              эретте.

...Әй, кыз бала!
Мөлдерәмә күзләрең синең!
Нарасый бер сафлыгың белән
тартыласың минем яныма.

Рәнҗерсең күк,
әлеге шул кар-бизәк күк,
синнән берни калмый,
тәмам эреп бетсәң җанымда.

*1963, гыйнвар*
*Казан*

## МАРТ АХЫРЫ

Яна Кояш!
Соңлап яуган карлар
Эри-эри ялмый күз явын!

Очкан кошлар күләгәсе буйлап
нәни гөрләвекләр кузгалды...

*1963, март*
*Казан*

## ЮЛСУБИНО

Кайсы йолдыз билгеләгәндер? —
Язмыш атлы минем казык
шушы җирнең шушы төшендә!

Яшәү дәверемдә бәйле аңа
Гомер дигән нечкә җеп белән.

*1963, март*
*Казан*

## ТӨШТӘ

Әни!

Тираннарны күрдем.
Кесәләре тулы — кеше күзе!..

Әрдәнәләп куллар өелгән.
Аның күләгәсенә килеп,
аяк бөкләп утырдылар алар.
(Берсенең кесәсеннән берничә күз җиргә тәгәрәде...)

Шәраб итеп
кан эчтеләр.

Мин курыктым, әни!

Аннан алар сөйләштеләр.
Чын кешечә сөйләштеләр, әни!
Тыңлау куркынычрак иде, әни!
Сүзләрен ишетү
авыррак иде!

Тираннарны күрдем.
Кесәләре тулы — кеше күзе...

Мин саташам.
Әни, уят тизрәк!
Уят та
тынлык төбенә яшер син мине!

P.S. *Еллар үткәч, уйлап куйдым: бәлки, бу — төш түгел, ә чынлыкның үзе булгандыр? Сугыш афәтләрен, фашизм мәхшәрләрен күргән өлкән буыннарның безнең геннардагы хәтередер?..*

*1963, март*
*Казан*

* * *

Өченче көн дә инандым.
Кичә дә инандым.
Бүген дә...

Бүгенге ышаныч
кичәгеңә тәңгәл түгел,
кичәгесе —
элгәргесеннән
                    бераз үзгә...

Димәк, без көн дә
әзме-күпме ялгышабыз!

*1963, март*
*Казан*

## МИРАС

*(Авыл хатирәсе)*

Шәйхи бабай улаклаган
бу чишмәдә —
Аның тавышы.

Өй алдында
ап-ак каен —
Гайниҗамал әби төсе.

*1963, май*
*Казан*

## АЧЫК ТӘРӘЗӘЛЕ ЯЗ КӨНЕ

Җилфер-җилфер язгы җил искәндә,
болыт булып очып китәр сыман
туй күлмәге кебек ак пәрдә!

Зәңгәр күктә — Кояш тәхетендә
минем күзләр өчен пәйда булыр
фәрештәдәй
сылу
сын-гәүдәң...

*1963, июнь*
*Казан*

* * *

Аста — дулкын, өстә — Кояш!
Идел буе чирәмлек!
Авыл шаулап туй үткәрә,
Гөрли бөтен тирәлек!

Халык уйный, халык җырлый,
халык бии яр тулып!
Яшь киленнең ак күлмәге
үрли ак ялкын булып!

Авыл рәхәттән исерек.
Туктармы туй өч көндә?
...Көймәгә капланып елый
бер кыз Идел өстендә.

*1963, июль*
*Казан*

## ПАРОМ ЧЫККАН ЧАКТА КИЛГӘН

Пароходлар буйлый Иделләрне,
буйлап йөри баржа-саллар да...
Паром исә аркылыга йөзә,
күпер булып каршы ярларга.

Фарватерын үтә, чоңгылын да,
кавыштыру гаме — моторда.
...Авыр йөктәй күпме гамь-исәп бар
без чыгарган шигырь, көй-җырда!

Заманасы хәзер шундый. Бара —
якынаюлары илләрнең.
Хакыйкатькә шагыйрь туры керә —
карап тормый:
саймы-тирәнме...

*1963, август*
*Казан*

* * *

Мин нур атам
кешеләрнең күңеленә!

Ә ник, каян
кадала еш
күкрәгемә
кара уклар?

Ә сез миңа авыр дисезме?

Күкрәгемнән укны суырам да,
бөекләрне уйлап рухланам да
ак кәгазьгә
утлы шигырь язам!

Нурлар яуса —
тоташ нурдан язам
җырымны!

*1963, август*
*Балык Бистәсе*

## ЯР КАРЛЫГАЧЫ

Оясыннан —
пуля кебек
атылды яр карлыгачы.
Әй уйнаклады Кама өстендә
канатлары талчыкканчы:
        әле түбән төште,
        әле биек менде,
        күзгеләрдә уйнаклаган
        нурлар сыман бөтерелде!

Пароходтан —
        соклandылар:
— Әй, карачы,
яр карлыгачы!
— Нинди җитез!
— Гәүдәсе — ук,
киерелгән җәямени канатлары!

Пассажирлар
күмелгәнче күзәттеләр.
Күзләр соклandылар,
какмыйча да кабакларын,
ә иреннәр сүзләр белән
соклануны кабатлады.

Хәзер төн.
Пароход инде Чистайдадыр,
        бәлки, арырак та...
Пассажирлар күптән оныттылар
ерακта
текә яр барын,
аның күкрәгенә ядрә булып кергән
            карлыгачларын...

Тик Ай гына
Кама ярына
кул яссуы кадәр якты куйган
сабый кулы гына сыярлык
карлыгачның оя алдына...

*1963, 22 август*
*Балык Бистәсе*

## ҖИЛ — ВАКЫТ УЛ...

Жилләр шатлык алып киләләр.
Җилләр картлык алып киләләр.
Җилләр диннәр алып киләләр.
Җилләр чирләр алып киләләр...
Җилләр алар шундый: теләсәләр —
әллә ниләр алып киләләр!

Җил — Вакыт ул, белми тынычлык!
Җил тамырын кисәр кылыч юк!

*1963, октябрь*
*Казан*

## КАР ЯВА

Кар ява.
Кар ява.
Сафлыкка күмелә,
аклыкка төренә,
пакьлеккә тиенә Җир-ана.

Кар ява.
Иң соңгы кышына кергән карт
уңарган күзләрен текәгән урамга.
Уйлана:
«Җир кәфен урана.
Җир кәфен урана...»

Кар ява.
Шул ук урамда.
Гыйшыктан исергән яшь егет, —
(әйтерсең күк-капу ачылган!) —
сөенә:

«Кешеләр, күрегез!
Кешеләр, күрегез!
Ап-актан
Җир туйга киенә,
Җир туйга киенә!»

Кар ява.
Тәрәзә янында яшь ана.
Кызчыгы — алдында.
— Әнием, ак карда эз ясап карыйм!
Ярыймы?

— Бар, кызым...

Кар ява.
Ашыкмыйм дигәндәй,
мәңгегә килгәндәй,
Дөньяга битараф
ябалак кар ява...

*1963, ноябрь*
*Казан*

* * *

Беренче кат кайчан көлдем мин?
Белмим.
Әнием белә.

Беренче кат кайчан еладым мин?
Белмим.
Әнием белә.

Тәүге адымым — кайсы аяктан?
Белмим.
Әнием белә.

Кайсы секундта йоклап китәм мин?
Белмим.
Әнием белә.

Ярылырмы бомба баш түбәмдә?
Белмим.
Әнием дә белми.
Кем белә?
Әйтегез сез аңа!
Әйтегез...

*1963, декабрь*
*Балык Бистәсе*

## БАЛЫКЧЫ КАРТ

Иске көймә.
Беткән көймә.

Җил-яңгырдан
типчелгән күп;
кычкырсаң да
таралыр күк.

Балыкчы карт
һаман ярда.
Йөзе — сөяк,
ә куллары
тамыр гына...

Сумаладай
эрер булып
карап тора
көймәсенең
ярыгына.
«Төзәтсәң, — ди, —
ару гына...»

Ышана әле
җилкән киереп
ерак ярга
барырына.

*1963*
*Казан*

## МЕТАМОРФОЗА

Сарайда ята
колун балта.
Түтәсе иңгән —
күп сугудан,
йөзе тонган —
тутыгудан.
Бер үрмәкүч узган
җебен суза-суза
тупас йөздән — чормадагы балавызга...

Бар иде колунның ялтыраган чагы, —
йөзәр яшьлек имәннәрнең калтыраган чагы!

Ә хәзер...
тумранны ваткан,
таш-сөякне чапкан
дәһшәт балта
йокымсырап, изрәп ята.

Пәрәвезне,
ичмасам,
берәр чебен очып өзмәсме дип,
җан юата.

*1963*
*Казан*

* * *

Үз көенә аксын.
Чагылдырсын күз яшь
кешеләрне, Кояш нурын.
Биттә кипсә дә, җиргә тамса да
барыбер бит синең чистаруың.

Көлү әйбәт. Ул рух өсти. Әмма
көлүләрнең төре, йөзе күп.
Күз яшенең мәгънәсе анык, —
кырыс хакыйкатьнең үзе күк.

*1963*
*Казан*

* * *

«Давылның күзендә очармын!»
Юана
салынкы канатлы карт бөркет.

Шагыйрь: «Җырларымның иң гүзәл
иртәгәсе җырым, — күңелем, көт!»
Юк! Мин көтмим абагадан чәчәк,
иямәнеп барам чынлыкка.
Миңа хәзер җыр язарга кирәк,
гомерем минем — янар комета!

*1963*
*Казан*

## ЯҢГЫР

Яңгыр!
Коргаксыган Җиргә тизрәк төш!
Тизрәк...

Әнә кырда
чалкан яткан тырма,
тимер бармакларын сузып,
тели каршы алырга!

«Тырма нәрсә?!
Миңа гөлләр ялварсыннар!»

Керфекләрен йомып иелгәннәр алар —
назлылыктан түгел —
борылып сиңа
карарга да хәлләре юк...

«Кеше дә сорасын!»

Әнә күр!
Кеше,
маңгай тузанын сөртеп,
күктә карашын йөгертеп
пышылдады:
«Иген корый...
Яңгыр!
Яңгыр! Бер тамызлык кына!»

Менә күктә
күптән көткән
өмет йомгагы — болыт!
Болыт!!!

Әй,
кошлар очты түбәнтеннән,
биешеп торган сыек рәшә
юкка чыкты тотенләп,
көтүченең чыбыркысы
үләннәргә сөенеч салып,
шуышты җир өстеннән.

Болыт
күл өстенә килеп
койды орып,
койды оеп...

Кырда
эсселектән кызган тимер тырма,
күккә табынып,
кулларын сузып калды.
Гөлләр ауды.
Ә Кеше
дәшмәде,
яңгыр булып Җиргә
тире тамды...

*1963*
*Казан*

## КҮПЕРДӘ

Күпер әзер.
Өрлекләрдә кадак башлары
береккәннәр мәңгелеккә,
текәлгәннәр күккә...

Балта остасы: «Шөкер!» — диде.
Коралларын иңенә алды.
Әле җәйгән такталарга
соң мәртәбә
горур гына караш салды:
клавишалармыни!

Ә кем керер
иң беренче бу күпергә?
Ашлык тулы машинамы?
Кырда эшләүче әтисенә
сөт илтүче бер малаймы?
Алма тулы атлы арбамы?..
Ни булса да,
иң элгәре, —
шатлык керсен,
сөенеч керсен...

...Кинәт кенә әллә кайдан,
чапкынны да узар булып,
гарип бер ир килеп чыкты.
Ул күпердән атлаганда
әллә оста,
әллә такта,
әллә протез сулкылдады...
«Хәбәр алдым больницадан!
Малай туган!
Малай туган!»

Оста калды.
Тартты.
Янә кулына
балта алды.
Тезе белән
тагын бер кат йөреп чыкты
такталарны...
Тигез булсын!

*1964, февраль*
*Казан*

* * *

Мич тулып шигырьләр яна.
Өмет яна,
            акыл,
                    хыял,
йокысыз төннәр,
            гомер яна...

Яна.
Яна җырлар,
            поэмалар...

Дәрт — ялкын-тел!
Хис — үкерә, үкси!
Фикер — чарт-чорт!

Мич хәзер күтәрелә!
Динамиттай шартлый —
читкәрәк китегез!
Бер!
Ике!..
. . . . . . . . . . . . . . .

Юк!
Кирпечләр бик таза,
ян-яннар нык...

Җәйрәп сүзләр яна.
Кемнәрнедер юатыр сүзләр,
кемнәрнеңдер
йөзләренә атар сүзләр,
учка салгач,
пешерер сүзләр,
тере сүзләр...

Ут гөнаһсыз,
ут эчкерсез.
Бирдең, — ялмый.

Ник ягаммы?
Җылысы бар! —
риялы җаннар,
астыртыннар,
ым-шым аулап
йөргәннәргә
җавабым шул!
Үзләре
янганнар
аңларлар...

Яна.
Яна.
Балладалар — кап-кайнар көл.
Касыйдәләр — көл.
Газәлләр — көл...
Табигатьнең туры законы:
бардан юк булмый,
юктан — бар...

Бары күчеш —
бер халәттән икенчегә...

Юкны бар диюче
мескеннәр жәл!
Барны юк диюче
бәндәләр жәл!
Һәрчак ялкын дөньяда.
Мәйданнарда кретиннар
өеп-өеп китап яга.
Парламентлар каршысында фидакярләр
бензин сибеп үзен яга.
Хаклык өчен...

Утка нәрсә?
Эше — яну, яну.
Ялкын бер үк,
ә мәгънәсе...

Мич тулып шигырьләр яна.
Күгем яна,
йолдызларым,
Аем яна...

Яну-ягу — шагыйрьләр эше.
Вак җаннарга кая!
Теләсә кемгә
тәтемәгән
яну бәхете!

...Кулларым яна,
иреннәрем,
бәбәкләрем...
Карындагы бала кебек
бөкрәеп, мин янам.
Янсын!

*1964, февраль*
*Казан*

* * *

Соңгы аваз, карлыгач кебек,
киңлеккә күтәрелмәс.
Урманнар айкап йөрмәс.
Кояшка сәлам илтергә
Җиде кат күккә менмәс...

Ботактагы соңгы алмадай,
ычкыныр да иреннән,
тәгәрәп кире кайтыр ул
күтәрелгән җиренә.

*1964, 19 март*
*Казан*

* * *

Ай — вакланган дулкыннарда,
ватылган бәхет сыман...
Ә синең тын күзләреңә
Ай тулы килеш сыйган.

Йөзә ул киң диңгездәге
ялгыз ак җилкән кебек, —
керфекләрең офыгына
бер кереп китәр кебек.

Аннан кабат чыгар төсле
Чисталык диңгезенә.
Якынлашыр да Ай-җилкән
мине дә алыр менә...

*1964, март*
*Казан*

## МИНЕМ ӘТИ

Философ булмаган әти.
Ә минем кирәкне белеп,
өйләнгән минем әти.

Галим дә булмаган әти.
Ә миңа җылы кирәккәч,
мичләр салуның рәтен
өйрәнгән минем әти.

Җырчы да булмаган әти.
Ә миңа бишек силәсен
зыңлап торганын ясарга
өйрәнгән минем әти.

Рәссам да булмаган әти.
Ә миңа салават күперен
чыкта да күрә белергә
өйрәтте мине әти.

Шагыйрь дә булмаган әти.
Ә мине көйгә кертергә
бер-ике йомры сүзне
өйрәнгән минем әти!

Герой да булмаган әти.
Ә сугышта алган җөен
хәтта миңа күрсәтмәскә
өйрәнгән минем әти!

Син Алла да түгел, әти,
фәрештә дә түгел, әти.
Син бары әти, Әти!

*1964, апрель*
*Казан*

* * *

Фикер килде миңа... —
гадәтемчә,
мин куанып каршыладым.

Ул башта елмайды,
күңелемә елышып
риясыз иркәләнде.

Мин дәшмәгәч,
күзен тутырып,
озак карап торды миңа,
аннан — чишенде...
«Соклан!» — диде.

Мин дәшмәгәч,
ул оялып башын иде,
аннан юхаланып юмалады:
«Кочагыңа атылырга торган
даның миндә синең!»

Мин дәшмәгәч, ул ялварды:
«Агачлардан кәгазь көтеп күпме,
рудалардан каләм көтеп күпме,
инде сиңа килдем.
Өметләнеп,
нык ышанып килдем,
аңла!»

Мин дәшмәгәч,
ул янады:
«Тынгы бирмәм сиңа,
һәрчак сагалармын:
үбешкәндә иренеңә килеп кымырҗырмын,
чабынганда ләүкәңдә торырмын,
йоклаганда саташтырып уятырмын...»

Мин дәшмәгәч,
мәэюс карап,
тагын бер кат пышылдады:
«Мин монда әле...»

Фикер килде миңа.
Ә мин кудым аны.

Кешелексез иде
ул фикер...

*1964, апрель*
*Казан*

## ЯШЬ ХАТЫН

Толымын тешләп,
сулкылдап елады,
елады...
Дымлы керфек арасыннан
ап-ак мамык мендәрдәге
ике баш эзен күреп,
дөньядагы
барлык парлы әйберләрне каргады:
үз толымнарын,
машина фараларын,
туфляларны,
ишек яңакларын,
кулына тоткан
кайчыларга кадәр каргады ул...

Ә кич белән
судан кайтканда,
парлы чиләкләрне иңендә тоеп,
кинәт бөтен тәне белән дерелдәп сөенде ул!
Парлы әйберләргә
каргышы исенә төшкәч:
«Тәүбә! Тәүбә!» — диде.

*1964, апрель*
*Казан*

## САБЫЙ САНАРГА ӨЙРӘНӘ

Бармакларын бөгә-бөгә,
иреннәрен бөрә-бөрә
сабый саный.
Бер...
Мин — берәү,
Кояш — берәү.

Ике...

Әти, әни — икәү,
күзләр,
куллар — икәү.

Өч...

Санарга мине
әни өйрәтте.
Мин дә бердән башладым.
Башта бармакларны,
салават күпере төсләрен санадым,
аннан —
көннәрне, чакрымнарны...

Хәзер инде саннар дөньясында мин:
кабинетта да,
урамда да,
поездда да...

Саннар!
Уңда — саннар!
Сулда — саннар!
Адымымны үлчи саннар,
Кан басымын үлчи саннар,
хисләремне үлчи саннар...
Саннар!
Кечкенәләр.
Зурлар...
(Зур саннарны әни миңа, йолдызлар санар
өчен кирәк, диде.)

Нульләр!
Баланслар!
Саннар!
Саннар!
Кирәклеләр,
Кирәксезләр...

Төн.
Мин язам.
Бүлмәдә беркем юк.
Тик нидер комачаулый.
Әнә счетчик
тек! тек! энергия чутлый почмакта
Кычкырасым килә:
«Тукта!
Кешелек яшен оныткан!
Аңлыйсыңмы, кешелек яшен оныткан!
Ә син...»
Бармакларын бөгә-бөгә,
иреннәрен бөрә-бөрә
сабый саный.

Бер...

Мин — берәү,
Кояш — берәү.

Ике...

Әти, әни — икәү,
күзләр,
куллар — икәү.

Өч...

Ул санарга өйрәнә.

Сугыш кырындагы үлекләрне түгел,
күктән үзе кояр
йолдызларны санар өчен
өйрәнә ул!

*1964, май*
*Казан*

## КОЯШКА АТЫЛГАН ЯДРӘГӘ

Өскә атылдың —
                    Кояшка таба,
яралы кош — аска.
Көчле димсең?
Юк!
Бездә көчлеләр
Кояшка таба
беренче бара.
Кош беренче иде,
син арттарак...

Кош
хәлсез канатлары белән
болытларны сыйпап,
Кояштан аерылмыйча,
озак талпынды күктә,
аннан — җиргә...
Хәзер әнә
Кояш алдында
чалкан ятып җан бирә.

Ә син, ядрә,
күктән тизрәк төшеп,
күптән постың
үләннәр итәге астына.
Гаҗәп!
Сине әле дә
көчле диюче кешеләр күп.

*1964, май*
*Казан*

* * *

Кулларымны өскә куеп
йолдызлар күрсәттемме,
ут ачарга боердыммы,
ура! кычкырдыммы...
мин аларны
барыбер төшерәм.

Аска төшерәм дә,
Куллар белән Җиргә кереп,
нигез корам,
канау ерам...
туфрактан тарих эзләп
актарынам...

Җирдә эш күп.
О, ничек күп!
Куллар гына сау булсын тик,
куллар гына...

Мин биеклекне яратам.
Чирәмнән алып
йолдызга чаклы!

Хәтта ары да...
Ә кулларым —
әллә тыйнакларммы уема караганда? —
иңбашыннан асылынып,
һаман аска —
Җиргә караганнар...

*1964, май*
*Казан*

* * *

«Аһ, кулларың, дидең, нинди кайнар!»
Чынында алар
неон кебек хиссез, җансыз иде.

«Син шат, елмаясың», — дидең.
Ә мин бу мәл
күптән булган чын көлүнең
тик төсмерен искә төшердем.

Ярый,
сау бул!
Бәхетле бул!
Киттем...
Мәхәббәткә Җир шар түгел, —
Магеллан кук бу ноктага
бүтән кайтмам.

Кузгалганда, соңгы тапкыр
сиңа түгел,
Кабанга карадым мин.

Тойдым,
сиздем,
күзләрең ялварды,
соңгы кат карачы миңа, дип,
иреннәр — миңа, дип!
иңнәрең — миңа, дип!..

Кабанга карадым мин.
Күзләреңнән артыграк
аңа ышандым.
Казанның моңлы бер күзе
күбрәк аңлар кебек иде...

Мин синнән киттем.
Таң белән
төн булып киттем мин синнән.

Иртәләрен
Кабанга карасаң,
пар түгел,
аннан
минем сагыш күтәрелер...

*1964, июль*
*Казан*

## ШАГЫЙРЬ ӨЧЕН ТИРАН НӘРСӘ УЛ!

«Сез күрәсез мине,
мин сезне —
юк!»
Син
Фучик, Җәлилләрне
тар өнлекле камерага япкач,
шулай дидең, палач.

«Син күрәсең мине,
мин сине —
юк!»

Чәчәкләргә басып
син Кояшка
шулай кычкырдың.

Әйе,
син күрмәдең аны,
бүтән эшләр белән мәшгуль идең:
җырны үтерер өчен
кораллар ясадың,
төрмәләр төзедең,
лагерьлар кордың...

Ә җыр сыймады!
Бу вакытта ул
йодрык эчендә,
күзләрдә иде.

«Сез күрәсез мине,
мин сезне —
юк!»

Син
Алиш, Җәлилләрне
тар өнлекле камерага япкач,
шулай дидең, палач.

Тик ялгыштың,
синнән битәр
туган халкын,
хатыннарын,
Чулпаннарын күрде алар.
Кисәкләп булса да
Кояшны күрделәр,
ә нурларын күңелгә ялгап,
җыр яздылар.
Үлмәс җыр!

«Сез күрәсез мине,
мин сезне —
          юк!»
Шагыйрьләргә
шулай дидең, палач.

Бүген менә
мин Кояшны күрәм,
Җәлилләрне күрәм,
ә сине —
               юк!

*1964, август*
*Казан*

* * *

Кер чайкыйлар кызлар.
Тезләрендә — Кояш!

Уйларны да, керләр кебек,
ак иткәнче, пакь иткәнче,
ах, чайкарга иде!

Сагышларны ике куллап,
кысып-кысып, кысып-кысып
сыгарга иде!

Шатлыкларны иң өстенә
сыйган кадәр, сыйган кадәр
өяргә иде!

Чын җырларны, — җилфердәргә
биеккәрәк, биеккәрәк
эләргә иде!

Кер чайкыйлар кызлар.
Тезләрендә — Кояш!
Күзләрендә — Яз!
Ярым ачык күкрәкләре
оялган күк бераз...

*1964, сентябрь*
*Казан*

## САМОЛЕТТА. БИЕКЛЕК — 8000 м.

Креслога чумган
нәфис, сылу ханым
мөлаем елмая.

...Иртәгә аның
Аерылышу гаризасы
Судта каралачак.

Нурларга манчылган
очкалак болытлар!

Пассажирлар
яшь егетнең җорлыгыннан көнләшәләр.

...Кесәсендә аның повесткасы,
берсекөнгә — полигонга.

Болытлар, —
хыяллар күк, — нинди пакьләр!

Елмаюына төреп,
стюардесса
конфетлар тарата.

...Саргылт чәчле Роберт
аэродромда аны
бүтән мәңге каршы алмас...

Болытлар!
Болытлар!
Гөнаһсыз җиңеллек!
Ә аста —
орып яңгыр ява...

*1964, декабрь*
*Казан*

## ЙОМАРЛАМ КАР

Хәтереңдәме?
Күптән инде —
дөнья безгә гел гөл чакта,
син шаяртып,
күзләреңне кыса төшеп,
миңа төбәп,
бер йомарлам җепшек кар аттың.

Ә мин тотып алдым...
Оныткансың!
Мин дә оныткан идем.
Менә бүген бер яшь парны күреп,
исемә төшердем.
Исәрләнеп кинәт,
шашкын хис белән,
учымны ачтым.
Хыялдагы шул йомарламны
кабат тоясым килде,
тотарга дип, җилгә каршы
кулны куясым килде.
Синең шаяруың сыйган,
минем тартынуым сыйган,
икебезнең яшьлеге сыйган
әлеге кардан
тамырларымны чеметтерәсем килде.
Уч төбе сызыгында
балачагымны
тагын бер кабат
эретәсем килде!

Хәзер кайда ул кар?
Эзлим мин аны!
Телә генә син!
Табам мин аны!
Телә генә син!

Чыкка әверелсә, —
үләннәрне сыйпап, барлармын,
җиргә сеңсә, —
чишмәләрне татып карармын,
яшькә әйләнсә, —
кешеләрнең йөзенә багармын...
Барыбер табармын!
Табармын!

Хәтереңдәме!
Без еш кына
яшәү-яшәмәү турында сөйләшә идек.
Хәзер инде
ышандым шуңа,
инандым шуңа:
дөньяда
бер йомарлам карны
искә төшереп, хисләнер өчен дә
яшәргә була.

*1964*
*Казан*

* * *

Чын дуслар очратып танышсам,
кемгәдер дөрес юл табышсам,
кемдәдер шат очкын кабызсам, —
яктырып,
нурланып,
очынып,
шигырьләр язаргаябышам.

Юлымнан барганда ялгышсам,
ауганда, дошманга ябышсам,
сагыштан чирләргә сабышсам,
хисемне яшемә чылатып,
шигырьләр язарга ябышам.

Ул иң бәхетле дип уйла син,
йә иң бәхетсез дип уйла син, —
әгәр дә төннәрен уянып,
шигырьләр язарга ябышсам.

*1964*
*Казан*

## ХӘРЕФЛӘР

Мин нәкъ сабый,
Аерма шул:
ул кубиклар тезә,
мин — хәрефләр,
ул мүкәләп тезә,
мин — утырып,
басып,
капланып,
чалкан ятып,
елап,
шашып...

Шагыйрь булу кыен түгел:
хәрефләрне җыясың да,
алардан сүзләр ясап,
берәм-берәм тезеп чыгасың.

Болай тезсәң, йөз дустың арта,
болай тезсәң, йөз дошманың!
Хәрефләр беркатлы алар,
алдалыйсың икән —
алданалар.

Тыңлаучаннар:
теләсәң ни куш!
Ышанучан алар:

һәр каләмгә менәр, һәр кәгазьгә төшәр.
Зәгыйфь алар, көчсез, каршылыксыз...

Дөньяда минем курыкканым —
алар рәнҗүе.

*1964*
*Казан*

* * *

Кояш!
Күземә үк төштең.
Рәхмәт!
Сиңа да,
керфек очындагы тамчыга да.

Сөйләшик.
Сөйләп җибәр Җир турында,
илләр турында:
Азиядә ни хәлләр бар?
Көнчыгышта?
Көнбатышта?

Сиңа мин күбрәк ышанам:
син барсына шаһит,
сиңа барсы мәгълүм.
Дәшмисең?

Юк, курыкма!
Бу сиңа төбәлгән пушкалар түгел,
керфекләр бу...

Каушама!
Атом сынамыйлар миндә,
дерелдәп китү ул —
күз кабакларының кыймылдавы...

Сөйлә, Кояш!
Бүтән илләрдә
минем кебек егерме яшьлекләр
ни уйлыйлар?
Кырыкка җиткәч нишләмәкчеләр?
Алтмышта?..

Юынганда,
уйланып,
борчылып,
керфек очындагы Кояш белән
озак сөйләшәм шулай.

Юынганда,
янымдагы җиде яшьлек малайның да
керфегендә тамчы була,
ә тамчыда Кояш була.
Ә ул шаян
Кояш белән сөйләшеп тә тормый!
Поши кебек башын селкүгә,
Кояш,
диск кебек, оча җиргә!
Малай үзе көлә.
Ә Кояшны миннән ким яратмый ул!

*1964*
*Казан*

## ЭМИГРАНТ

Туган илдә сагыш,
көзге яфрак кебек,
сары төстә генә...
Ә монда сагышның
зәңгәре,
        аклары,
                аллары...

Чиста күк йөзе,
кар,
роза,
балачактагыча
        зәңгәр генә түгел,
        ап-ак кына түгел,
        алсу гына түгел...

Хәзер аларда
яңа төсмерләр —
сагыш төсмере.

Туган илдә кайгы,
көзге төннәр кебек,
кара төстә генә.

Ә монда...
аякларым баскан
соры урам ташларында,
бармакларым орынган
яшел йөзем тәлгәшендә,
иреннәрем тигән
кызгылт шәраб тамчыларында
һәммәсендә кайгы төсләре...

Төсләр!
Күзләрем тәүге күргәннән соң
сез ничаклы үзгәрдегез!

Күз яшьләрем генә,
билгесезлек кебек,
һаман төссез,
            төссез...

*1964*
*Казан*

## БУХЕНВАЛЬД КҮГЕ

Бухенвальд күгендә дә,
бездәгедәй,
җитен чәчәге төсе.
Тик яшь аша ул,
әйтерсең, төрмә җәймәсе.

Бухенвальд күгендә дә,
бездәгедәй,
тузганак болытлар.

Тик монда
(яңгырга күз яше кушылгач!)
Җир күбрәк чылана.

Төннәрен
Бухенвальд күгендә,
бездәгедәй, йолдызлар, йолдызлар...
Тик монда,
«убыр» булып,
фосфорлы сөякләр туфракта җемелди.

Бухенвальд күгендә дә,
бездәгедәй, салават күпере.
Тик монда —
крематория өстендә
күктәге кызыл төс җетерәк шикелле...

Бухенвальдта — күк гөмбәзе астында,
бездәгедәй, үбешәләр.
Баскан туфрак та бездәгечә:
монда да
бодай үсә, үлән үсә, чәчәк үсә...
Чөнки бит Җир
хатын-кыз күк:
яраларын күрсәтергә бик яратмый.

Ә күк үзе
Бухенвальд өстендә
ирләр күңеле кебек шыр ачык...

*1964*
*Казан*

* * *

Әй, җәйге төн!
Әй, нечкә төн!
Монашкадай
чем-кара төн!

Чишендереп төнне
аҗаганнар уйный.
Аһ, уңайсыз...
Аҗаганнар уйный.
Аһ...

Кышкы төн.
Тулы төн.
Юан төн.
Бер аҗаган юк...

*1964*
*Казан*

## ЯШЬЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН МОҢСУ ЮЛЛАР

Кайда ул Мәхәббәт Гөле?
Күңелдә шыткан иде!
Икәүләп саклый алмагач,
юкка да чыккан инде...

Син дә инде бәргәләнмә,
көндез шәмнәр кабызып.
Мин дә күним. Икебезгә дә
тигән өлеш — ялгызлык.

*1964*
*Казан*

## ПРИСТАНЬ

Сине кайберәүләр күралмыйлар,
имеш,
аерылуның башы шуңардан...
Ә мин сине юри якын итәм,
үч алырга теләп шулардан.

Без бит тынгысызлар —
                                син дә, мин дә:
гел яңаны эзләп дөньядан
унбиш яшьтән өйдән качып киттем,
син туганнан бирле — чит ярда.

Мине дөнья җиле сөя,
сине —
гашыйк дулкыннарың иркәли...
Каксалар да безне — назлау дибез,
чөнки без
белмибез үпкәли.

Тик шулай да синнән көнләшәм мин
тормыш сиңа серен күп чишә:
аерылышу-кавышу —
                                бер поэма
пароходлар кабат килдисә.

Ах, кызганыч!
Китәсең син көзен
күпме сереӊ төяп затонга.
Ә мин һаман Язмыш көтеп йөрим
бер кечкенә җырым хакына.

*1964*
*Балык Бистәсе*

* * *

Бүтән килмибез дип,
торып киткән утыргычны ватмыйк әле.
Бу бакчага бездән башка
күп гашыйклар киләсе бар!
Җимермик әле барысын!
Калсын:
гашыйкларга ышык урыннар калсын!
Кул кысышыр өчен станцалар, портлар,
салават күпере чагылырга — чык-тамчылар,
карлыгачлар өчен — зәп-зәңгәр күк,
кешеләргә
җырлар калсын!
Көчле җырлар!

Җимермик әле барысын!
Без бит кыргый түгел ләбаса.
Беренчеләр түгел дөньяда:
беләбез яхшы-яманны,
буыннарның әманәтен һәм өметен,
әйткән сүзебез,
кылган эшебез мәгънәсен...
Артны учакка каратып,
соңгы алманы Кояшка атып
китмик!

Без бу дөньяда
иң соңгылар түгел...

*1964*
*Казан*

## ПАРИКМАХЕРСКАЯДА

Без тәвәккәл,
йөрәк бар бездә, —
сискәнмибез дә,
шикләнү дә юк уебызда...
ә бит муеныбызда —
парикмахер кызның үткер пәкесе
аркылы уза,
буйга уза!..
Пәке бии муеныбызда!

Ә артериядә кан,
ябылып яшәүдә өлгергән кыз кебек,
тарлыктан туйганга
туглана —
пәке белән ярәшергә кабалана!

Ә без —
әйтерсең лә сабый бала:
юаныч бар — көзге алда.
Аякларны салындырып утырабыз креслода.
Тик шулай да
тәвәккәл без,
йөрәк бар бездә:
ике дә уйламыйча,
тартынмыйча,
акылыбызда килеш
баш бирәбез пәке тоткан хатын-кызга!

Күк.
Реактив самолет.
Бер ир кеше кабинада.
Ә канаты самолетның Кояшта, ай, ялтырый,
планета венасын кисәсе пычакмыни!
Кинәт...

канат астыннан бомбалар!
Әйтерсең пәкедән тамучы кан алар.
Планета!
Бетте?!

Бер пәке канатлы самолет,
бер ир бармагы,
бер кнопка
харап итте?

Юк!
Бу төш.
Минем саташуым!..

Мин ышанмыйм:
хис тоткыны — хатын-кызның
ялгышып та — кан тамырын кисмәгәнне,
ирләр —
нык җилкәлеләр,
мәхәббәтнең, иминлекнең
сагына алынганнар,
көчле җаннар —
Җир кендеген кисмәс!
Кисмәс!

*1964*
*Казан*

## ТОЛ ХАТЫННАР ЧӘЕР АГЫЗА

Күңеле китекләргә сүздә сак бул.
Каты бәреләә күрмә ялгызга.
Ялгыз наратларны кочып, тырнап,
тол хатыннар чәер агыза.

Эссе җилдә җәрәхәтен ачып,
әй, сызыла кәүсә, әй, сыза...
Тиргә батып, нарат күкрәгеннән
тол хатыннар чәер агыза.

Нихәл итмәк кирәк, яшәү очы
багъланган булгач сагызга...
Сызландырып, үзләре дә сызып,
тол хатыннар чәер агыза.

*1965, 17—18 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Үләнгә—
борынлап чыгарга, яшәрергә... тагын җиргә сеңәргә.
Ташка —
җилдән ярылырга, яңгырдан уелырга... җиргә иңәргә.
Кошка —
талпынырга, җил кочагына атылырга, аннан... җиргә.
Миңа —
Нәфрәттән Мәхәббәткә кадәр
күтәрелергә,
күтәрелергә,
күтәрелергә...

*1965, гыйнвар*
*Казан*

## ИҢЕМӘ КУЛЛАРЫҢ ОРЫНГАЧ

Буран котырган төндә,
кечкенә бүлмәмдә,
уйда изрәп утырганда,
иңнәремә минем
әллә апрель,
әллә май кагылды?

Тәнем буйлап кинәт
зәңгәр гөрләвекләр йөгерде,
ләйсән яңгыр исе
яңагымны сыйпап узды,
күзләремә тулган зур шатлыктан
керфекләрем ябылалмый калды.
Күңелдә булган инсафсыз сүзләр,
иреннән тәгәрәп,
идән ярыгына төшеп югалдылар...
Өстәлдәге агач ручка яфрак ярды,
урындык аяклары сөенешеп үзара
пышылдаштылар
(такмак язучы шагыйрьдән акыллырак булып
күренделәр алар бу минутта),
язу машинкасындагы хәрефләр
иң игелекле сүзләр язарга әзерләнделәр...
Туңган тәрәзәдә бөгелгән кулларың чагылышы
салават күпере ясады;
урамнан — шул күпер өстеннән —
безнең тәрәзәгә елмаеп,
изге күңелле кеше узды...

Котсыз суык көнне,
шыксыз бүлмәмә син яз китердең.
Әгәр һәр кергән бүлмәгә яз ясасаң,
миңа күңелле булмас...

Тик шулай да бүлмәләргә,
кемнекенә генә булса да,
көз китермә, яме!

*1965, 10 май*
*Казан*

## КИТ!

Бар кит инде, сеңлем!
Күзләреңне тутырырлык
иң гүзәл сүзләрне
әйтәсем бар.

Кит!
Күңелемә сурәтең ясыйсым бар.
Төсләр эзлисем бар:
Кояштан,
чәчәкләр таҗыннан...

Кит!
Син барда мин һәрчак дулкынланам.
Яңгырлар белән юньләп сөйләшә алмыйм.
Җилләргә җавап биргәндә тотлыгам...

Кит!
Син киткәч,
күңелдәгесе белән
иркенләп,
ачыктан-ачык
сөйләшәсем бар.

Кит!
Тик беразга гына,
бик азга гына...

*1965, июнь*
*Казан*

* * *

«Ашыгыч ярдәм» машинасы бездән китkәч,
урамыбыз сөремләнеп калган иде...
Бүген бөтенләй башка!
Җитәкләшеп кайтып киләбез:
больница артта, атлаган саен дару исе кими бара.
Җылы кофтаңа,
кулымдагы пальтоңа кешеләрнең күзе төшә.
Бу эсседә...
Җил ярамаганын сиңа
каян белсеннәр соң!

Ә мин — Мәҗнүн!
Үз-үземне белештермичәме,
әллә сөенүдән каушапмы,
әле уң ягыңа чыгам, әле сул ягыңа:
бу ягыннан тотсам, аңа җиңелрәк булыр,
бу ягыннан тотсам, җиңелрәк булыр...

Кайтып җиткәч,
баскычтан күтәрелгәндә,
башларыбыз күккә тиеп-тиеп алды,
аяз күк — зәңгәр шатлык! — үзе безне үбеп алды.
Кеше сөенүенә мәрхәмәтле күк битараф буламы соң!

Сине йортта беренче булып
балкондагы яран чәчәк күреп алды.
Елмаюыңнан тәрәзәбез яктырып китте,
урамыбыз яктырып китте, шәһәребез...
«Рецептларны ерак яшердем: көн чыраен күрә
алмаслар,
боеклыгым озакка югалды, аңа тиз генә
юлыкмассың...» —
диден дә хәлсез кулларыңны мангаема куйдың.
Мин бу мәлдә онытылдым.

Терелүең шатлыгыннан
оныттым вакытны.
(Еллар, көннәр, секундлар, кичерегез мине!)

Әллә нинди бүген көне!
Ул безнең йорттагы җылылык,
ул безнең йорттагы яктылык —
глобустагы Арктикага да Кояш төшкән!

Әллә нинди бүген көне!
Күк тулы карлыгачлар,
чәчәкләрдә төклетура, бал кортлары...
Бакчага чыккач,
күкрәгеңә куярмын дип,
чәчәккә үрелдем. Кая өзү!
Тиз генә чәчәкләр янына үзеңне чакырдым.

Әллә нинди бүген көне!
Төнлә, күзләремне йомгач та,
шундый матур төшләр керде.
Хәлеңне белергә дип синең янга йолдызлар төште.
(Ләхет кебек түбәләр юк,
өстә туфраклы түшәмнәр юк,
гел пыяла гына!)
Аннан, сөенешеп, янә менеп киттеләр.
Таң атканчы шулай булды...

*1965, июль*
*Казан*

## КҮМӘЧ ПЕШЕРҮЧЕЛӘР ҖЫРЫ

Сез кем, дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр без!
Кешеләрнең йөзләренә
шатлык төшерүчеләр без!
Күмәч пешерүчеләр без!

Күмәч кебек йомшак түгел,
үзебез каты куллыбыз:
изә, баса, туглыйбыз,
йоп-йомшак камырны
кайнар мичкә юллыйбыз.
Күмәчләрнең йөзе килсә,
бөркелеп хуш исе килсә,
нечкәрә күңелебез:
сөенәбез, көләбез —
бик сабый күңелле без.

Күмәч пешерүчеләр без!
Пешерәбез йөземлесен,
мәклесен һәм мәксезен,
түгәрәген, сырлысын...
Табыныбыз мул булсын!
Әйдә, кайчак он кунсын,
куллар камырда булсын!
Тик эшебез эшчәннәрнең
хезмәте чаклы булсын,
күзләрдә чаткы булсын,
йөзебез якты булсын!

Сез кем, дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр без!
Без күп телләр белмибез,
күп илләрне гизмибез,
алтын белән диварларда
язылмый исемебез,
икмәк кебек гап-гади,
күмәч пешерүчеләр без!

Эшебез, ай-яй, тыгын,
сөйләшмибез артыгын,
кабарт, из, бас тизрәк,
әвәлә, сал тизрәк!
Күмәч кирәк! Күмәч кирәк!
Эшчегә, язучыга да,
саллар агызучыга да,
очкыч җибәрүчегә дә,
пыяла өрүчегә дә,
терлек караучыга да,
полярник аучыга да,
речьләр сөйләүчегә дә,
чалгы көйләүчегә дә,
БМО башлыгына да —
барсына да, барсына да
күмәч кирәк, күмәч кирәк!
Кабарт, из, бас тизрәк,
әвәлә, сал тизрәк!
Күп кешеле зур чатлар,
светофор-маяклар,
машина-самокатлар
авырсынмый юл бирсен!
Әбиләргә, бабайларга,
этиләргә, әниләргә,
сеңелләргә, энеләргә,
абыйларга, сабыйларга
чәйгә күмәч өлгерсен!
Иртән дә күмәч булсын,
көндез дә күмәч булсын,
кичен дә күмәч булсын,
урта бер җирдә
табынның
кояшы булып торсын!

Сез кем, дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр без!
Кешеләрнең йөзләренә
шатлык төшерүчеләр без!
Сез кем, дип сорыйсызмы?

Тәнгә, кул-аякларга
хәрәкәт бирүчеләр без!
Сез кем, дип сорыйсызмы?
Тереклеккә гел яшәргә
куәт бирүчеләр без —
күмәч пешерүчеләр без!

Ә соң сез
үзегез
кем?

*1965, октябрь*
*Казан*

* * *

Кил, кайгы, кил!
Танып, ерактан күреп кил!
Гөрләвектәй йөгереп кил!

Кил, кайгы, кил!
Дустай кулыңны сузып кил!
Шатлыкларымны узып кил!

Кил, кайгы, кил!
Дәртлелек белән көлеп кил!

Тик
тиз китәрсең, белеп кил!

*1965, октябрь*
*Уфа*

* * *

...Уйда җиткесез уй-хыял!
Ашканы җирдә — чынлыкта —
гөрләвектән дә артта.

...Ишетелә кайчакта, —
дөнья күргән картлар сөйли:
«Сугыш чыга җәй якта...»

...Сандугачларын тирбәтеп,
бер куак та кар-буранга
яшелдән керә алмады.

...Быел да көртләрне ярып,
тәңре-җиргә мәет узды, —
туң каршы торалмады...

Кыен...
Шагыйрь җанга беркайда да,
беркайчан да җиңел түгел —
язларын да, көзләрен дә...

*1965, 11 октябрь*
*Уфа*

## МИНЕМ ТЕЛЕМ

Минем телем —
меңәрләгән ишләре күк,
тыйнак тел ул.
Гайрәтләнмәс, артык һаваланмас,
яңгырыйм дип кабаланмас,
җегәр чиген белер,
йөрер җирен...

Басынкы ул:
БМОларда конгресслар,
парламентлар ачып йөрми,
акча, чеклар битенә менми,
Сугыш ачмыйлар минем телемдә...
капитуляция дә ясамыйлар!

Түзем тел ул.
Окопларда, төрмәләрдә, лагерьларда
атылса да, ысланса да, асылса да,
җиңү рухын җуймаган ул.
Гильотина өсләрендә
яшәү җырын җырлаган ул!

Минем телем —
меңәрләгән ишләре күк,
моңлы тел ул.
Үзенә җай, үзенә ятыш аның көе.
«Сак-Сок»лары, «Рамай»лары, «Сарман»нары,
«Гөлҗамал»ы, «Карурман»ы, «Әллүки»е...

Гавәми ул,
бик гади ул.
Минем телдә иген үсә,
сөт парлана, җеп эрләнә,
нефть чыга, тире иләнә...
Туендыручылар,
киендерүчеләр дигәндә —
минем телем искә төшсен!

*1965, 3 декабрь*
*Казан*

* * *

*Урман караучы кызының*
*такыясы ландыштан!*

Малайчак дәфтәреннән

Сине күптән күргәнем юк,
бик еракта торасыңдыр.
Урман кызы түгелдерсең,
инде ана булгансыңдыр:
тормышның авыр, җиңелен
тәнеңдә тоясыңдыр...

Кайчак бик күрәсем килә,
бик-бик сөйләшәсем килә...
Тик куркам, кыен булыр күк
син такыясыз булсаң,
каршымда ханым булып,
тулышып басып торсаң.
Юк,
яхшысы, күренмә син,
Мин ияләндем бугай,
үткәннәргә кайтмак булсам,
исемә төшереп шулай,
сиңа аталган сүзләремне
кабатлыйм яңабаштан:

«Урман караучы кызының
такыясы ландыштан!
Урман караучы кызының
такыясы ландыштан!»

*1965*
*Казан*

## ХЫЯЛГА

Алдадың, Хыял, алдадың!
Әллә үз итеп алдадың...

Хәтереңдәме,
сабый чакта
күктән йолдыз
алып төшеп бирәм, дидең.

Малай булгач,
зәңгәр күктән өлге кисеп,
күлмәк тегеп бирәм, дидең.

Егет булгач,
иң инсафлы Зөһрә кызны
Айдан алып бирәм, дидең.

Ата булгач,
бишек сакларга
яшеннән
кылыч алып бирәм, дидең...

Алдадың, Хыял, алдадың!
Әллә үз итеп алдадың...
Мин картайгач,
үлем юк дип,
анда да син
тагын, яме, алдаларсың.

*1965*
*Балык Бистәсе*

## КҮЗЛӘР

Күккә баккан күзләреңне үптем.
Иреннәрем белән гүя күккә орынып,
болытларны,
тургайларны үптем...

Алар барысы
күзләреңә сыйган иде.

Җиргә баккан күзләреңне үптем,
туфракны,
чәчәкләрне,
шулар белән
үземне үптем...

Алар барысы
күзләреңә сыйган иде.

Күзләреңне үптем.
Синең кайгың,
шатлыгыңны кушып
мин дөньяны үптем!

Бүген миңа күңелсез.
Янымда син юк,
күзләрең юк...

*1965*
*Казан*

## АҖАГАН

Аҗаган уйнаклады,
аҗаган уйнаклады...

Төнлә карт
идәнгә төшкән
юрганын тартып алды.
— Яшенме әллә ялт-йолт итә?
— Әй, карчык, йокла! Хәвеф юк —
аҗаган гына бары!

Яшьләр үбешә иделәр...
Иреннәр аерылмады.
Керфекләр генә сөйләште:
«Аҗаган гына бары,
аҗаган гына бары...»

Кемдер юри радиоалгычның
штепселен алмады:
«Музыка тыңлыйм. Ә күктә
«Алла фоторепортеры» —
аҗаган гына бары...»

Ояда кош
канатыннан
башын да чыгармады.
«Давыл түгел — очыртмас ла,
күкрәү түгел — тетрәтмәс лә,
аҗаган гына бары...»
Булмады быел алмалар —
агачлар кысыр калды.
Әйтте күпләр: «Чәчәген
аҗаган гына алды,
аҗаган гына алды...»

*1965*
*Казан*

## ҖИЛФЕРДӘҮЧЕ КЕРЛӘР ҖЫРЫ

Без елый белмибез
Авыр булсак та,
яшькә бай булсак та,
елый белмибез.

Без җырлыйбыз бары:
җилфердәп торсак та,
кыштырдап куйсак та,
бары җырлыйбыз.

Без сансыз күптөрле,
ә җырыбыз — бер:
Кояш турында гел,
Җил турында гел.

Без бик күп төслеләр.
Безнең арада —
бар сары, алы да...
төсен җуйганнар да,
манылганнары да...

Безне киючеләр —
Кешеләр төрле.
Үзләре кебек үк
җырлары төрле.

Безнең җыр — мәңгелек,
безнең һаман — бер:
Кояш турында гел,
Җил турында гел.

Пуля тишә безне,
сода кисә безне...
Юк, сыкрау түгел, —
әйтү бу сүзне.

Кешеләр мәңгегә
киткәндә бездән,
яшь агызып түгел, —
кул болгап калабыз,
җырлап калабыз.

Без авыр булсак та,
яшькә бай булсак та,
елый белмибез, —
бары җырлыйбыз без.
Ә җыр һаман — бер:
Кояш турында гел,
Җил турында гел...

*1965*
*Казан*

## АШКЫНУ

Кош оча, йолдызлар атыла,
елгалар ярыннан ташына...
Шуларны күрәм дә, күңелем
еракка, еракка ашкына.

Җир матур, Җир гүзәл, тик аны
кадерләп, серләрен ач кына.
Дәрт тулы күңелем барсын да
белергә, күрергә ашкына.

Ышанып киләчәк тормышка,
сокланып кешеләр гыйшкына, —
җыр тулы тынгысыз күңелем
яшәргә, яшәргә ашкына.

*1965*
*Казан*

## РӘСЕМ

Күкне бизәкли карлыгач.
Җирне ямьләтә ярым.
Карлыгач, оч-оч югары,
Син, ярым, елмай тагын.

Карлыгачта — җәя канат,
Ярымның — матур миңе.
Карлыгач, иркәлә Күкне,
Син, ярым, назла мине.

Карлыгач, ярым миңенә
күләгәчек төшереп ал.
Син, ярым, Күк һәм Җир өчен
бер елмаеп көлеп ал.

*1966, 16 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Вулканнар бар диңгез төбендә.
Әллә ниләр кайный күңелдә.
Бар җиһанга ярасы иде дә!..
Ярар, сабыр, калсын бүгенгә.

Иртәгесен иртүк уй туа:
«Без дөньяга ир булып туган!
Ярыл, фикер! Чишел, тойгылар!
Чыгарып сал, башка ни тулган...

Кичен янә шәфәкъ — күгендә,
әллә ниләр сызлый күңелдә.
Ирексездән иреннәр көйли:
«вулканнар бар диңгез төбендә,
вулканнар бар диңгез төбендә».

*1966, 15—16 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Ал поездлар юллыйм мин сиңа.
Каршыла!

Кайчан сиңа килеп төшәрләр?
Бураннарда балкып төшәрләр күк.
Ләйсәннәрдә...

Ал поездлар юллыйм мин сиңа.
Кешеләр юк,
тавышлар юк,
көпчәкләр юк, —
фәкать сагыш
вагон-вагон...
Сагыш, сагыш...

Ал поездлар юллыйм мин сиңа.
Иртәгә килерләрме,
бер айданмы...
Тик каршыла!
Тик каршыла!

*1966, февраль*
*Казан*

* * *

Күз кичәге — караш бүтән,
сүз кичәге — мәгънә бүтән…
Горурлыгым уяу чакта
юл бир миңа, китәм!

Ялварасың, алгысындым:
«Кичәгегә кайтсак икән!..»
Үткәннәргә хәтер кайтыр,
мин тере әле — китәм!

*1966, 28—29 май*
*Казан*

* * *

Мин сине ничек яраттым!
Мәктәп юллары белә.
Синең эзне аера идем
мең эздән, карау белән.

Мин сине ничек яраттым!
Искә төшерәм дә, тынам.
Орыну түгел, күз атсам да
рәнҗетер идем сыман.

Мин сине ничек яраттым!
Киттең читкә. Көтмәдең.

Хәбәрең бар: «Нигә шулчак
үзеңнеке итмәдең?!»

Каян белим ди мин ул чак
кавышу-кушылулар барын.
Сине яраттым. Яраттым.
Яраттым... Менә шул бары.

*1966, 2 июль*
*Казан*

* * *

Шатлыгы киләме бүген?
Әллә кайгысы килә?..
Нигә әле бу уй башта?
Кыр казы исе килә!

Бу яз көнне, аяз көнне
сөя, назлыйсы килә!
Җаны йокымсыраганнарга:
«Терел! Яз!» — дисе килә!

Бардыр... Бәлки, кемнәрнеңдер
кабер казыйсы килә...
Бу чакта ничек үлим соң —
кыр казы исе килә!

*1966, 9 июль*
*Чуаш Кичүе*

* * *

*Дөньяны яратудан арса,*
*туйса күзләрем, —*
*елтыраштырып торганчы,*
*ябу хәер үзләрен...*

Изасы бар, хафасы бар,
Барырым — чытыр юллы.
Каш астында ике алма —
күзләрем һаман шулмы?

Өйрәтәләр, күрсәтәләр:
моны түгел, ал шуны...
Үземә иң гадел күргән
күзләрем һаман шулмы?

Булыр малы, булыр даны.
Шау күмәр уңны-сулны...
Балачактан саклап килгән
күзләрем һаман шулмы?

Текәлеп карыйм юлны,
күзләрем һаман шулмы?

*1966, 12 июль*
*Чуаш Кичүе*

* * *

Кыз бала йөгереп үткән.
Тезенә бәрелгәч, башактан
орлыклар чәчрәп киткән...

Инде күптән җәй икән!
Кай арада яз үткән?
Кайчандыр учымда йөрткән
кыз үсеп буйга җиткән.

Инде күптән җәй икән!
Җанда моң әле ниткән...
Өлгергән бодай кырыннан
кыз бала йөгереп үткән, —
йомрыланган тезләреннән
орлыклар чәчрәп киткән...

*1966, 13 июль*
*Чуаш Кичүе*

## АЛМА

Нигә гаҗәпләнәсез?
Минем җирдә ятуымнан
шикләнәсез әллә сез?

Тулылангач, аллангач,
эрмәкләнгәч, баллангач,
гел бер җирдә — нечкә чемдә
торыр тәкать калмагач,
тоттым да
сикердем менә...

Нигә гаҗәпләнәсез?
Минем җирдә ятуымны
өнәмисез әллә сез?
Мин шул алма —
кичә өскә
карап сокланганыгыз —
үрелеп алалмадыгыз,
хәзер иелеп алыгыз!

*1966, 20 июль*
*Казан*

* * *

Бер күтәргәч өй булыр…
Инде бурада күз яше,
салып кергәч ни булыр?

Ире гел кагып торса,
яше гел тамып торса…

Бүрәнә җеге җектә,
дөнья тора нәзектә!

Салып кергәч өй булыр.
Инде бурада күз яше,
тора-бара ни булыр?..

*1966, 23 июль*
*Юлсубино*

* * *

Язын өмет булган икмәк
келәт тулы, чолан тулы...
Тышта яңгыр... Өйдә рәхәт
мич алдында җылы!

Чү! Әнә сабан тургае
тәрәзәгә кунган!
Күңелем убылып китте:
тамчы гына булган...

*1966, 25 июль*
*Юлсубино*

* * *

Ни бар канда, ни бар җанда
ачтым салдым. Ышандым.
Сөенечләрдән-көенечләрдән,
ичмасам, бер бушаныйм!

Ә чынлыкта авырайдым,
Уй-исәп барыбер басты:
Ни колакка ирешерне
төгәл белми, сер ачтым...

*1966, 26 июль*
*Юлсубино*

* * *

Үпкәлим,
һәр җай саен:
сәбәптән дә,
бер дә юктан да...

Беләм:
шундук юатырга ашыгасың, —
җанга ятыш сүз әйтәсең.
(Миңа шул кирәк тә!)
Иркәләргә тотынасың:
сыйпыйсың, үбәсең
чәчемне,
күземне...

Ә мин
отыры күбрәк үпкәлим.
Мин, имеш, гел кимсетеләм,
һаман саен рәнҗетеләм...
Сабый бала анасыдай —
син ничек тә көйлим, дисең:
Хет көлеп,
хет елап,
хет биләп...

«Үчтеки» итмәк буласың,
Көчең генә җитми!
Алдыңа алмак буласың,
кулың гына җитми!
Күбрәк иркә өмет итеп,
мин тагын үпкәлим, —
отыры күбрәк...

Ә син үзең
бер дә юкка бүген
ничек газапладың!

Күңелеңне табар өчен
ни кылмадым!
Үтендем,
ялвардым,
табындым...

Аның саен
боек торгач —
коелып төштем,
йөземнән нур качты,
өнем бетте.

Бары кичен —
елмайгач кына син —
үземә кайттым,
терелә алдым.

Мин бит
юри генә үпкәлим гел,
Ә син
әллә чынлап инде?

*1966, 9 август*
*Казан*

* * *

Кеше ирекле...

Яланаяк
салкын, юеш ташта торамы ул,
үлән-чәчәк өстендәме,
һавадамы,
судамы,
җир куены шахтадамы —
ул ирекле.

Хәятыма тигән
шул зур бәхет өчен
көрәшергә бөек хакым бар.

Талчыгаммы мин бу юлда,
тетримме рухи,
кимсенәмме,
тир түгәмме, канмы,
тәмам бетәмме —
барына хаклы.

Тик...
җиңелергә генә
хакым юк!

*1966, 10 август*
*Казан*

* * *

Илгә чыксам, өн ишетәм:
«Сак бул, зинһар! Гарип итмә?
Без дә кешеләр шикелле —
җан кирәк вә кан кирәк!»

Өйгә керсәм, өн ишетәм:
«Гарип итмә! Гарип итмә!
Без дә кешеләр шикелле —
җан кирәк вә кан кирәк!»

Сүздән сурәт ясый идем, —
алар миннән җан сорый.

*1966, 12 август*
*Казан*

* * *

Ни исәп, ни гамь бар бу ярда?
Ни сагыш, ни моң-зар бу талда?
Ни хикмәт, ни акыл бу ташта?
Ни төен, ни сер бар бу тауда?
Ни көй бар, ни җыр бар инештә?
Ни бөек мәшһүрләр бу төштә?
Ни мәзәк, ни җорлык бу якта?
Ни үлән, ни һава, ни дым туфракта?..

Әгәр дә шуларны белмәсәм,
ничек мин
үткәнен, бүгенен
аңлыйм бу Илнең?

*1966, 13 август*
*Казан*

* * *

Төн эченнән атлыйм сиңа, Ут.
Якыная, елыша барам...
Үз ялкыным белән килгән саен
җемелдәвең кими,
сүрәнләнәсең,
тоныкланасың...

Җәлеп иттең.
Тарттың.
Килдем.
Күрдем.
Ә сүземә
рәнҗемә, Ут!

Юлдагылар — чиксез
Яктылыкка баручылар бихисап күп.
Бүген шулай.
Иртәгә күбрәк булыр,
Алга табан тагын...
Шунсы кыйбат!

*1966, 24 август*
*Казан*

* * *

Туфрак җибәрде мине:
«Хәрәкәт иясесең —
яшә! — диде. —
Йөгер! Җырла!
Озат! Көнләш! Көт!
Сөен! Сыен! Оч хет!..»

Тик —
онытмаска:
мине туфрак җибәрде
Кояш астына —
сынамакка...

*1966, 27 август*
*Казан*

* * *

Катмарлы икән,
кызык икән
тормыш гармониясе.
Әле ия, әле чөя,
әле сөя, әле төя!..

Ә син миңа
шуның барысын
көйлә, дисең,
бер көй белән.

Күз — дәрья.
Күңел — дөнья.
Сыйган аңа
шарлавык та,
тын елга да,
бал да, кан да,
гөлле уч та,
ут-кылыч та...

Төрле көчтә,
төрле эштә,
төрле тында,
төрле тонда,
төрле тәмдә,
төрле ямьдә
шигырьләр дә!

*1966, 29 август*
*Казан*

* * *

Чәчмим, җыймыйм,
чапмыйм, коймыйм...

Шулай да
миндә дә соңармый чәчүләр,
шытымнар сау-имин чыгалар,
өлгергәч башаклар, —
минем дә бәгырьгә төртелә, —
йөрәгем төбендә шау тынмый:
чабалар күмерен,
коялар корычын...

Әгәр дә Кешеләр
ышанса шуңарга —
чәчәм дә, җыям да,
чабам да, коям да!..

*1966, 10 сентябрь*
*Казан*

* * *

*Башны хәсрәткә салып,*
*шигырь язасың талып.*
*Төрлечә гули халык...*

Башны салларга салып
китәсе иде агып...

Бер күңел булыр иде!
Шатлыгым ургыр иде,
Йә сыктап сулгыр идем.

Башны салларга салып
китәсе иде агып, —
дәшәр иде әле дулкыннар
бер шагыйрь җанны танып.

*1966, 19 сентябрь*
*Казан*

* * *

Матурлар күп.
Тик алар
кереп югалалар тыкрыкларга,
күмеләләр куаклар артында,
калалар тукталышларда,
утырып китәләр йә...

Ә син минем
гел янымда! —
һәрчак үзем белән!

Матурлар күп.
Ә син —
матурларның иң матуры.

*1966, 27 сентябрь*
*Сембер*

* * *

Ярамаган сүз дисең.
Ник ярамаган булсын!
Әйтергә дә ярамагач,
нигә яралган ул соң?

Ярамаган сүз дисең.
Булса соң? Әйдә, булсын!
Яраганнарга үч итеп
яратыйк әле бусын!

*1966, 22 октябрь*
*Казан*

* * *

Җирдә төсләр, җилдә тавыш,
миндә исәп, миндә уй...
Аз бит гомер, аз бит яшәү
кадерсенеп торсаң да!

Җирдә төсләр, җилдә тавыш,
миндә исәп, миндә уй...
Кеше кадәр Кеше булып
кабер сине йотсын, ә?

*1966, 23 октябрь*
*Казан*

# Солдат дәфтәреннән

*Солдаттан әйләнеп кайттым,*
*Әмәт тавындагы Ай*
*тамчы да үзгәрмәгән.*



* * *

Басып торам
карта алдында.
Меридианнар сугыша,
параллельләр сугыша,
материклар сугыша,
таулар, сулар сугыша...

Иң кыены
кешеләр сугыша.

*1966, 3 сентябрь*
*Казан*

* * *

Туган якка оча аккош,
җилпешләре җиңел икән!
Сәлам яздым канатына —
күрдегез микән?

Туган яктан килә аккош,
кагышлары авыр, авыр...
Канатларыннан укыдым:
«Итә күр сабыр!..»

*1966, октябрь*
*Казан*

## ЯРАН ГӨЛ

Миңа күренгән
читәннән бүтән, —
арырак киткәч, —
ниләр бар икән?
Миндәйләр бармы?!
Булса, ни атлы?
Күпме иркенлек,
никадәр якты?

Чәчкәмне салып
пыялаларга,
карыйм урамга —
телим аңларга:
«Ни соң ул җирләр?
Ни соң ул илләр?
Кешеләр кем ул?
Ни сүз сөйлиләр?»

Миңа күренгән
читәннән бүтән, —
арырак киткәч, —
ниләр бар икән?

Читән. Тау бите.
Аннан — җир чите...
Яшәү — тәрәздә:
кысан һәм читен!

Күрсәт дөньяны,
аңлат тәртибен.
Әй, балчык чүлмәк!
Әй, тәрәз төбе!..

*1966, 7 ноябрь*
*Казан*

* * *

Куып тереклек итүнең
мең башлы мәшәкатен, —
куеп бер якка көннәрнең
каһәрен һәм шәфкатен;
үз хозурында җанны бер
рәхәтлеккә талдырып,
керфек эрерлек яшемдә
кояшны чагылдырып,
килә елыйсы кайчакта,
килә өзгәләнәсе!
Ярый нечкәрә беләбез,
юкса
нишләр җирнең бәндәсе?..

*1966, октябрь*
*Казан*

* * *

Бу дөньяны, кешеләрне
тик яртылаш яраталдым.
Бирә алыр шатлыкларның
тик яртысын таратталдым.

Ярты тизлегемдә үттем —
максатыма барышымны.
Тик яртысын очлый алдым
кулдан килгән бар эшемнең.

Ә менә
бәхеткә өмет
ярты түгел, —
туп-тулы.

*1966, 9 ноябрь*
*Казан*

* * *

Манма сумын. Ник туктамый?
Әй, каһәрле яңгыры!
Ниткән шомлык? — япа-ялгыз
буп-буш кырда каңгыру...

Бар бит зур, җылы сарайлар,
катлы, затлы пулатлар...
Тиздән, тиздән туңган тәнем
берәрсендә кунаклар!

Төнгә калдым. Күшекте тән.
Кая зат түр уемда!
Куанып җылыттым җанны
ялгыз кибән куенында.

*1966, 9 ноябрь*
*Казан*

* * *

Ярлар күчәр, дулкын бәрсә.
Тик... торсыннар безнекеләр!
Тимәгез җанкайларга!

Ут өстенә ут өрмәгез!
Болай да ялкында без...
Тимәгез җанкайларга!

Исән булып, бер кайтырбыз,
ничек тә бер юатырбыз...
Тимәгез җанкайларга!

*1966, 6 декабрь*
*Казан*

## ӘЙТТЕ КЫЗ КАЗАРМА ЯНЫНДА...

Погоныңа черки кунган —
ку, солдат! Ку, солдат!
Кулларыңа таплар тигән —
ю, солдат! Ю, солдат!

Сукмагыма каршы төшмә,
кит, солдат! Кит, солдат!
Кайтып, ярыңны бәхетле
ит, солдат! Ит, солдат!

*1966, 9 декабрь*
*Казан*

* * *

Син — гүя бер күчмә шәһәр
һәм мин яшим шунда, —
бер бәләкәй почмагында.

Син — чибәрсең. Шуны раслап
гел йөрисең гизеп,
биеп, көлеп,
төнге матур калаларың буйлап...

Онытылмакчысың.
Ничектер акланмакчысың.
Күрми дисең?
Тоймый дисең?
Мөмкин булса —
йөгереп, яшьнәп
элеккегегә кайтмакчысың!..

«Аһ!» дигән сүз
нигә бик еш
сагыш булып тибрәнә
бу шәһәрнең өсләрендә?

Синдә яшим мин.
Бер бәләкәй почмагында.
Уңай булсын, димим,
җиңел булсын, димим,
бәргәләнмим, сүз дә дәшмим,
мин бит бары —
бәйсез куыш
(дөрес, кемнәргәдер мин дә шәһәр).
Син — шәһәрнең
иң газиз бер почмагында...

*1966, 13 декабрь*
*Казан*

* * *

Телем оер,
каным кибәр,
күзәнәкләр катар
торараштай... —
сөюеңнән мәхрүм итсәң.

Тик күзләрем калыр
элеккечә,
өмет белән.

Чагылырсың, бәлки...

*1966, 14 декабрь*
*Казан*

* * *

*...гә*

Җир җимермәк идек!
Күкне ватмак идек!
Мәңгелеккә балкыр
утлар якмак идек!

...Күзгә сагыш иңгән,
исәп башны игән.
Балкыр чыра сүнгән
тамчы яңгыр белән...

*1966, декабрь*
*Казан*

* * *

Булчы, зинһар, зәңгәре син
салават күперенең!
(Нишләве бу зәңгәр күзнең,
яндыру-өтүеме?
Бу хисем — үсүемме соң,
әллә дә бетүемме?)

...Иң яхшысы, бул зәңгәре
салават күперенең!
Зәңгәрлегең ялкынында
тилермәс, янмас идем.
Күккә төбәлер идем дә
күземне алмас идем.

*1966*
*Казан*

* * *

Алма булырга иде миңа!
Теләмәдем, —
бурзай этләр өргән чакта
дерелдәргә ботакта.

Кыр чәчәге булырга иде!
Теләмәдем, —
чүп дип, читкә атуларын
ашлык җилгәргән чакта.

Туфрак булырга иде дә!..
Минем өстә
полигоннар корырлар дип
курыктым мин.

Таш булырга иде!
Йә чардуган итәрләр дип,
кире уйладым.

Кеше булдым.
Дөньяда
өр-яңа аваз,
карлыгачтай очып,
вокзал,
базар,
сиреналар шавына ияреп,
гомумтавыш гармониясенә кушылды.

Беләм:
бу — кемгәдер ошамады.
Җирне ихлас «яратучы»
мальтусчылар,
яңа авазны буарга теләп,
тукындылар:

«Җиргә хәзер,
биләүләрдән бигрәк,
кәфен кирәк!..»

Дөньяда
янә ике яшь кул,
нурларга тотынып,
Кояшка үрелде.
Беләм:
Бу — кемгәдер ошамады.
Үтерешле уйнап,
әледән-әле
бомба шартлатып,
мин ябышкан Кояш нурларын
өзмәкче булдылар.

Ә шулай да күпләр
чын күңелдән сөенделәр.
Күңеле тарларның
ысылдавын басып:
«Хәерле»,
«бәхетең белән», — диделәр.
Сукранмыйча,
хәрәкәтемә — ирек,
карашыма — киңлек,
ә тәнемә — икмәк бирделәр;
киендерделәр,
сүз мәгънәләренә төшендерделәр.
(Икмәк һәм Металлның
чын асылын мин алардан белдем;
парга очса да,
тирнең судан аерылганын
мин алардан белдем.)
Әйе, күпләр яхшылык теләде миңа:
сукырлар күрергә өйрәтте,
аяксызлар — адым ясарга...

Кырын карамады җисемнәр дә:
миңа
Кояш —
елмаюын,
Ай — ак нурын,
юл — тузанын,
диңгез — шавын,
җил — дулавын җәлләмәскә вәгъдә итте.

Кеше булдым.
Бәхетлемен!
Уйның түмен тоя алам,
хисемнән шигырь коя алам,
борчылып, янып-көя алам,
онытылып, шашып сөя алам.

Тагын нәрсә?
Кирәкми бүтән, —
ахыргача
кешелегем
саклый алсам, —
бәхетлемен.

*1966*
*Казан*

## НАРАТ

Күкрәк-кәүсәм яргаланган...
Тама аннан, ага аннан
кемгә чәер, кемгә бәгырь...

Әй, тол хатын! Син ник монда?
Югал күздән! Янда торма! –
Кешеләреңә кайтып ела!

Ылыс сыза, үзәк ката,
улакчыктан агып ята
кемгә чәер, кемгә бәгырь...

Әй, тол хатын! Кил, кил монда!

Кумыйм! Кумыйм! Тор янымда
теләгәнчә, теләгәнчә...

*1966*
*Казан*

* * *

Күкне иңдереп,
башымны идең.
Мин бит — тургай!

Төннәремне кудың.
Яктыртучы бөҗәк мин!

Җырларымны будың.
Мин бит — аваз!

Миннән барсын алдың.
Мародерның күзе төшмәгән
үлек кулындагы сәгать кебек,
ялгыз мин калдым...

*1966*
*Казан*

* * *

Болын кебек бу маңгаем
вакыт мөһер суксынгамы?
Күкрәкләргә сыеныргамы?
Батырлар чардуганына,
иелеп, орыныргамы?
Уйланып, шәфәкъ күзәтеп,
тәрәзәгә терәргәме?
Туган җиргә капланганда,
чирәм эзе төшсенгәме?..

Башны тотып уйланганда,
маңгаемнан уч төбенә
җыерчыклар күчәр төсле...

*1966*
*Казан*

* * *

Өшеттергеч бәсле ак кар
чия ботакларында.
Кояшка да ут өстәр дәрт
янса да каннарымда, —
барыбер, Җирдә җылылыкның
җитмәгән чаклары ла!

Агачлар нурга тиенми,
кешеләр — җылы сүзгә...
Табигатькә рәнҗик микән,
үпкәликме үзебезгә?

*1966*
*Казан*

## СОЛДАТКА КИТҮ

Юатырга тырыштым,
Ә ул елап елышты.
Китеп бардык төялеп,
Ярым калды сөялеп.

Кая барам? Ник дип китәм?
Кемнән саклыйм кемнәрне?..
...Күздән яшьне җил киптерде,
кичеп чыккач үрләрне.

*1966*
*Казан*

* * *

Көн шыксыз дип карадым,
юл котсыз дип карадым.
«Казармага кадәр, диден,
барам дигәч барамын!»
Килеп җиткәч, күзгә карап,
бераз керми тор, диден.
Күк зилзиләсенә ымлап,
үзәк өзгеч җыр, диден.
Хәрбиләрчә, коры гына,
бу җыр түгел — кар, дидем.
Үзем җибәрмәскә кочкан,
үзем: кайтчы бар, дидем.
Кердем. Киттем. Син урамда
калдың буран эчендә...
. . . . . . . . . . . . . .
Хәзер май. Җирдә яшеллек, —
карның беткән исе дә.
Ә ул көннең ул бураны
бөртегенчә исемдә.
Карап ятам казармадан
майның аяз кичендә.
Күз алдымда син торасың
яшел буран эчендә.

*1967, 8—9 гыйнвар*
*Самара*

* * *

Яз гына Рухыңнан,
син — беттең!

Ашыйм-эчәм,
гомер кичәм,
дип куанма.

Тере мәетеңнең,
төртелергә кабер эзләп,
аунавы ул...

*1967, 13 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Офыклар — тоташканнар.
Болытлар — кочаклашканнар.
Ә мин менә
китәм әле...

Иминлек тели игеннәр.
Гыйшык сүз сөйли иреннәр.
Ә мин менә
китәм әле...

*1967, 19 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Әй, гашыйк без матурлыкка!
Әй, комсыз без ямьгә!
Ә соң үзебез ямьлеме?
Әйткән сүзебез тәмлеме? —
сирәк була гамьдә.

Ачулы без әшәкегә:
«Син хайванмы әллә?!»
Ник кешелектән төшкән соң?
Шул түбәнлеккә җиткән соң?
Сирәк була гамьдә.

*1967, 19 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Әй Туган җир! Туган җир!
Барлыгыма сыйган кадәр
бар яхшылык җыйган җир!

Әй туйган җир! Туенган җир!
Туып үскән илемә карап
күз яшьләрем койган җир...

Әй Туган җир! Туган җир!

*1967, март*
*Казан*

* * *

Мәңгегә яратам, димим.
Чөнки беләм, —
беркөн китәчәкмен үзем...
Тизме, соңмы?
(Бик соң түгел, уйлап баксаң.)

«Мәңгелегем!» дисең, еш кына
чын яратып, чын күңелдән.

Шул мәл карыйм да сиңа
моңсу гына көлемсерим...

*1967, апрель*
*Казан*

* * *

Шулай туры килә,
читләргә кителә:
әле уң якка, әле сул якка,
әле төньягыңа синең,
әле көньягыңа...

Һәр якның үзгә бер сагышы,
Һәр ераклыкның
үзгә бер ашкыну газабы...

Шулай да
рәхәт сине сагыну!

Көнбагыш чәчәкләре!
Көнбагыш чәчәкләре!
Очрыйлар һәркайда.
Син — үзәге аның,
сары чуклар —
юлларым минем.

*1967, май*
*Самара*

* * *

Кемгә хаҗәт шатлык-кайгың!
Янма-көймә — барыбер чит син.
Хәтта матурлыгы үрти:
«Син кем кадерлесе монда!..»

Кеше сабыр. Түзә. Күнә.
Ияләшә күз дә, тел дә.
Ә җан тынмый, үрсәләнә —
«Син кем кадерлесе анда?..»

*1967, май*
*Самара*

* * *

*«Кая барма, татар очратам...»*

*Җил-давылда чәчмә орлык,*
*давыл ерак алып китәр...*

Очырасың, очырасың
төшләреңне, гөл генәм!
Еракларга очыруда
дөресмесең гел генә?
Кай туфракка төшә төшең?
Уйлап бакчы бер генә!

«Мин төшләнәм, җимешләнәм,
ә уйната җил көче».
Шытмый калган төшләреңнең
илдә-җилдә ни эше?

*1967, июнь*
*Самара*

* * *

Күпмегә тулды тәүбәләр!
Кирәккәме? Кирәккә...
Ә тәүбәдән ни җиңеллек
имгәтелгән йөрәккә?

Тәүбә — дәва! Көн дә — тәүбә!
Җанны тынычландырам!..

Чынында — йөрәккә кат-катлы
сүтелмәс кәфен сарам...

*1967, 6 август*
*Самара*

* * *

Сәерсең, дисең, яши
белмисең шул бер дә!
Мин бит җиргә яңа килдем,
һәм күпмегә генә!

Ә шулай да күпме сукмак,
дус, дошманым илдә!
Ә бит үзем яңа килдем,
һәм күпмегә генә...

*1967, 14 август*
*Самара*

* * *

Юк кылган батырлык,
дәрәҗәм, олы даным.
Ничек соң сакчысы иткән
Илем, Анам, Ярым?!

Һәр күзәнәк киеренкедә.
Дөньяга карыйм.
Алда — хәвефле бишектә —
Илем, Анам, Ярым?

Әй вак күренә шулчак
гайбәт, интригаларың!
Оял! Ишетсә ялгыш
Илем, Анам, Ярым.

Авырга түзсә дә, вакны
күтәралмый җаным.
Ваксытма мине алда
Илем, Анам, Ярым.

*1967, август*
*Самара*

* * *

«Әле алда тулы ун көн —
яшәргә дә яшәргә!»
дип яздым да уйга калдым:
бу — чын булса әгәр дә
әйтү җиңел, белеп торсаң,
әле алда мең-мең көн.
Ә бит туачак бермәлне
ун көн калган шул бер көн.
Җитәрме йөрәк шул мизгел
үз җаныма дәшәргә:
«Әле алда тулы ун көн —
яшәргә дә яшәргә!»

*1967, 31 август*
*Самара*

* * *

Хәерлегә булсын,
син дә киттең...

Аяз көндә яшен димим
бу эшеңне,
әмма
арттан бәргән сөнге ише булды
бу адымың.

Тик мәлҗерәмәдем,
йөзем дә бозылмады,
сабыр, горур булдым.
Күрәсең, олыгаела,
күрәсең, күрелә төрлесен...
Ни дисәң дә,
минем дә бит инде
мәңгелеккә киткән
дусларым бар...

Ә болай киткәннәр —
исәннәр күпме.
Һәркайсының үз дөньясы,
үз сукмагы, үз түбәсе.
Күбесенең
артык тыныч,
артык тыйнак
аквариум — бәләкәй тормыш.
Кыскасы —
яшьлеккә хыянәт!

Оят
антлардан,
хатлардан,
серләрдән...

Хәерлегә булсын,
ниятләгәч,
китүең яхшы.
Мыштым качу урынына,
ирләрчә бер даулап китү
әйбәтрәк булыр иде дә...

Бераүгә дә:
«Элек дус идек тә,
хәзер сүндек», — димәм.
Кемнәрнеңдер
дуслыклары зурлыгына
шик төшерүем бар.

Синең хакта
яман бер сүз әйтмәм
яки сөйләмәм бөтенләй,
тыныч бул.

Хәерлегә булсын,
син дә киттең!..
Хәерлегә булсын,
хәерлегә...

*1967, 31 август*
*Самара*

* * *

*Ишетәсеңме,*
*әллә җил бу?*
*«Янсаң хөрлек*
*көрәшендә,*
*йә кылычтай*
*калсаң сынып, —*
*офтанма бер дә!*
*Заманалар*
*үзе килер*
*юксынып...»*

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
җай бар ул һаман да.

Ә бит бар кешеләр —
шәхесен ватмаган,
хаклыкны сатмаган,
вөҗданны саклаган.
Әйткәннәр: тарихтан
түгелсәм түгеләм,
изелсәм изеләм, —
әмма да бөгелмәм!

Үзләре сеңсә дә,
рухлары калыккан.
...Әнә шулар үлеме
җан өрә халыкка.
Асылыңны яшереп
кыланма ни генә, —
буыннар хәтерендә
бары да чигелә!

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга...

*1967, август*
*Самара*

* * *

Ятлар әйтте: олакты ла!
Дуслар сызды: аһ, китте!
Гомерме узды, мизгелме, —
менә кайтыр чак җитте.

Дуслар учагы кабынган, —
ялкын үреләә генә!
Ятларныкы сөрем аша
чак-чак күренә генә...

*1967, сентябрь*
*Самара*

* * *

Азмы кирәк
яшәү өчен? —
ышаныч,
көч,
ихтыяр,
дәрт!

Бездән —
көн дә кешелекклелек,
ныклык,
сафлык,
фидакарьлек!

Бездән —
көн дә яныш сөю,
тугры сүз,
җылылык,
нур!

Юкса
безгә җан өрүче
хыялдан оят,
тормыштан оят...

Алда — кул тимәгән
тау-тау эшләр,
өмет дәрьялары,
ераклыклар...

*1967, октябрь*
*Самара*

* * *

Куркытмый мине
безнең арадагы
ун чакрымнар,
йөз чакрымнар, мең чакрымнар.
Кисә бүтәне —
көннәр, төннәр...
Алар — күбәү.
Алар — калын урман.
Миңа — аларны кисеп чыгарга!
Аударырга Вакыт-кылыч белән
берсен уңнан,
берсен сулдан... —
әкияттәге пәһлевандай!

Вокзал, йортлар,
юллар, чатлар,
диңгез, һава юллары...
Алар — нәрсә!
Шахмат тактасына төшкән
бөҗәк кебек
кичәм шакмакларны:
әле карасын, әле агын.
Берсен үтәм,
янә алда икенчесен...

Шулай да
якынаям!
Якынаям
Сиңа!

*1967, октябрь*
*Самара*

* * *

Бала чактан туры
без көрәшкә кердек.
Бездән көлделәр,
без кайтарып көлдек!

Без тәүге кат килдек,
без тәүге кат күрдек, —
дөнья гаҗәп икән!
Мәйдан олы икән:
буының ныкмы дип
сорап тормый икән...
Канун, гадәтләрне
чыккан өнен атлап,
кирәбеткән чиру
китмәк булды таптап,
кайсы, өтәм, диде.
Кайсы, тетәм, диде.
Искелек: «Өереп
эзгә кертәм», — диде.
Ә без карыштык.
«Тамак-өс кенә
безнең җанга, — дидек, —
булыр кечкенә!»
Ә без тартыштык
нәни йөрәк белән!

Ышаныч дигән
бөек терәк белән!
Ашкынып чапканда
хөрлеккә йөз төбәп,
булды мизгелләр —
капландык йөзтүбән...

Тик
тордык янәдән
мең артык көч белән:
«Ирлекне расларга
эш белән! Эш белән!»

Бала чактан туры
без мәйданга кердек.
Без — үтә гайрәтле,
гаҗәп сабый идек.
Яшь күкрәккә ук
тиз кадала икән,
тик яшь тән барбер
тиз яңара икән.
Яшь кече — уй олы,
кайчак әрнү җанда.
Әмма, шөкер, —
хыял
исән-аман алда!

*1967, сентябрь*
*Самара*

## ЮАНУ

Юрадылар: «Бу — яшь, кайнар
ерак һәм озак баралмас...»
Бәхеттә чыныккан җан мин!
Бәлки, бәла алалмас?

Вөҗданым кушканча яшим;
димим бар да җай гына...
Бәлки, миһербанлы булыр
миңа язган кайгы да.

*1967, ноябрь*
*Самара*

* * *

Күңелеңә салкын тигән:
ютәллисең көнчелектән.
Хәтәр тигән! Хәтәр тигән!
Ялгыз калганда да — корык-корык,
хәтта кеше алдында да...

Ай яман чир ул — көнчелек!
Терелерсеңме, юкмы, белмим,
кызганам мин сине, бичара!

*1967, ноябрь*
*Самара*

* * *

Диңгездә Ай юлы.
Бер безме аерым?..

Ай нурында, һай, ялтырый
каешым аелы!
Сагышымны сиңа илтер, —
диңгездә Ай юлы.

Бер аерылсаң, ай, озак үтә.
озак үтә ай, елы...
Ай нурында, ай, ялтырый
каешым аелы.

*1967, ноябрь*
*Таллин*

* * *

Ут яна табаннар,
балтырлар таш...
Итекләрне салгач, пар чыга.
Шултик җирдә ни кылдың, дип,
син сорасаң, чыгып каршыма, —
әйтәм: берни!
Бары җыр үтердем, —
ул үз җырым иде туачак.
Әйбәт буласы идеме?..
Әмма
начар җыр тумады. Шунсы хак.

Итекләрне салгач, пар чыга,
пилотканы кыскач — тамчылар...

*1967, ноябрь*
*Самара*

* * *

Яктыга төшә күз, акка...
Күңел һаман — алгысына
матурлыкның алгысына.

Сөю хисе меңәү икән,
ә мин үзем берәү икән.
Акыл моны белә кебек,
ә соң йөрәк белә микән?
Ә соң үзем беләм микән?

Яктыга төшә күз, акка...
Күңел һаман — алгысына
матурлыкның алгысына.
Ә син, ярым, барсын узып
чык иң алга һәм... көт мине!

*1967, ноябрь*
*Самара*

* * *

— Кая ашкынасың, күңел?
— Ирекkә, тынычлыкка!
— Илаһи ирек, тынычлык
булмаган һәм ул юк та!
Җирдә көрәш кенә бары:
моны син беләсең, күңел.
Ә соң кая ашкынасың,
ярсыйсың, җитеп чиккә?
— Көрәш аша ирекkә!
— Көрәш аша ирекkә!

*1967, декабрь*
*Самара*

* * *

Була минутлар:
шатлык җанга сыймый —
ташый, ургый...

Сөенечеңнән җиңеләясең,
аерыласың туфрагыңнан,
шашкын хисең сөйри сине
бер илаһи биеклеккә...

Менү рәхәт!
Кеше күп чак шул мизгелдә
ялгыша да.

Безгә ак болыт булырга
язмаган шул...

*1967, декабрь*
*Самара*

* * *

Кешеләрнең үзләредәй
бәхеткәйләр төрле-төрле...
Кемнең җаны
кая очына!

Ә соң каян
уртак нәфрәт —
ялгызлыкка,
бәйлелеккә,
хыянәткә?

Әгәр илгә
афәт килсә,
стенадай
миллион иңсә!

Кешеләрнең үзләредәй
бәхеткәйләр төрле-төрле...
Ә шулай да
кешеләр
берләшә ала!

*1967, декабрь*
*Самара*

* * *

Килер бер көн, —
соңгы минут,
соңгы мизгел...

Күз карашы
нәрсәдәдер туктап калыр.

Ватасы килә аны!
Челпәрәмә китерәсе!
Юк итәсе!
Гел яшисе килә!
Гел яшисе!!!

Аһ, күп чак
ул мәл
баш очында безнең
иң якыннар булучан шул! —
туганнар
гомер кичкән ярлар,
балалар,
Кояш...

Менә ни өчен
ул чак
берни ватмыйбыз без,
җимермибез,
кырмыйбыз, —
әкрен генә
калучылардан бәхиллек сорап,
сүнәбез
үзебез...

*1967, декабрь*
*Самара*

* * *

*Н. авызыннан*

Исәннәрнең күзләреннән югалуга
(соңгы юлга китү юлында),
безнең яну-көюләргә,
исәпләргә, уй-гамьнәргә саңгырау еллар
кинәт айныр,
көч уяныр,
фикер торыр,
акыл артыр...

Кайтмас безне эзләп,
Сак-Сок моңы белән,
яхшы авазлар йөрер каңгырып
җирдән — җиргә,
офыктан — офыкка,
бушлыктан — бушлыкка...

*1967, декабрь*
*Самара*

* * *

Теләге бәхеттә иде,
хыялы тәхеттә иде,
йөргәне — бәрхеттә...

Морҗага кош ояламый.
Бәхет тә шулай икән:
төкергән тәхетенә!

Теләге иде бәхеттә,
хыялы иде тәхеттә,
хәзер ята ләхеттә.
Тәне, дөрес, бәрхеттә...

*1967, декабрь*
*Самара*

* * *

Юмаладың чегән карчык:
учымдагы сызыклардан
киләчәгең карыйм, диде.

Учым ачтым.
«Менә — бәхет сыры,
менә — ак юл эзе,
менә — сөйгән ярың», — диде.

Ә мин аның
яргаланган маңгаена карап тордым.
Бәхетсезлек сызыклары,
азаплы юл сызыклары,
ялгызлык сызыклары...

*1967, декабрь*
*Самара*

## ӘЛЛӘ ИНДЕ...

Йөрисең,
күрәсең...
Тагын йөрисең,
тагын күрәсең,
ишетәсең...

Кояш тотылгандай,
кайчак килә башка шомлы уй:
әллә инде бу дөньяда
иң үсемле,
иң камил фән —
үтерү фәне?..

*1967, декабрь*
*Самара*

## КИРЕСЕНЧӘ БУЛСА ӘГӘР...

«Тигезсезләр җирдә
тигезләнер — гүрдә!»
Нинди матур ялган!

Әгәр киресенчә —
(ялганга бит барыбер!) —
«Бар да тигез — җирдә,
тигезсезлек — гүрдә!» булса,
руханилар шулай тукынса,
Кешеләр
Җир хәлләрен күрер иделәр дә,
үз хәлләрен белер иделәр дә,
Көрәшчеләр күбрәк,
тормыш ямьлерәк,
гаделлекләр артыграк,
дөнья матуррак
булыр иде!

*1967, декабрь*
*Самара*

* * *

*А. Хәлимгә*

«Бу юлларны сагынырбыз әле!
Тик кайтылмас бүтән менә...»
Әйе, сагынырбыз. Вакыт — Алла.
Ә без бары кеше генә...

Ә шулай да без — без булырбыз гел!
Дәрте калыр, дәрман бетсә дә!
Изүләрне чишеп юл чыгарбыз,
Илдә зарыгып безне көтсәләр...

*1968, гыйнвар*
*Әгерҗе*

* * *

Үлемнәре белән үлемсезлек
яулап ала безнең шагыйрьләр.
Кемдер сорар: «Кая дәлилең?»
Мин эндәшмим.
Каберләре әйтсен
Тукай,
        Кәрим,
                Кутуй,
                        Җәлилнең...

Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!
Гомерләре булды, һай, кыска!
Ә бит үлеп үлемсезлек яулау —
бердәнбер юл түгел тормышта...

*1968, 3 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Гөлем идең, яктым!
Синең иң соңгы хатыңны
кырга чыгып яктым.

Соң нигә калтырый тәнем?
Ә төн җылы, тып-тын...
Пышылдаулар ишетелә:
«Әллә инде шаштың?..»

Күңелемдә караңгылык,
ә йөземдә — якты.
Уттан түгел, ул — кайчандыр
син кабызган чаткы!

Хискә кысан булмасын дип,
кырга чыгып яктым...

*1968, 5 гыйнвар*
*Казан*

* * *

*Солдаттан әйләнеп кайттым,*
*Әмәт тавында Ай*
*тамчы да үзгәрмәгән.*

Бераз үзгә, бераз бүтән, —
әллә ябыккан инде?
Йөзендә буйлы күләгә, —
әллә яулыктан инде?
Күзеңдә сабырлы сагыш, —
газаплы көткәннәнме?
Керфекләреңне аралап
күп көннәр үткәннәнме?
Җир ич! Язлар, гөрләвекләр
үзенекен иткәннәрдер.
Безгә, ятимнәр юк сана дип,
сипкелләр сипкәннәрдер.
Сынапмы ятлар, болаймы,
күңлеңә чирткәннәрдер...
Шулай да татлы ашкыну,
сагыну, өмет ташкыны
сүнеп үк җитмәгәндер.
Калгандыр нәрсә дә булса
күңелең юшкынында.
Ахыр чиктә шатлыгыңнан
елаган кич турында
хәтереңдәдер, яшь һәм яңгыр
яңагың чылатканы,
мин сине, ә син үземне
арганчы елатканы;
татулашкач, сабыйлар күк,
җитәкләшеп кайтканы...
Калгандыр нәрсә дә булса,
шулаймы? Әйт, яшермә!
Юк булса, — горур китәрмен, —
Куралмассың яшем дә!

*1968, гыйнвар*
*Казан*

# Әмәт дәфтәреннән

*Ерак Кабан күле өстендә*
*йөзә кучмә утраулар...*



* * *

«Дәшмәү — алтын».
Кайчак дәшмим.
«Дәшмәү — сәнгать».
Кайчак дәшмим.
Иреннәремә тимә!
Өне юк икән димә!

Сез ишетмисезмени?
Яр салам мин,
нәгъра орам!
Дан җырлыйм,
йә ләгънәтлим
күкрәүләр,
гөрелтеләр —
шарлавык сулар аша!

Бу — бүген.
Бер көн үзләре
аваз-күкрәүләр килер дә
атлыгып шаша-шаша
яңгырар безнең аша!

*1968, 11 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Бастырма аны
ташка!
Менмә кели
машка.

Менеп алса
машка,
утырачак
башка.
Төкерәчәк
ашка...

Күтәрмә аны
ташка!

*1968, 15 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Менә без дә үсеп җиттек, әни!
Кыр казлары, элеккечә,
түбәбездән үтә икән.
Күк һаман шул,
казлар гына менә...

Менә без дә үсеп җиттек, әни!
Сабантуйлары, элеккечә,
тау башында үтә икән.
Тау һаман шул,
кызлар гына менә...

Менә без дә үсеп җиттек, әни!
Син әллә ни үзгәрмәгәнсең,
элеккедәй мөлаемсың.
Күзләр гел шул,
яшьләр генә менә...

Менә без дә үсеп җиттек, әни!
Беркөн безнең ярларга да
оныкларың килеп әйтер:
«Менә без дә үсеп җиттек, әни!»

Бар да әйбәт, әни.
Моңсу гына бераз...

*1968, гыйнвар*
*Казан*

## КАРТ ШАГЫЙРЬ

Шәфәкъләр алсу-алсу,
Дөньялар ямансу.

Әй күкләр зәңгәр, зәңгәр!
Күзләрдә яшьләр, яшьләр...
Ни кичкәнбез, ни уйда без
бик аз беләсез, яшьләр.

Әй җирләр яшел, яшел!
Күңелдә сагыш, сагыш...
Кем яд итәр үзегезне,
сез безне онытсагыз?..

Әй сулар ярсу-ярсу!
Эчләрдә ялкын-ялкын...
Без китәбез, кала өмет,
акларсызмы ил хакын?..

Шәфәкъләр алсу-алсу,
дөньялар ямансу.

*1968, гыйнвар*
*Казан*

## УЛ КӨННӘРНЕ ИНДЕ ДАУЛАП БУЛМЫЙ...

Ул көннәрне инде даулап булмый...
Сагынып кына була!
...Сөю ни икәнен белми гомерең узса, —
каплан да бер ела.

Сүнгән еллар исәбенчә, тезеп,
кара шәмнәр кабыз.
Кешеләрне ку! Хет тынлыкта кал, —
син барыбер ялгыз...

Ул елларны инде даулап булмый...
Сагынып кына була!
Үткән бөеклеккә кайтып булмый, —
табынып кына була...

*1968, 4 февраль*
*Казан*

* * *

*Т-га*

Мин көрәшмим синең белән,
син тиң түгел...
Тик рәнҗемә!
Яхшылыкта күңелем.
Беләм: яшьлек-картлык
безнең
ихтыярда түгелен.
Көрәшәсең киләдер дә,
ә соң минем ни хата?
Карт белән яшьнең алышы
хупланмый безнең якта.
Тор урыныңда: күзәт, төзәт
аксакал күзең белән;
дәртләндер, кузгат яшьләрне,
илһам бир сүзең белән.
Канат куй! Өметне кисмә!
Мәгънә юк гөрзи белән!
Көрәшмик!
Тиле хисең уяныр да...
Миндә дә яшьлек каны —
үзем дә сизми калырмын
җан чыгарлык кысканны.
Күтәрермен дә дуамал,
уңайсыз төшәрсең күк.
Төшкән җиреңнән торалмый,
җиргә үк күчәрсең күк...
. . . . . . . . . . . . . .
...Җитәрлек җирдә исәрлек,
Акыл болай да китек.
Үземне ник кимсетим соң,
хурлыкны җиңү итеп?

Кичер мине!
Мин көрәшмим...

*1968, 4 февраль*
*Әгерҗе*

* * *

«Хакыйкать ул — авыр.
Авырлыгын шуның белү
җиңеллек тә җанга!» —
дия идең остаз.

Үлдең.
Бу — хакыйкать.
Моның авырлыгын белү
тагын мең-мең авыр...

Әй остаз...

*1968, 6 март*
*Казан*

* * *

Сөю көчле иманнан!
Чорнаса мәхәббәт-ялкын —
котылуың юк аннан!

Әхлак кануннарын көйләп,
тукысалар да туганнан,
Яз һәм Яшьлеккә вәгазь ни? —
сөю көчле иманнан!

Яшен-күкрәүләр тын кала,
ярсу хис ташса җаннан.
Җилләр калтырап кабатлый:
сөю көчле иманнан!

Кабынса мәхәббәт уты
котылуың юк аннан!

*1968, 11 март*
*Казан*

* * *

Кешелек язына
            йөз төбәп
            барганда,
безгә —
Ныклык
һәм Матурлык!

Җилме син?
Бәр! Бәр!
Бозмы син?
Бәр! Бәр!
Мәрмәр
барыбер
мәрмәр!

Замана һәр буынга
куя олы эшләр.
«Сезнекеләр нишләр?
Сезнекеләр нишләр?»
Кем шикләнә анда?

Аек кара сүзгә!
Төбәп кара күзгә!
Сынап кара йөзгә!

Җилме син?
Бәр! Бәр!
Бозмы син?
Бәр! Бәр!
Без — Мәрмәр!

Безгә —
Ныклык
һәм Матурлык!
Безнең иман —
Гуманизм!

*1968, март*
*Казан*

## ДӘРДЕМӘНДКӘ ТӘКЪЛИДӘН

Нинди мәхшәр!
Кайдан бу ут?
Җилкәннәр дөрләп яна.
Дулкын шаша.
Каек тулук, —
кайда Ул, кайда Ана...

Кораб баткан.
Каек эзсез.
Нинди ярдан аңгырык?
Кайсы якта
илсез, күзсез
кемнәр йөри каңгырып?..

*1968, апрель*
*Казан*

* * *

Минеке түгел сылулыгың,
аклыгың.
Минеке түгел күз яшьләрең,
пакьлегең.

...Чәчләреңнең каралыгы
бер уңар.
Йөзләреңнең аксыллыгы
бер сулар.
Төсләр, сине ташлап, күчәр
бүтәнгә...

Белмим, ул чак кем табыныр
бу тәнгә.

*1968, 9 июнь*
*Казан*

* * *

Яздым мәхәббәт турында
янып-көеп мин дә бер:
«Җир өчен — миллиардтан бер,
минем өчен — бердәнбер».

Дөньяның чын кадерен
тик сөйгәндә беләсең.
Яздым мәхәббәт турында, —
яшим әле, күрәсең.

*1968, 9 июнь*
*Казан*

## ТУКАЙЛАРНЫ УЙЛАП

Шагыйрьләр аз яши, диләр.
Без озак яшәтик!
Күгебезгә менгезик
һәм яшьнәтик!

Җырчы шагыйрьләр аз яши.
Тираннар — озак.
Нигә карга озак яши,
ә былбыл — азрак.
«Табигать бит!» — дип кеткелди
башлы бер корсак.
Җырларны да май басу бар,
битараф торсак.
Яшәсен шул — кем чын сөя
Җирне һәм Күкне.
Җирдә шагыйрьләр санаулы,
яшәүче күпме!
Яшәсен шул — хаклык өчен
кем җанын сала.
Кем, яшим дип, сата җанын —
тиз үлем аңа!
Түбән җаннан архивларда
доносы кала.
Шагыйрьләрдән — шигырьләре, —
намусы кала...
Шагыйрьләр гомерсезлегенә
кем соң гаепле?
Пушкин, Тукайлар язмышын,
Лорка, Җәлилләр язмышын
без белмиекме?
Аларны саклый алмаганга
горур йөрикме?
Берничә генә меңме ул,
йөз миллионмы, —
шагыйрьләрен сакламаган
халык зурмыни ул!

Саклыйлар бит алтыннарны,
биналарны, шәрабларны
һәм каберләрне...
Нигә сакламаска
чын шагыйрьләрне?
Мактауны гел калдырмыйк
үлем ягына.
Кадерлене кадерлик
исән чагында!

Шагыйрьләр, имеш, аз яши.
Ә без яшәтик!
Күгебезгә менгезик
һәм яшьнәтик!

*1968, 8—10 июнь*
*Казан*

* * *

Өндәде,
чакырды,
әйдәде,
кычкырып йә үксеп...
Ишетмәделәр.
Гомер кичте
җирдә ялгыз җирсеп.

...Җеназасында халык күп:
урам — тоташ агым:
чынлап аңлауда шәхесне
беренче зур адым.

*1968, 25 июнь*
*Казан*

* * *

*Аклыны бирдисә? —*
*ак яра җанда.*
*Каралыны бирсәң —*
*карасы...*

Аһ, аеклык! —
Бар да аныклык!
Кешеләр — аксым, матдә, җисем...
Җирдә аек акыл ташса, әй Күк үкси:
«Сөю әмер үтәп йөрсен...»

Аһ, исәрлек!
Күк шаркылдап көлә!
Җирдә — уйнаш, сугыш, рия...
Кара көя Җир,
тетри
һәм оятыннан
асыл акылларны җыя
туфрагына кире...

*1968, 25 июнь*
*Казан*

* * *

Нәкъ минем күк кеше юктыр.
Хыяллар буенча охшашлар,
холыкка һәм төскә тартымнар,
яну-көюләре белән миндәйләр
байтак булганнардыр җиһанда.
Әле дә бардыр.

Элгәрләре ниләр эшләп киткән бу тормышта?
Исәннәре ни уйда бүген?..

Олыгая барган саен
күңел —
тыныч түгел.

*1968, 29 июнь*
*Казан*

* * *

Килерме
һәлакәт?

Янартаулар атар,
тетрәүләр кубар алдыннан,
хәвефләнгән кошлар шикелле,
күңел сизгечләре тынычсыз.

Килә калса,
нинди һәлакәт ул?
Бар дөньягамы?
Япа-ялгыз үземәме?

Моны ачыклау мөһимме соң?
Дөнья җимерелсә —
миңа һәлакәт,
үзем аусам —
барыбер миңа...

*1968, 29 июнь*
*Казан*

* * *

— Нигә дип килдең син, Кеше,
яр ягасына?
— Карыйсым килде дулкынның
ак ярасына.

— Кешенең ни эше дә күбекнең
кешедә ни эше?
— Ярама иш яра күргәч,
нишлим: мин — Кеше!

*1968, 8 июль*
*Казан*

* * *

Төн бастырып куйдымы сине
ак күлмәгең белән ак ярга?

Ак болытмы син?
Әллә ак мизгел?
Әллә ак яра?..

Ә аста
әй шашты соң дулкын!
Әй шашты!
Колачлары — буш...
Әй шашты!
Үртәлеп бәрелде ярларга,
чигенде ярлардан
сыкрап, сулкылдап,
яңадан
тугланды, аунады...
Ул ярдан төшәр!
Төшәр!
Төшәр!
Ә син, йолдызларга карап,
һаман тордың ярда.

Әллә ак болыт?
Әллә ак мизгел?
Әллә ак яра...
Мин дулкында идем.
(Әллә дулкын үзем идем?)
Ярда тору кирәк булган
синең белән,
йә икебезгә дә
дулкын кочагында...

*1968, 8 июль*
*Казан*

* * *

Мин, ахры, изгеләштерәм
бик гап-гади нәрсәләрне.

Ник дип ашыктың син шулкадәр?
Ник теләдең тилертергә
ерагайган саен якынаеп?
Ул мәл сиңа
иң кирәк җир шул идеме?
(Әйтик Суконныйның бер почмагы.)
Мин баскан җир ят идеме?
Һәйкәленнән Тукай, күреп,
безгә сөенеп тора иде...
Ә син киттең,
үзеңнекен иттең...

Мин, ахры, изгеләштерәм
бик гап-гади нәрсәләрне,
катлауландырам, ахры.
Үз иркемнәнме,
ирексездәнме?

Утырдың да киттең,
ә мин калдым
зуп-зур шәһәр уртасында
япа-ялгыз...

*1968, 9 июль*
*Болгар*

* * *

Без, ахры, гыйбадәт кылдык:
тезләр тездә иде, күзләр — күздә...
Әллә егерменче гасыр,
әллә мәҗүсилек бездә?

Нинди табыну бу? Сүз юк,
өн-тавыш юк, хәрәкәт юк...
Җанда бөек иреклелек —
сыкрану юк, һәлакәт юк...

Күк!
Нигә пышылдыйсың бер үк сүзне:
«Сез бер-берегезгә түгел!
Сез бер-берегезгә түгел!»
Күк!!

Күк ишетми...
Әйтче Күккә, күңел! «Без —
Кешеләр, җансыз маллар түгел...
Безгә рәхәт бу мизгелдә...»

Әй Вакыт!
Тамырларым буйлап йөгереп
тукыйсың:
«Белегез!
Белегез!
Бәхетле мизгелегез
үтә, үтә...»

Вакыт! Туктап тор аз гына!
Рәхәт табыну кешенең
гомерендә
нинди аз була!
Күк һаман пышылдый,
Вакыт һаман тукый.
Урман сагаеп тыңлап тора.
Җил шуышып арага керә...

Без, ахры, гыйбадәт кылдык.
Күңел тулы яшь, күздә — бер тамчы юк.
Мәхәббәт бар. Сафлык, сәгадәт бар...
...кавышу юк.

Бәхетебезне озатыр өченме
без гыйбадәт кылдык?..

*1968, 10 июль*
*Казан*

* * *

Нигә чыктың
һәлакәтле юлга?
Очрашачакны белә идең.
Мин-ялкынга нигә җил булдың?
Дөрләячәкне белә идең.

Нигә куркытмады сине вәхшилек,
Успен йортының кара рухы,
хәрабәләрнең өнсез каргышы,
чиркәү эчендәге шыксыз тәре,
әрвахларның сөякләре,
кызыл йөзле археологның зур пычагы,
исәннәрнең туклыгы һәм мәнсезлеге,
сөйләүләрдәге алдау, рия,
синең янда йөргән бер шагыйрьнең
саркып торган җан ярасы?..

Нигә һәлакәтле юлга чыктың?
Син әллә батырмы, кыз бала?

*1968, 12 июль*
*Казан*

* * *

Чакырдың да,
үзең киткәнсең...

Синең тәрәз каршысында
басып торам.
Буп-буш урам.

Йә,
бу мизгелдә
син нишлисең анда?
Көнләшүгә охшаш бер хис җанда:
«Син нишлисең анда?
Син нишлисең анда?..»
Мине оялткан күзләреңдә ни чагылыш?
Яңагымны иркәләгән кулларыңда ни хәрәкәт?
Яшем тамган күкрәгеңдә нинди сулыш?
Күземне үпкән иреннәрдә нинди сүзләр?
Ни җан белән яшәргә кирәк
нindiдер бер Борда! *

Монда бар да
яна синсез:
гөлләр яна,
төбәк-илләр яна,
таш пулатлар яна,
Идел, Кабан яна, —
бар да яна!

Басып торам
тавыш-тынсыз.
Эч тулы — яшь,
тик керфекләр генә дымсыз.

*1968, июль*
*Казан*

* Казан янындагы Зеленый Бор күздә тотыла.

* * *

Күргән һәр сылуга мин гашыйк.
Телим ешрак очрауларын!
Сихерле гүзәл йөз өчен
мин әзер сәҗдә кылырга.
Матурлык киммени изгедән!
Бәхеттән —
көннән-көн күбәя чибәрләр,
күркәм йөзлеләр,
үзәккә үтәрлек күзлеләр...

Гашыйк булган саен
күңелемә нурлар тула,
тойгылар-хисләрем нечкәрә,
ышанычым арта үз-үземә.
Мәңге яшәр кебек хис итәм дә
тураямын. Күңелдә кояшлы ләйсән!
Күзләр йолдызлардан ары...
Һәм шул килеш кайтам сиңа —
сөеклем, бердәнберемә —
күпме аклык алып,
күпме пакьлек алып,
олыланып!

Әй, наз кояшым! Бу — мин!
Бик күпләргә гашыйк булып,
иңнәремә үскән канатларым белән
болытларны сыйпый-сыйпый
кайтып киләм —
бар зурлыгың белән каршыла!

*1968, июль*
*София*

## АЛМАЗГА

*Аталар*
*улларына калдыра,*
*васыять итеп,*
*эшкә ашмаган хыялларын,*
*кыла алмаган зур эшләрен.*
*Гел шулай.*
*Буыннан-буынга.*
*Кабул итәләрме уллары,*
*юкмы, —*
*аталар калдыра...*

Саумы, улым, —
чыгышым һәм баешым минем!
Исәнме син,
яңа Кеше!

Дөнья инде шушы була!
Йә, нинди ул?

Сиңа әле күпме төс күрәсе!
Күпме уй-хис кичерәсе!
Күпме мәгънә төшенәсе
һәм беләсе...
Бер әйтерсең үз сүзеңне
дөньяга.

Исәнме, улым!
Син гел мин дә,
мин дә түгел.
Бу күз-кашлар — ул син.
Бу аяк-кул — ул син.
Ә шулай да, беләсеңме,
син — мин.
Тәнеңдәге һәр күзәнәк
минем өмет белән тулы...
Мин дөнья бирдем сиңа,
һәм соралыр синнән
дөнья кадәр!

Менә шушы, безнең бу Җир.
Әйдә, таныш!
Күр,
        сөен,
                кайгыр,
                        яшә!

Үз иманың булсын.
Тик ул иман
сызып ташламасын минекен.
Мин — әтиең.

...Әгәр ялгыш
миңа якын кешеләрдән йөз чөерсәң,
мин сокланганнардан җирәнсәң,
мин табынганнарга сырт куйсаң,
мин сөйләгән телне,
мин көйләгән көйне онытсаң...

Юк! Юк!
Болай уйларга әле хакым юк!
Хыялларың минекеннән баш алыр, дим,
юлда калган арбамны син күкрәк белән
                                        этәрсең, дим,
күңелең минекеннән күп аграк
һәм сафрак булыр, дим,
кешеләрне яратуың күпкә артык,
кешелегең минекеннән зур булыр, дим, —
шуңа ышанып,
дулкынланып һәм куанып:
«Саумы, улым!» — дим.

*1968, июль-август*
*София*

* * *

Миңа бары бер җыр кирәк.
Әйдә, көн дә мине үксетсен ул,
ярсытсын, изрәтсен
йә тетрәтсен.
Әйдә, көн дә
үтерсен һәм терелтсен ул —
тик көрәшкә генә әйдәсен,
тик яшәргә генә әйдәсен!

Бары бер җыр кирәк миңа
бу тормышта,
бары бер җыр...

*1968, август*
*София*

## НИНДИ БЕТМӘС ЫШАНЫЧ БУ?

Янган-көенгән чакта,
башың иелгән чакта,
кайгың өелгән чакта, —
беттем! — дисең... Күзең ачсаң,
Вөжданың белән беррәттән
Ышаныч тора сакта, —
кешелегеңне саклап.

Нинди үлмәс Ышаныч бу!
Үтерергә теләп аны
эзли Мәкер, Өметсезлек, —
бетереп бар дөньяны.
Ә ул исән һәм сине әйдәр:
«Утыр, — дияр, — канатыма!
Югалма, туган, яшәрбез,
тормышны ярат кына!»

Нинди бетмәс Ышаныч бу!
Инде юктыр ул, дисәм,
упкыныма тау була ул
һәм яр сала: «Без исән!»
Тураям шундук, зурая
мәгънәм һәм максатым.
Илһамланам, бар җиһанга
таралыр күк яхшы атым!

*1968, август*
*София*

# Әлмәт дәфтәреннән

*Әмәттә дә шул ук Кояш,*
*Әлмәттә дә шул ук Ай!*



* * *

Яз төсе бу көздә!
Күренәме күзгә?..

Үсмер чактагыдан
дөнья шактый үзгә!

Табигатьтә яз-көз
элеккечә кана!

...Еллар үткән саен,
язлар җитми кала.

*1968, октябрь*
*Әлмәт*

* * *

Ярсыгансың, янгансың...
Кемгәме ачулангансың?
Кемнәнме үчең аласың?
Җиде кат төн уртасында
ялгызың кая барасың?

Ярамый димә, ярасын,
киләә саклап барасым.
Кемгәдер газиз бала син!

*1968, октябрь*
*Әлмәт*

* * *

Юатудан узган күңел.
Дөрес кенә сыя җанга.
Сүзең өзеп торып китсәм —
теләсә ничек аңла.

Һәр чын инде сискәндерми.
Ә рия үтереп сала!
Ашың ташлап торып китсәм —
Теләсә ничек аңла!

*1968, октябрь*
*Әлмәт*

* * *

Гөлсарларда хәмер яна...
Өстәлдә ике буш кул.

Мәгънәсез һәм эзсез
тагын көн үтте безсез.
Мәгънәсез һәм эзсез...

Өстәлдә ике буш кул.
Тәрәзәдән күренә юл.
Кайларга китә икән ул?

Күз нурларын үзенә җыеп,
гөлсарларда хәмер яна...

*1968, 24 октябрь*
*Әлмәт*

* * *

Үсә алган һәрбер нәрсә
яна ала.
Ян син.

Мин каршы түгел.
Яндыр мине.
Мин каршы түгел.

...Күзләреңә карап әйтәм:
мин яратмыйм сине!

Үсә алган һәрбер нәрсә яна ала.
Җаның тели икән —
әйдә, ян!

*1968, 25—26 октябрь*
*Әлмәт*

* * *

«Булдыралмыйм! Хуш!..» — диде ул.
Кара яндың
һәм юандың:
«Үкенәчәксең!
Үкенәчәксең!»

Чыннан да бер үкенде ул.
Тик... башка өчен.

Сөенмә!
Ул да, синең күк,
бер бәләкәй юаныч табар.

*1968, 6 ноябрь*
*Әлмәт*

* * *

Төнге шәһәр буйлап йөрим,
мәйданнарга килеп чыгам.
Буш трибунадан, күтәрелеп,
кемдер нотык сөйләр сыман.

Ары китәм. Нәрсә мәйдан?
Аннан сөйли алыр кем дә.
Шагыйрь җанга иң чын мәйдан
үз халкының күңелендә.

Төнге шәһәр буйлап йөрим.

*1968, 7 ноябрь*
*Әлмәт*

* * *

Эшең юк, язган чакта мин
үксимме, әллә көләм.
Ничек язганымны бары
бер үзем генә беләм!

Япа-ялгыз мин. Бу ялгыз чак —
иң бөек хөрриятем.
Вөҗданым белән сөйләшәм, —
шул минем шигъриятем.

*1968, 10 ноябрь*
*Әлмәт*

* * *

Җанга якын җаннар китә тора.
«Яшәгез, яшьләр! Афәрин!» диючеләр,
җилкәдән кагып, безгә юл бирүчеләр
китә тора.
Күбрәк —
        килүчеләр,
                килүчеләр,
                        килүчеләр...

Суксаң — тимер өзсәң дә,
бассаң — бакыр изсәң дә,
үзеңне Салсал батырдай
йә Алыптай дисәң дә, —
юл чыкканда изге теләк
теләүчеләр кирәк икән.
Аталарча фатихалар
бирүчеләр кирәк икән!

Җанга якын җаннар китә тора.
Килүчеләр, килүчеләр, килүчеләр...
Без аларны каршы алганда
сөенешеп һәм кул биреп,
искә төшә безгә фатихалар биргән
аксакаллар, ил картлары.
Боекканнар, имеш, пышылдыйлар кебек:

«Фатиханың ахыры бәхиллек,
фатиханың ахыры бәхиллек...»
Кылган эшләр бәхилләрлекме?
Җанга якын җаннар китә тора...

*1968, ноябрь*
*Әлмәт*

* * *

Дөньяда, һай, күп кирәк!
Горур башка — күк кирәк!
Аякларга — җир кирәк!
Күңелкәйгә — ил кирәк!
Күзкәйләргә — ямь кирәк!
Иреннәргә — тәм кирәк!
Горур жанга ни кирәк?

Лаек биеклек кирәк —
...абынсаң, очар өчен...

*1968*
*Әлмәт*

* * *

«Монда тыныч! Монда ямь-тәм!
Калыгыз монда!..»

Безгә шул ары барырга!
Ары барырга!

«Монда сөю! Монда җәннәт!
Анда сезне ни көтә?»

Кеше булып кала алсак,
шул җитә.
Шул җитә...

*1968*
*Әлмәт*

* * *

«Сафлыкка өйрәнәм Сездән,
язганыгыз гел-гел пакь...»

Юлда йә өйдә кайчак
искә килә шушы юллар, —
күз алдымда синең хат.

Синең, ахры, иң рәхәт чак,
сагышсыз, тәүбәсез чак!
Сеңлем, син үзең Сафлыктыр,
язган хатың бигрәк ак!

Кеше үткәнен сагына,
кайтмасын эзли күп чак.
Газиз югалтулар миндә
булганнар, бәлки, шуңа да
ярсына күңел-учак?
Бәлки, шуңадыр, язганнарым
артык ак һәм артык пакь?

Өстәлемдә синең хат.
Әллә син хак,
әллә мин хак?..

*1968*
*Әлмәт*

* * *

«Зинһар, кит!» — дисең,
газап белән...
Беләм...

«Син — чит! Чит!» — дисең,
Нишлим соң?
Күзләрең: «Иң якын», — ди.

Шулай да мин китәм.

Әйдә,
үз-үзеңә карыш —
теләкләреңне бу,
хыялларыңны җимереп тор,
хисләреңә зынҗырлар сал —
үз-үзеңә сугыш ачып,
үз-үзеңне җиңеп кара!
Тик шулмы
кешелеклелек!..

*1968*
*Әлмәт*

* * *

Аһ, тау юклыклар!
Кыя юклыклар!
Үзән, калкулыклар —
күз текәмә кая...

Бөркетләр түмгәктә
канатларын кага...
Тырнаклары чумган...
Ә күзләре яна!
Биектән бөтенләй
башкача күз алды.
Күзләрдән оят булыр
күрмәсәк дөньяны.
Карсак калкулык та
күз сирпешен киссә,
«Мин давыл!» дип, янда
мескен җилләр иссә...
Биектән башкача —
гөл дә, чүл дә, ил дә.
Тау да, үзән дә бер
тик җебегән иргә.
Бөркетләр түмгәктә
канатларын җилпи:
басар кыя җитми,
менәр күге җитми.
Таңнарын бөркетләр,
ай, ничек очына!
Таң гүя тау! Менмәкче
шул тауның очына.

Аһ, тау юклыклар!
Кыя юклыклар!
Күз текәмә кая —
үзән, калкулыклар...

*1968*
*Казан*

* * *

Имеш, күктә фәрештә!
Юк ул күктә фәрештә!
Безнең хыяллар анда
җирдә ашмаганы эшкә
ашканнар шулай өскә...

Хыялларга күк тыныч,
юк бернинди куркыныч.
Анда алардан көлмиләр,
анда аларга иркенлек,
чын ирeклек, чын хөрлек!
Кимсенү, читенсенү юк,
шикләнү, чикләнү юк.

Имеш, күктә фәрештә.
Юк ул күктә фәрештә.
Җирдә була фәрештә,
Алла булган һәр төштә.

Ә күктә, биеклектә —
анда безнең хыяллар...

Сирәк карыйбыз күккә,
Җирдә мәшәкать күпкә.
Күктә ярты дөньябыз —
зәңгәрлекләр, аклыклар,
ак болытлар, сафлыклар...

*1968*
*Әлмәт*

* * *

Йоп-йомшак иреннәрне
ихтыярсыз йомдыралмый
нинди каты көч тә.
Кыра алмый бер эш тә —
ни патша,
ни канун,
ни су,
ни ут...

Фәкать туфрак,
йомшак туфрак кына
яба ала
кеше авызын.

*1969, май*
*Әлмәт*

* * *

Мөмкинлегең — чигең узып,
тәкъдирең — язганың бозып,
күкләреңне биегәйтеп,
һәммә тарлыкны киңәйтеп,
алга барыш.

«Нинди көч бу?! Каян килә!»
Иш кыланып, син төпченмә!
Иманы, хыял-теләге
көчле булган үзе белә.

*1969, 4 июнь*
*Әлмәт*

## ОЧРАШКАЧ

Иреннәрең тетрәде...
һәм яшь тәгәрәде.
Аңыңа кил!
Яле! Көл!
Яле!

Бик азга гына булса да,
без бит
бергә әле!
Бар язганы белән алда
тулы
гомер әле!

Кадер генәм!
Риза булчы Шатлыгыбызның
килгән кадәренә!
Акыллы бул!
Өстебездәге
тургай кадәр генә!
Акыллы бул!..

*1969, 7 июнь*
*Әлмәт*

* * *

Мин ашыккан, син соңарган...
Әгәр киресенчә булса да —
соңаручы мин фәкыйрь —
өмет тергезер идем,
һаман күңелдәге «Синне»
мең кат хисләр арасыннан
өскә менгезер идем
һәм чабар идем шашып!

Ах, соңаручысы шул син...

*1969, 12 июнь*
*Әлмәт*

* * *

Кадер, бәя, чын хак,
кайчак
иясеннән, һай, ерак!
Берәүгә таҗ буласы сүз
бер туң җанда — олтырак!..

Дулкынын мәңге югалткан
ялгыз акчарлак сымак
килә ул кадер. Тик бик соң.
Куныры кайтмас — ерак!

*1969, 20 июнь*
*Әлмәт*

* * *

*Университет сабакташым*
*Зариф Халитов истәлегенә*

Төбәгән максат юлында
кыю адым атласаң,
һәммә кеше инанырлык
юньле бер эш башкарсаң,
бәячедән макталсаң, —
капылт сине күреп алып:
«Тәбриклибез! — диләр, —
Сезгә яңадан-яңа
уңыш телибез!» — диләр,
аз-маз күз күргәннәр,
тирәндә йөргәннәр,
тагын әллә кемнәр...

Әй юксынам шулчак чын дусларны!
Ә кая алар?
Кайсы калган,
кайсы югалган,
кайсы бик ерак,
кайсы — инде туфрак...

Минем ише генә иделәрме
ул дусларым!
Ул зиһеннән дисеңме,
ул гайрәттән дисеңме,
ул куәттән дисеңме...
Җыя алмассың исеңне!

Кайсы калган,
кайсы югалган,
кайсы бик ерак,
кайсы — инде туфрак...

бергә юл башлаганнар,
иңнәрне иңнәргә терәп,
тормышка ташланганнар,
сер, икмәк бүлешкәннәр,
беравыздан бер җыр җырлап,
елашкан, көлешкәннәр!

...Уңышың булса, әйткән дә юк, —
җанда шатлык өере!
Әмма барыбер бар күңелдә
сагышның бер төере —
юксыну чын дусларны.
Ә соң алар
минем ише генә иделәрме!..

*1969, июнь*
*Әлмәт*

* * *

Әти эшләгән җирләр бу.
Әти казганган өйләр.
Кешеләр әйтә: уллары да
яхшы ат казанган, диләр.

Бер әти үзе беләдер
ни ат казанганнарын.
Эндәшми тамырлы куллар,
сөйләми чаллары аның.
Бары бер үзе беләдер,
күпме мал, даны барын.
Тормыш атын ничә җигеп,
ничә кат туарганын...
Әти эшләгән җирләр бу.
Әти казганган өйләр.
...Яшь бара безнең дә. Инде
күрелде җирләр-илләр.
Әти гел ир, ә без әле
һаман да сабый ирләр;
һаман әле әти бара
давылның уртасыннан.
Без һаман тормышның әле
тыныч каютасында.

...Урам. Әнә әти. Бара.
Сизәме: карап торам.
Бара. Мәшәкать дәрьясында
билгесез кораб сыман.

*1969, июнь*
*Әлмәт*

* * *

Йөгереп-уйнап
ага Болак.

Камышлары — рәшәдә!
Казан өсте — ап-ачык күк,
Иделкәй янәшәдә!

Йөгереп-уйнап
ага Болак.

Чуерташлар — төбендә.
Тымык түгел, йомык түгел,
Болак гел саф күңелдә.

Таңда тор да,
ят та тыңла, —
җир астында чишмәләр!
Алар бит эндәшәләр!
«Идел-ана янәшәдә!
Безгә мәңге яшәргә!»

Йөгереп-уйнап
ага Болак!

*1969, 6 июль*
*Әлмәт*

## ХУШЛАШЫР АЛДЫННАН

Хөкемнәрне җиңеләйтә
дөресен сөйләү чын күнелдән.
Кылганнар ниятләгәннән
аерыла шактый. Беләм.

Акланмыйм. Юк. Бар ялгышны
таныйм. Сез дә киметмәгез.
Барым белән сезнең алда.
Хөкемегез көтәм. Ягез!

Артык хафаланмыйм. Чөнки
хөкем гадел булыр, беләм.
Мин, үзем ирешкән кадәр,
дөресен яздым, чын күңелдән.

*1969, 6 июль*
*Әлмәт*

## ЭТЮД ИДИЛЛИЯ

Кешеләр менгән Айга.
Ә без менә җайга
бу борынгы җирдә,
тамырланган илдә,
үзебез корган өйдә
тәрәз юабыз.
Шундый бездә йола:
язлар җитү белән,
халык өйләр юа.
Йөзләрдә — көләчлек,
табигатьтә — яшьлек!
Әле Кояш яна,
әле ләйсән ява!
Кызлар су ташыйлар
йөгерә-чаба.
Кыска итәкләргә
шук тамчылар тама...
Кем чыгарган йола?
Язлар җитте исә,
халык өйләр юа.
Юа бар җирен дә, —
калдырмый җеген дә!

Кешеләр Айга менгән.
Ә без җирдә менә
тәрәз юабыз
синең белән бергә.
Тыштан мин су сибәм,
эчтән син юасың.
Мин көлемсерим дә,
ә син елмаясың.

Гөрләвекләрмени
өлгеләр, рамнарда!
Күрәмсең, чистара!
Чистара! Тагын да
сафлана шикелле
икебезнең ара...

Җитсен киче генә,
йолдызлар балкышып
тезелгәч күгенә,
нәни улыбызны
уртабызга алып,
карарбыз тәрәзәдән,
бу айга таң калып.

*1969, июль*
*Әлмәт*

* * *

Һәр табуда күпме югалтулар!
Кыйммәтләнә ачыш-табышлар.
Һәр яңада бераз куаныч булса,
җуюларда азмы сагышлар!..

Дөреснең дә ниндие юк икән!
Җан ирешә алган ул хакыйкать
зурайтамы сине, ваклыймы,
керле итәме, әллә пакьлиме,
бала чакта җанга табигый
өерелеп тулган яктыны
җимерәме, әллә саклыймы —
(ялгышмыйммы!) — хикмәт шунда кебек.

Үз-үземне яңа тануым.
Мәгънәсен эзлим табуымның.

*1969, 15 июль*
*Әлмәт*

* * *

Суыр көн дә коллыгыңны!
Җаныңнан чыгар чөйләп!
Иреген тоеп суласаң,
исемең — Кеше, димәк.

Хөрлектән башлана Кеше.
Коллыгы аның — ләхет.
Куркып тереклек иткәнче,
хөр үлә белү бәхет.

Ирешкәч шушыңа, ничек
мин дөньядан бизием?
Юк! Җиһаннан, Табигатьтән
җанга хөр иш эзлимен!

Әйдә, сүзем, кылган эшем
шәбәйтсен хөрлегемне!
Шулай шәхсемне дәлилләп,
раслыйм ирлегемне!

*1969, 16 июль*
*Әлмәт*

* * *

Кызганам мин сине;
кара болыт суырырлык
аждаһа булалмадың! —
куркакларны сагайтырлык
бер юха булып калдың...
Күз-карашлар юк чагында
баш калкытып куясың,
зур язмышлар арасына
шуышып кермәк буласың...
Бәлки, шулчак аждаһадай
тоясыңдыр син үзеңне?

Кызганам барбер,
нибары —
юха гына булалдың!
Мөмкинлегең нинди иде!
...Табалмадың бугай җирлегең.

*1969, 27 июль*
*Займище*

* * *

Хак сүз, Тарих, гыйбрәтләр
өстә ятмый. Алсаң гына
чумып, мәрҗән эзләүчедәй.
Йөрәк таза, тын киң булып,
исән-имин калсаң гына...
Карама күзгә, — тонгандыр,
яңагым, бәлки, сулгандыр.
Карама беләкләремә!
Кара учка: бу — тапканым!
Кара тотып, тешләп, чиртеп!
Тик төпченмә — каян алган?
Ничек алган? Кайчан алган?
Иң мөһиме — түгел ялган!
Без эзлибез — шунда бәхет! —
туры карап хәвефебезгә.
Шуңа, ахры, шатлыгы да,
газабы да бөтен бездә.
Әй, сез, өстә йөзүчеләр!
Шактый оста йөзүчеләр!
Дулкын-күбек сөзүчеләр!
Сез Кояшның күзендәме?..
Үпкәләүдән биегрәк без!
Кирәк — ерак йөзәрлек без!
Кирәк — тирән чума алырлык!
...Төптә тәнне иркәләүче
суда дулкын була алырлык!

Кояшкамы тел тидерү! Юк!
Сөйсен дулкын йөзендәген!
Тирән төшсәң, «Кеше» дигән
кояш кыйбат үзендәге!

*1969, июль*
*Әлмәт*

* * *

Күктә — яшен!
Дәһшәт, шом!
Ярда — син —
алиһә сын.

Тузанга да
күрмәүме бу —
алла, күкрәве!

Син — зур зат, дип,
тибрәнә әнә
алма күкрәге!

Күктә — яшен,
ярда — син.
Кем сынамак
без — табигать
баласын?

Күкрәү. Тетрәү.
Ярлар ишелә!
...Илаһи, тын гына
сылу чишенә.

*1969, 18 август*
*Чуаш Кичүе*

* * *

*Дусларга*

Бәя җитмәс кешеләр сез, —
ә бәяләнәсез;
кемнәрнеңдер уйларында
меңгә әйләнәсез.
Инде бәя җанга, рухка
бәйләнгән икән,
кеше бәя чыгырында
әйләнә икән, —
куйсыннар бәяләрен, тик
асылыңа тиңен;
үз хакыңны бугазлап ал,
бирсәләр кимен.
Мут тегүчедәй, синекеннән
киенмәсеннәр!
Бәяңә кереп, исемеңә
төренмәсеннәр!
...Бәя икән бәя! Күрсеннәр,
ач җәүһәр-җаның!
Вакыт күзе үзе күрсен,
расласын барын!
Дусларым!
Бәя җитмәс җаннар! Моны
күпләрме белә?
Йокласа хаклык, аңардан
бармы мәгънә?
Вөждан рәнҗемәсен. Аның
хөкеме каты.
Ирме соң без, акламасак
исемебез хакын?!

*1969, 20—21 август*
*Чуаш Кичүе*

* * *

Хиссият илендә икәү,
әйдә, гизиек әле!
Теләк бакчаларыбыздан
гөлләр өзиек әле!
Иш килгәннәрен аралап,
бергә тезиек әле!

Әйтсәләр әйтерләр инде:
«Ярамый! Тыела!» — дип.
Тик соңыннан әйтмәсеннәр:
«Их, әрәм!.. Коелган...» — дип.

Тартынмыйча хөр йөрик бер
бакчабызда, үз булып.
Назга сусаган бер гөл дә
калмасын мәэюс булып.
Рәнҗемәсә кешелегең,
фатиха булса җаннан, —
тыйма мәхәббәт ташкынын
сихерле тыелганнан!
Әйдә, урнашсын бер мәлгә
синдә шәхси үз әдәп.
Бәлки, мәҗнүни бу мизгел —
бүтән кайтмас сәгадәт?..
Онытылып, иркәләнеп,
әйдә, бер йөрик әле!
Серле, тансык гөлләр өзеп,
уйнап, көлиек әле!

*1969, 5 сентябрь*
*Әлмәт*

* * *

Яңа казылган кабергә —
мәрхүм ятар урынга
төшмәсенме бер бомба!
(Солдат җанын кыйганы да
төшәр булсачы шунда!)

Тәэсирләндем мин моңа.
Бер-ике сүз тиеш таптым
бу «акыллы» бомбага.

*1969, 22 сентябрь*
*Әлмәт*

* * *

Боек дип уйлама син, төнбоек!
Килешмәс офтану
су гөле — син гүзәл
торганда
алдымда.
Җитмәсә,
ярым да
янымда!
Мин болай гына —
уйда гына...

Кабатланмас бу мизгелнең,
бу халәтнең
ни мәгънәсе гомеребездә,
Мәңгелектә?

«Кеше боек!» дип уйлама, төнбоек, —
мин уйда гына...

*1969, 25 сентябрь*
*Әлмәт*

* * *

Тугры дусың улмы, бумы?
Бүген кысышкан бу куллар,
егылсаң, сузылыр кулмы?
Тайпылсаң, бу нурлы күзләр
ялгышың төзәтер күзме?
Киләчәккә ант-вәгъдәләр
буш авазмы, ихлас сүзме?
Карыйм төбәп, карыйм сынап.
Күзләрдән — күңелгә ара
уйлаганнан күп чак ерак!

...Сындырып сыный дөнья.
Дусларны чәчеп җыям.

*1969, 25 ноябрь*
*Әлмәт*

* * *

Курыкма, биек оч, Кошым!
Күк чикне беләмени!
Көл, күңел! Дөнья моңы
бер безгә генәмени!

Оч, оч, Кошкай, кис җилләрне!
Шаш, Рухым, — дуласын җан!
...Егылсак — белгән-күргәннәр
яхшыга юрасыннар.

*1969, 8—9 декабрь*
*Әлмәт*

## СОҢАРГАН ШАҺИТ

Чабып килгән. Янган-пешкән.
Тормый сүзләр сайлап.
Яралы ярсу җаныннан
чыга сүзләр кайнап.

Ялварамы? Боерамы?
Ләгънәтлиме әллә?
Исәрме? Тәңреме? Сөйли
тетрәндергеч хәлләр!

Сөйли бөтен тәне. Бер яна,
бер куя күк өшеп.
Сүзе белән сер-төенне
ташлый гына чишеп!

Менә бит ничек икән ул!
Менә ничек булган!
...Вакыт үзе үкенүдән
илереп елар сыман!

Сөйли шаһит. Сөйли. Сөйли...—
һәрбер сүзе хәнҗәр!
Хак сүзен аның бүләргә
кыймас хәтта әҗәл!

. . . . . . . . . . . . . .

Их! Ичмасам, бер генә җан
тыңлый алса икән!
...Берәү дә юк. Карар чыккан.
Хөкемдарлар киткән...

*1969, 10 декабрь*
*Әлмәт*

* * *

Алдындагын кем дә күрер.
Күр төптәген, камылдагын!
Тел сөйләр ул... Ә беләмсең
күңелендәген, җанындагын?

Якты утларны кем дә күрер,
үрләтә бел үз учагың!
Бүген бер хәл. Күзаллыймсың
дөньяның безсез чагын?

*1969, 14 декабрь*
*Әлмәт*

* * *

Бәхетлеләр — ачык, киң күңелле,
риясыз, саксыз, ваемсыз.
Ә бәхетсез күп чак көчле көнче
һәм юкка да үче аяусыз...

Бәхетлеләр оныта, кичерәләр,
хөсетлелек нигә аларга?
Барсын күреп торган, һәр чак аек
бәхетсездән саклан дөньяда!

*1969*
*Әлмәт*

* * *

Артык бернәрсә дә өмет итмим;
хис — тыюлы, күңел — утырган.
Ә шулай да, үсмер чактагыдай,
бер тилереп алу ни тора!

Тик гадел бул, күрсен күңел күзең,
бу — хыянәт түгел, бу — яшәү!
Киткән яшьлегеңнең еракта бер
миһербанлы булып дәшүе.

Ихтыярың: йә көл, йә ачулан,
аңлый алсаң әгәр — рәхмәтем.
Унҗидедә, белмим, тоярсыңмы
сагышның бар ачысын, рәхәтен...

Дөнья матур! — безнең бүгенге күк!
Син көләсең, миндә уй да шом.
Нигә Кеше Олы Матурлыкның
бик азына гына хуҗа соң?

Бик азына... Син минеке түгел.
Сау бул!

Каргыш кануннарга яусын!..
Барсы өчен рәхмәт әйтәм бары,
син дә, яме, алгысынмассың!

*1969*
*Әлмәт*

## БӘЛКИ, СИН...

Бәлки, син — минем җырланмас
иң гүзәл җырымдыр?
Бәлки, син — минем чыгалмас
иң данлы юлымдыр?

Бәлки, син — минем меналмас
иң биек күгемдер?
Бәлки, син — күтәралмас
гомерлек йөгемдер?

Бәлки, син — минем беркайчан
кул җитмәс кошымдыр?
Бәлки, син — үзем аңламас
бәхетем алкышыдыр?

*1969*
*Әлмәт*

* * *

Чыныгаммы, күнегәмме?
Күнегәмме, чыныгаммы?
Шуны анык белми яшәү —
кисә җанны, сыга җанны...

Бер тәгъбир йөри күнелдә,
сүз булып та менә телгә:
«Һәммәсенә күнгән кеше —
җиңелүгә дә күнә.
Һәммәсенә күнгән кеше —
җиңелүгә дә күнә».

Яшим. Тормыш-эземнең
шыксызлыгы бар, бар — яме.
Монсы бер хәл. Иң мөһиме —
чыныгаммы, күнегәмме?..

*1969*
*Әлмәт*

* * *

*Р-гә*

Сабыйлык та картлык синдә,
егетлек юк!
Әйтеп ардым инде. Бүтән
үгетлим юк!
«Йомшак. Зәгыйфьмен. Булмый, —
дисең, — миннән».
Әйдә, тагын бер кат мин оялыйм
яшьлегеңнән...
Әйдә, тагын фәлсәфә сүт,
коштай сайра!
Мескенлекне гуман яса,
өстен сана!
Әйт, кирәк, дип, миңа фәкать,
фәкать тыныч!
...Җилдән мәхрүм тычкан тормышы,
һай, куркыныч!
Кирәк, диеп, тагын рәхәт.
Җиңел рәхәт!
Кем белә: бәлки, иң җиңеле —
җиңү рәхәт!
...һәм, ниһаять, моны укы да
хатасын тап!
Тап та тынычлан. Бу юлы да
мин, диген, хак!
Хәер, үзеңчә бул. Бүтән
үгетлим юк.
Мин нишлим соң? Чөнки тыңлар
егетем юк!

*1970, гыйнвар*
*Әлмәт*

* * *

Зәй буенда сугыш уены.
Ак халаттан бар да ак карда.
«Сугышчылар» хәзер бүленми
кызылларга яки акларга.

Бер сүз — «дошман» — һәр як өчен дә,
«дошманыңны» юк ит, из, тапта!
Юри сугышуны бик җитди
командирлар күзәтә «штаб»та.

Бер вахтадан кайткан егетләр
бер-берсенә каршы йөгерә.
Беренчесе «тереләй» алганчы,
икенчесе «атып» өлгерә.

Берсе «газ!» дип, яман кычкыра,
сигнал бирә ракета чөеп.
Кайсы ава, кайсы йөгерә,
башларына маскалар киеп.

Зурлар уйный, зурлар мәш килә!
Тавышлары ишетелә Бигәшкә*.
Малай-шалай килгән карарга.
Күбесенә булыр ун яшьләр.

Авызларын ачып басканнар,
онытылган чана шуасы.
Зурлар булып зурлар уйнагач,
малайларны ничек тыясың?

Малайларга кызык: «Урра!»лар
тәэсир итә әле, җилкетә.
«Сугыш» бетеп, өйгә кайтуга
йомшак күмәч, җылы сөт көтә.

---

* Б и г ә ш — авыл исеме.

...Карт солдатлар бара азаеп.
Солдат уенында — яңалар.
Әллә инде сугыш зәхмәте
буыннарга күчеп ярала?..

Зәй буенда сугыш уены...

*1970, 8 март*
*Әлмәт*

* * *

Җирдә — аклык, җанда — шатлык!
Беренче кар, беренче кар!
Баш — бүректә, бүрек — күктә!
Беренче кар, беренче кар!
Чана-чана бала-чага —
беренче кар, беренче кар!

...Малай чакны искә төшергән
һәр нәрсәдә изгелек бар.
Эшләпәмне салып торам,
беренче кар, беренче кар!

*1970, 22 март*
*Әлмәт*

* * *

*Сиңа,*
*Батаган истәлеге итеп*

Адаштык. Төн килә өскә.
Урман — кара, җил — шомлы...
Ни өмет караңгы Җирдә?!
Күк, табышсана юлны!

Күктә дә капкач болыт шул,
ул да — йолдызсыз, ятим.
Яңгыры кемгәдер шифа,
тик безгә — каһәргә тиң.

Бар тирә-як шомда, ымда,
нидер сагалый сыман.
Кайдадыр Алмазга охшаш
яшь бала елый сыман.

Ниндидер көч көлә кебек:
«Нишлисез инде, ягез?..»
Куанма: болар сансыз дип,
без дә кемгәдер газиз!

Адаштык шул. Ярый син бар.
Ярый син янда гына!
Барабыз икәү — йөз ачык —
билгесез алдагыга.

*1970, 23—24 апрель*
*Әлмәт*

## МӨТӘГАЛИМГӘ

Көчерәсең дә язасың,
язасың да ятлыйсың.
Әйтерлек бер үз сүзең юк,
үзең галим атлысың

— Гыйлем бит ул — тирән һәм киң,
дәрьяга тиң,— дисең,—
вакыт җитми! Кешенең шул
бер гомер, бер ми,— дисең.

Заман куйган олы эшләргә
вакыт табучылар бар!
Юллар салучылар бар!
Янып калучылар бар!

Беләсең, юктан бар булмый,
бардан да булалмый юк.
Бер булганны бар диюдән
ил дә, фән дә булмас тук.

Үзең, бәлки, булырсың тук,
атларсың эре-эре.
Халкыңның уй-хисеннән
еракта — читтә йөреп...

...Ә гомер үтеп бара,
чәчләрең бетеп бара.
Инде үзең булып карарга
бик вакыт һәм бик пора!

*1970, 21 май*
*Әлмәт*

## БУ СӨЮ

Бу сөю — диңгез икән дә,
иксез дә чиксез икән!
Туйганчы талгын йөзәргә
гомер җиткесез икән...

Бу сөю — тормыш, яшәүнең
тылсымлы иле икән.
Кешедә гомер картаймас
җанның яшьлеге икән.

Бу сөю — бөек мәгънә —
бәхетнең үзе икән.
Аңа таба онытылып
гел чап, оч һәм йөз икән.

*1970, 23 май*
*Әлмәт*

* * *

Хыянәткә, ялагайлыкка,
хөсетлелек йә наданлыкка —
яшәгәндә без моңа шаһит! —
шак та катмыйм, гаҗәпләнмим дә.

Сихерләнеп һәм гаҗиз калып
гаҗәпләнгән нәрсәм дөньяда:
ул — бала.

Сафлыгына һәм гүзәллегенә
зиһенем ирешә алмый һаман да.

*1970, 26 май*
*Әлмәт*

* * *

*Гомерләре җыр булалган*
*Кешеләр — иң бәхетлеләр!*

Язсам гына яшәвемне раслыйм.
Юньле эшем — йөзем аклыгы.
Язсам гына — Җирнең улы булам,
сөелүгә-назга хаклымын.

Язсам гына — бәхтем тулы, бөтен.
Язу эше — намус, кан эше.
Язсам гына — илгә, кешеләргә
файда итсәм генә мин кеше.

*1970, 26 май*
*Әлмәт*

* * *

Азмы синдә байлык, кодрәт,
уен, җыр, шәраб, көлеш!
Көнләшәсең? Мин шул һаман —
мөлкәтсез, малсыз килеш...

Җан тынычлыгы малдамы?
Кыендыр шул яхшы атсыз!
Мәгънә юкмы көч-кодрәттә,
гомер кичкәч максатсыз?
Мин һаман шул. Элеккечә
рухым нык, юлым анык.
Күгәрченем бирмәскә исәп,
алмашка козгын алып*.

Күз камашырлык син тыштан!
Әйтүчеләр бар: һай, шәп!
...Вакытны, Хакны, Халыкны
танырга безнең исәп.

Без төрле шул, һәркем үзе.
Үзе дәрәҗәсендә.
Карама шулай мөлдерәп
кызгансам, рәнҗерсең йә.

*1970, 21 июнь*
*Әлмәт*

* Г. Тукайның «Үтенеч» исемле шигырендәге «Ак күгәрченне кулымнан алдылар, козгын биреп» дигән юлларына ишарә.

* * *

Сөйли. Җитди. Хак эш өчен
шәһит киткәнмени!
Хәер, үзеңне акларга
дәлил беткәнмени!

Мещан җанның фәлсәфәсе —
кадими фәлсәфә:
«Ничек яшәсәң дә яшә, тик
тук һәм рәхәт яшә!
Борчылулар, көенүләр,
тетрәүләр нигә?
Кеше фани дөньяга
яшәү өчен килгән!»

Куркаклыгын, пошмаслыгын
төбәп әйтсәң аңа, —
дөрес яшәвен исбатлап
ул мең җавап таба.

Ә нәрсә ул акланулар!
Хөкем залларында
«акланыр» сүзләре була
сатлыкҗаннарның да.

Намуслыга нигә аклану?
Нигә дәлилләрең!
Аклауга мохтаҗмы эше
Тукай, Җәлилләрнең!

Тормышның тәрәккыятен
син Тарихтан сора:
Дөнья — фидаи җаннарның
януында тора!
Яшәсә кеше янусыз,
тик үзе өчен һәм сак,
битараф та булса, ул —
потенциаль куркак!

Ышанма тасма телләргә,
кылган эшкә кара!
Суфи күк оеп торамы,
көрәшкәме бара?
Үз бурычын үтәгәнме?
Таләп ит һәм сора!
Гөлчәчәкле бакчабыз — Җир
кыл өстендә тора...

*1970, 2 август*
*Займище*

* * *

*С.С-га*

Җилләр уйный — триумф!
Кышка — алкыш.
Шәрә ботакларда
кызыл балкыш!

Миләшләргә карап
гаҗәпсенмә.
— Чәчәк — ялкынмы? — дип,
син ымсынма!

Хәтерлә: чәчәге
ап-ак иде...
Тик ул чакта көз түгел,
яз чак иде!

...Йөзең инде көздә.
Язда — күзең!
Бөреләнеп чәчәк
ату көзен —
хәерлеме, юкмы,
аңла үзең!

Җилләргә ни — шаша!
Кышка — алкыш!
Миләшләрдә ялкын —
көзге балкыш!..

*1970, 5 сентябрь*
*Казан*

* * *

Гөмбәзләре — кояшмыни!
Сары алтын — чиркәү.
Бабайларның күз яшьләре
менә кайда икән!

Төссез түгел күз яшьләре,
сары төстә икән!
Ничек ялтырый тәреләр!
Акыл — көчтә икән...

Безнең якта — борынгыдан
хәрабәләр генә.
Чын тарихны азлар белә, —
хәбәрдарлар гына...

Гавамга мирас — моң, сагыш, —
менә калган байлык.
Шулай да әле халыкта гамь,
байтак Тукайлык.

*1970, 7—8 ноябрь*
*Әлмәт*

* * *

Дан аты — холыксыз!
Дан аты — канатлы!
Ул чабар үрләргә,
онтылып, җан атып!

Тәкәббер башларны
ул чөеп күпме аткан!
Кайсысы — баш ваткан,
кайсысын — канаткан...

Ул сынар, син чыда!
Шанлы бу юлыңда
төшүең, төшмәвең —
баш белән кулыңда.

Аңладым: Дан атын
тезгенләү — көч икән!
Тыңлату дәвасы —
эш икән, эш икән!

*1970, 23 ноябрь*
*Әлмәт*

* * *

*Китапчы галимнәребез*
*Ә.Кәримуллинга, А.Фәтхигә*

Хәзинәнең сакчысы да,
хуҗасы да сез аның.
Сезгә, мөгаен, ачыграктыр
кая баруы дөньяның!

Чор-заманнарны үтәли
күрәлгән зирәк ирләр,
сезнең үлчәү, берәмлекләр —
гасырлар да дәверләр!

Кемнәре юк бу дөньяның!
тиңсезе, ятимнәре...
Рухи мирас бакчасының
сез — хуҗа, хакимнәре!

Еллар аша ничек күренә
безнең эшләр, янулар?
Бәләкәйме? Әйтәсезме:
«Бичаралар, фанилар...»

Әйе, кылганнар аз, мыскал...
Шулай да бер сүз — бездән:
«Без фанидыр, фаныерак —
максатсызлар, йөзсезләр!»

Хаклыкка якын торучы
әй, халык галимнәре!
Ил-йортның эшчән уллары,
милләтнең хадимнәре!

Дөнья бәһасе язу да,
мәкале, әйтеме дә,
мирасы — мәшһүр бинең дә,
бер дәрвиш хәкимнең дә —
язмышы сезнең хөкемдә!

Сезнең үлчәү берәмлекләр —
гасырлар да дәверләр!
Сезгәме соң тиңләшә ала
өч көн көчле Дәү ирләр!

Хәзинәнең сакчысы да,
хуҗасы да сез аның!
Сезгә, мөгаен, ачыграктыр
кая баруы дөньяның!

*1970, ноябрь*
*Әлмәт*

## КЫШКЫ БЕР КИЧ

*И-га*

Кыш башында каян килгән,
каян килгән язгы җил бу?
Гүя ишетелә: «Мин бу! Мин бу!
Үткән гомерең — мин бу!»

Әй, син, дымсу, ямансу җил!
Язлап кына килер булсаң!
Гомер үтүен тою авыр, —
килмәс идең белер булсаң!

Ләйсәннәргә ымсындырып,
күңелләрне ник кузгаттың?
Күзгә зәңгәрлек иңәр дип,
томырылып күккә бактым, —
анда кар һәм соры болыт...

Әй, син, дымсу, ямансу җил!
Язлап кына килер булсаң!..

*1970*
*Әлмәт*

* * *

Ни генә дә җиккесез!
Чапты заман — җиткесез!

Нинди ил юк, нинди җир юк
һәм кемнәр юк җиһанда!
Җисмән, белмим, рухи һаман
бар коллар да, би-хан да!

Тавыш тизлеге таман —
ыргылып чаба заман!
Ә үткәннәргә баксаң,
бүгенге биеклегеннән
киләчәккә күз атсаң,
бер инану — кемнәр белән
ничек чапса да заман,
асылы шул ук һаман —
беркайчан кабатланмас,
бер мизгелгә дә тынмас
көрәш! Үзәктә — Кеше —
язмышлар бәрелеше!
Бар үткәннәрне хурлап,
алдагын гына зурлап,
була ул җырлап көйләргә:
«Җиттек әллә ниләргә!»
Җитсәк тә әллә ниләргә,
барыбер иген игәргә,
тынычлык кирәк өйләргә,
бәрәкәт кирәк илләргә...

Кай заман куркактан булган
дөреслеккә юл яра алу?
Заманның һәм халкыңның
улы булып кала алу
бик җиңелме?
Бу — бүгенме?
Бу сүз әллә бик борынгы
берәр шагыйрьнең өнеме?

Ни генә дә җиккесез!
Чапты заман — җиткесез!
Төшәрләр Айны кыеп.
Нур түгеп һәм сагаеп
калды җиһан...

*1970*
*Әлмәт*

* * *

Төбенә төшеп уйлап баксаң,
бернәрсә дә куркыныч түгел.
Туу — Үлү дигән ике чикне
котылгысыз үтү һәркемгә.
Мәңгелекнең, фанилыкның да
мохтаҗы юк безнең хөкемгә.

Ахыр чиктә
бернәрсә дә куркыныч түгел,
бернәрсә дә...

*1970*
*Казан*

## ИДЕЛ АГА

Идел ага. Пароходтан —
акчарлаклар, таллар кала,
моңайган авыллар кала,
керәшәле ярлар кала.

Идел ага. Күпме аккан
ул Ра булып, Әтил булып,
Волга булып... Зур дәрьяга
халыклардан вәкил булып.

Идел ага. Кешеләр буса —
җәелеп ага, тулып ага.
Дулкын булып кына түгел,
Җыр-дастаннар булып ага.

Идел ага. Исе китми
дәверләргә, ялганнарга.
Гамь кирәкме каберләре
су төбендә калганнарга...

Идел ага. Ил барыбер
Идел-йортын онытмады.
Ярларында яши бирә
Идегәйнең оныклары.

Идел ага. Без агабыз.
Артта — маяк, саллар кала.
Култыкларда пристаньнар,
яулык болгап ярлар кала.

Идел ага. Ул — мәңгелек.
Кай елгалар кибеп кала.
Иделең белән акканда
җанда барбер өмет кала.

*1970*
*Казан*

## БҮГЕН — БОЛАЙ, Ә ИРТӘГӘ...

Яшьсең. Саусың. Көчең ташый.
Ил эше иңеңдәдер.
Тик, бәлки, син бу мизгелдә
яшьлегең чигендәдер?

Яр саласың: «Бүген мин иң,
иң бәхетле бер кешедер!»
Бу, бәлки, бәхет кошыңның
иң назлы җилпешедер?

Болар — бүген. Киләчәктә
нинди хәлдә күренерсең?..

*1970*
*Казан*

## ВАКЫТ!

Вакыт ныгырга,
катыланырга!
Бу дөньяда
атың алырга!

Вакыт, бик вакыт
бизәп җиреңне,
эштә расларга
егетлегеңне!

Вакыт —
үз-үзең
булып калырга!
Ил-Ватан кушса,
башың салырга!

Вакыт, бик вакыт
катыланырга!

*1970*
*Займище*

## КАРТЛЫК

Бу — тын култык, бу — пристань,
котылгысыз тукталыш.
Кая ди ләйсәнле язлар!
Монда бары көз дә кыш...

Дөрес, бай җир, монда акыл,
гыйлем, хикмәт — барысы да...
Тик алармы тиңләшә ала
тиле Яшьлек каршында!

Т-сс! Шаркылдама... Сак була күр
«яшьмен!» дип масаюдан.
Аралар төрле булса да,
бөтенебез бер үк юлда...

*1970*
*Займище*

## КОМЛЫКТА

Күк иңдеме?
Яңгыр, яңгыр...
Су ташкыны алдымда!
Кем санаган — күпме бөртек
комлыкта һәм яңгырда.

Нигә әле
яше, исәбе?
Җисемнәр,
җиһан күк — борынгыдан.
Мин менә вакыт кунагы, —
зур эштәй, бер уч коры комны
эземдә саклап торам...

*1970*
*Займище*

* * *

*Н. Исәнбәткә*

Яу-дауларны күргәннәр күп,
Көрәш-шауда җиңгәннәр күп,
Вакыт-яу — иң-иң яманы!
Җиңүчеләр сирәк аны!

Вакыт белән хезмәте тау
ирләр генә алыша ала.
Заман, иелеп, җиңүченең
шанлы исемен алып кала.

*1970*
*Займище*

## ЭЛЕГИЯ

Яшел бөре тәрәз алдымда,
кисәк-кисәк зәп-зәңгәр күк,
алтынсу нур,
чем-кара сыерчык ботакта;
ап-ак кәгазь өстәлемдә,
һәм мин басып торам —
һәммәсеннән өстен көч булып.

Кодрәтем — бу төсләр юк.
Кодрәтем — бу аваз юк.
Телим икән — берсе дә юк! —
Кодрәтем!..

...Беркөн яшел бөре булыр тәрәз алдымда,
өлгеләрдә зәп-зәңгәр күк,
алтынсу нур,
чем-кара сыерчык ботакта;
аз-маз сызгалаган кәгазь — өстәлемдә,
ә менә мин — юк...

*1970*
*Займище — Казан*

## КИЧЕРЕР ДИМӘ!

Кыланганда тойгансыңмы
ачуым кайнаганын?
Аңлыем дип, шагыйрь җанын,
гел кичереп бардым.

Минем аша шигырьләреҗ
дуслар отып алды.
Кемнәрнеңдер күңелендә
яхшы исмең калды.

...Тагын хәбәр синең хакта —
башка суктымыни!
Йә, син генәме? Илдә бүтән
яхшы юктырмыни?

Синнән алдан, исмең сызып,
яман хәбәр йөри.
Кемнәрдер сиңа рәнҗегән,
кемдер каргыш тели.

Уйла, мин дә яклавымның,
бәлки, чигендәдер...
Күңелем туңса, эрер димә,
Мәңге кичермәмен!

*1970*
*Әлмәт*

* * *

Космополит түгел.
Шөкер,
халкым да бар, ил дә, Ватан да.
Мин тынычмын: «татарныкы» диеп
төртеп күрсәтмимен ал таңга.

«Минеке» дип бүлмим күкне, айны,
мөһер сукмыйм ел фасылына.
Милләт исемен такмыйм урман-суга,
агач-ташның иң асылына.

Һәммә гашыйк, һәммә халык өчен
бар табигать — уртак матурлык.
Барыбызга да газиз Матурлыкны
бирәүнең дә
үзенеке ясар хакы юк!

Кояшка һәм Күккә бар да тигез.
Без табигать балалары ла!
Без һәммәбез тигез. Кая?
Кемнәр ак сөякле, зәңгәр канлылар?

Безнекеләр Ил-туфрак өчен
яуларда баш салмадылармы?
Уртак Ватан өчен Парижларны,
Берлиннарны алмадылармы?

Дошманга без — дәһшәт. Будык аны,
кирәк чакта, барып өненә.
Тынычта да өлеш аздан түгел
Уртак Илнең һәр җиңүендә.

Шуңа күрә горур, тынычмын мин,
Халкым да бар, ил дә, Ватан да!
Уртак могҗиза дип карыйм кояшка мин,
барыбызныкы дип карыйм ал таңга!

Миңа җитә — халкым, Ватаным бар,
Матурга да бик нечкә күңел.
Кем кылана,— димәк, җитми. Ә без?
Без болай да бәләкәй түгел!

*1969—1970*

* * *

Төзү, кору, кискен үзгәртүләрнең
мәгънәсен эзлим күңелдә.
Борынгы ямь белән килер ямьнең
чагылышы бармы бүгендә?

Һәм Табигать җавап бирә сыман:
уең синең, сагышың, җирсүең
мәгънәле — килер буыннарга
саклый алсаң гына Җир-суың.

*1971, 12 гыйнвар*
*Әлмәт*

* * *

Язгы дәрт белән өздерә
Ай яктысында тургай, —
кайтып җитү шатлыгыннан
айнып җитәлми бугай...

Көтмәгән төнге шатлыкның
ләззәте чиксез икән, —
хәтта чык бөртекләренең
җемелдәүләре бүтән!

Һай, яктылык! Тургай җыры
зәңгәр күк катларында!
Канат икәү генәме соң
үз туган якларында!

Туган җирнең һәрбер төше —
сабый чактагы юрган.
Шушы оялар канат биргән,
шушы күкләр очырган.

Бу офыклар, тугай-сыртлар
шулкадәр сагындырган!
Беренче канат кагынган
таллар да исән торган...

Тыңлап туймыйм. Менә дим ул —
табигать могҗизасы!
Нәни җанның туган җиргә
изге гимны, догасы!

Баш очымда — зәңгәр Күк, Ай,
йолдызга якын тургай.

*1971, 16 гыйнвар*
*Әлмәт*

* * *

Яңабаштан — булмый.
Мөмкин түгел. Соң...

Үткәнгә, юк, тимим —
онытмыйм. Торсын.
Анда — ак Балачак, —
иң газиз хатирә.
Әле дә ул көннәр
төшләремә керә!
Чирәмнәрдә аунау...
Ул беренче карлар!
Сиздермичә генә
«яныл сөйгән» ярлар...

Яңабаштан — булмый.
Гомер шул, һай, кыска!
Ә кешеләр аерылган
дошманга һәм дуска.
Өлгерелгән. Ә бит
күп күрмәдем әле.
Ил басмаларыннан
күп йөрмәдем әле!
Күпне татырга да
өлгермәдем әле!

Хаталар да киткән...
Ул чак тоелмаган.
Ә Вакыт — чос, өлгер —
шундук уеп алган,
чәчәкнең касәсен
уйган бөҗәк кебек.
Хәзерге акылдан:
үткән — мәзәк кебек.

Яңабаштан — булмый.
Яшәү — кабатланмас.
Бу Кояш астында
гомер-шәм гел янмас...
Син торган аулакта
бүтәннәр очраша.
Үткәннәргә кайтыла
тик яңалар аша.

Түшәмгә карап ят,
кулларың мендәрдә.
Көмеш Ай нурлары
бүтән керфекләрдә...
Чиккә җитү кыен!
Чүгә башлау кыен!
Көрәеп һәм көлеп
үлә башлау кыен!

Яңабаштан — булмый.
Мөмкин түгел. Соң...
Дәвамын дауларга —
алга фәкать, алга!..
Бүтәнчә
нишлик соң?..

*1971, 7 февраль*
*Әлмәт*

* * *

Һәр тамыр, һәр бөре — һәрбере
бер шауда, бер сүздә: Яз! Яз! Яз!
Чү! Өстә — каенның тузыннан
ишетелә кызганыч бер аваз?!

Шыгырдый, сыкрый яшь юкә,
каенның иңенә ауган да...
Шулайрак егыла кеше дә
җиңәм дип, җитәм дип барганда.

Тантана, язгы шау урманда!
Бар да бар, бар да бар дөньяда!..

*1971, 10 февраль*
*Әлмәт*

* * *

Кыз сынын ясады бер оста.
Ә кыз эчтән көлде, масайды.
«Җан өрсәң дә, оста, син ташка,
таш таш инде, тере мин — башка!»

...Акты гомер. Оста күптән юк...
Ә таш сын шул — көләч, яшь һаман!
Бөкре карчык килгән янына:
яшьлегенә — сынга яшь тама...

*1971, 17 февраль*
*Әлмәт*

* * *

Коточкыч бу! Күзләр гаҗәпләнми.
Табаннар тартыла иске эзгә.
Тук һәм мәнсез күзәнәкләр арта.
Ят төсмерләр — элек ал йөздә.
Аһ! — дим, айнып, үз-үземә дәшәм:
«Балачакка кире йөгерергә!»
«Ха! Ха! — башымны иеп Вакыт көлә:
Алга! Җәтрәк! Финиш! Өлгерергә!»
Менә ничек! Вакыт инде дошман!
Ничек тоймаганмын шул мизгелне!
Таң дип белеп әллә шәфәкъкамы
куам атым, тартып тезгенне?..

*1971, 20 февраль*
*Әлмәт*

## УРСАЛ ТАВЫНДА

Үрсәләнеп үрдә, һай, яна ут!
Шәфәкъка да карый, таңга да.
Бар януның мәгънә төсмерләре,
аңлый алсаң, барсы бар анда.

Бөтен кешегә дә барыбер түгел
килер буыннарның язмышы.
Җаны януларын шушы утка
тиңләп йөрүчеләр азмы соң!

*1971, 21 февраль*
*Әлмәт*

* * *

Озак көттем таңымның атуын,
дөньяның нурда балкуын.
Хыялларым белән көчле идем.
Мин дә бер балкыр төсле идем!

...Кояш инде чыгышноктадан
баш очыма килеп туктаган.
Яна Вакыт төшлек турымда!
Уйлап бактым үзем турында.
Байтак кына гомер узылган,
юлым-эзем шактый сузылган...
Ил йөзендә—эшең. Күр, кара!
Күренмиме? Нишлим? Ни чара...
Йә йөзеңне капла хурлыктан!
Янә башлап булмый бу йортта.

Яна Вакыт төшлек турымда!
Мин өметсез ерак — җиткесез —
хыялдагы тиеш урынга.

*1971, февраль*
*Әлмәт*

* * *

Дөнья — әле гел кояшлы.
Язмыш — шәфкать туташы.
Иң татлы төшемдәгеннән
өндәге чыным яхшы.
Мин — бәхеттән яктыручы
йолдыз астында туган.
Кайгым да минем ак төстә
өрекмим куркытудан.
Тик бер курку: бәхетемне
Ил белән югалтудан.

*1971, 7 март*
*Әлмәт*

## БОЛГАРДА ТӨН

Хәрабәләр түбәнәя.
Биегәя Болгар күге.
Зиярәт кылып йөргәннәр,
ни дисәң дә, барыбер үги.

Монда вәхшәт эзе тирән,
мыскыллаулар — сүздән түбән.
Суда ухылдап чайкала
ярга бәйләгән көймәм...

*1977, 9—10 март*
*Әлмәт*

* * *

Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда...
Шундый тансык бөек тилерүләр
кануннардан каткан дөньяда!

Бәрәкәтсез гомер, аһ, сүтелә!
Вакыт белән дуэль. Ни чара?
Бу таңнарны күбрәк күргән саен
күңелне ник моң һәм шом сара?

Янарга да, батарга да риза
эштә, өйдә, идеалларда...
Барыбер килә,
күзләр аша килә олыгаю,
күзләр аша, — авыр аларга...

...Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда.
Онытылып сөйдек, сөелдек бер!
Йә, тагын соң ни бар дөньяда?..

*1971, 20 март*
*Әлмәт*

* * *

*Б. Йосыповка*

Бодай кыры уртасында
Бари ага яланбаш...
Җиргә иелә белгән баш.
Илгә иелә белгән баш.

Зәйдә ташбаш куган баш.
Иртә билен буган баш.
Дошманга ут койган баш.
Утта күзен җуйган баш, —
тик үлмәскә туган баш!
Җиңелмәскә туган баш!

Мәрхәмәтле бул, Кояш!
Мәрхәмәтле бул, Кояш!
Бари ага кырда йөри,
башын чөйгән, яланбаш.

*1971, 22 март*
*Әлмәт*

* * *

Күк тулы — сер, җир тулы — сер,
һәр үлән — сер, һәр таш — сер,
чылтырап аккан чишмәләр — сер,
йөзеңә баккан туташ — сер.
Җир-Кояш — сер, гыйшкый Яз — сер,
Дөнья — тылсым, тоташ сер...

Серле бәйрәм — бу тормыш, дип,
үз-үземә эндәшәм.
Үзем бездән соң калачак
һәрнәрсәдән көнләшәм.
Яшерен сөйгәч, бигрәк сергә
әверелде бу яшәү!
...Мин яшермим, син дә көлмә,
сердән узды күз яше.

*1971, 23 март*
*Казан*

* * *

Гел өр-яңа бу дөньяда
гомер шәме бер кат яна.
Кабат янмавын искәртеп
тик язлар кабатлана...
Күзләр яна, күңел яна,
йөрәк яна, җан яна!
Тик язлар кабатлана!
Тик язлар кабатлана...

Зәңгәр күктә, үзәкне өзеп,
торналар канат кага.

*1971, 1—2 апрель*
*Әлмәт*

* * *

Яздан аерып булмый Тукайны!
Язда килгән, язда ул янган.
Язы, киләчәге барлар ничек китсен,
ничек югалалсын дөньядан.

Язны җуймый кара елларда да,
халыкның ул гүзәл гамьнәрен,
хыялларын чорлар аша безгә —
бүгенгегә китереп бәйләде.

Тел яшергән Тарих кына белә
бар кылганын аның, күргәнен.
Ә шулай да булалган бит Илгә
игелеклелек кылу үрнәге!

Бу тарихта мәшһүрләрне куйсаң
ул яшәгән хәлгә, урынга,
байтагының шаулы даны түгел,
чыкмас иде, бәлки, тыны да!

Яшәрен һәм үлемсезлеген
дәлилләүгә мохтаҗмы халык?
Шикләнүче булса, кара, тикшер,
бер бәгърен — Тукаен алып!

Апрель.
Кемнәр көтми ышанулар, гөлләр,
яшәрүләр биргән бу айны?
Яздан, гаделлектән, киләчәктән
мөмкин түгел аеру Тукайны!

*1971, 3—4 апрель*
*Әлмәт*

## БЕР МӘҖЛЕСТӘ

*А-га*

«Минме соң бу — зиндан кичкән?
Минме тау-таш аударган?
Бар да сау-шат... Көлә кызлар,
җелексез яшь малайлар, —
ә синнән...
яшь чыксын, имеш...

Ярый шампан хуҗа. Шау-гөр!
Һәркемнең ярсу йөрәк!
Кем күз яше тикшерә монда?
Кем кемгә монда кирәк?»

Җинаятьтә тотылган күк,
качып, борылдың читкә.
«Бу йодрык яшь сөртсенме?
Бетәр, диден, ничек тә».

Әйе, бетте. Мәҗлес гөрли.
Бар да гөл дә, бар да ай!
Син искечә. Йөзең кырыс —
каторжан Жан Вальжандай*.

Юк, мин күрдем синең яшьне.
Җаның тойдым, аңладым.
Җан яшерер битлек юк шул,
яшереп бетә алмадың.
Нишлим? Күрдем синең яшьне.
Сизмәдең, кирәкми дә...
Бәлки, ачарга булгандыр
сине тойган йөрәкне дә.

Син шул яшерен еладың.
Мин дә яшерен аңладым.
Булган сагышка ялганып,
туды, ахры, яңа моң.

*1971, 12 апрель*
*Әлмәт*

---

* Жан Вальжан — В.Гюгоның «Хокуксызлар» романы каһарманы.

* * *

Кояш булган күзләреңнән
нур алган бу дөнья —
керфекләр күләгәсенә
яңа сызыклар уя…

Нур юлы булган сызыклар
үзләре дә нурга тулсын.
Үткән язларыңны белмим,
килерләре матур булсын!

*1971, 18 апрель*
*Казан*

* * *

Шактый ук искергән дөнья —
шундый үзгә!
Күк капусының ачкычы
бүген бездә!

Җирдә күпме —
күрелмәгән
яңа төс, ямь!
Тәндә күпме —
татылмаган
ләззәт, көч, тәм!

Яшәүне данлау — җан тулы,
күңел тулы!
Изге хисләргә һәйкәл бит —
бу онытылу!

Дөньяның газиз һәр бөртек,
һәр тамчысы!
Без бары мәңгелекнең
мизгел
дәвамчысы!

Күктән йолдызлар сөенеп
безгә дәшә!
Аһ! Мең-мең гомер дә җитмәс,
бу — сөю, яшәү!

Гашыйк җанда хис тә, уй да, —
бар да өр-яңа!
Бер сөяр өчен генә дә
Кеше булып туу ярый
бу дөньяга!

*1971, 24 апрель*
*Әлмәт*

* * *

Күз алдында күпме картайдылар!
Бер без бирешмәдек шикелле,
Һаман унсигездә! Хисләр — ташкын,
гашыйк күзгә дөнья сөйкемле!
Ләйләсенең Мәҗнүнедәй әзер
тилерергә теләсә ни көнне!

Күпме картайдылар! Тик мин генә
гел яшьлектә калдым шикелле.
...Уем бүленә: ишек ачыла —
улым кайткан. Алган «икеле»!

Картаймаган идек шикелле...

*1971, 25 апрель*
*Әлмәт*

* * *

Сагыш газапка әйләнгәч,
күз яше — кара канга,
син әллә каргый башладың
мин сине яратканга?

Акыллы бул... Кисмә өметне!
Бәгырьдән ал пычак очын!
Мин әзер мең кат янарга
бер бәхетле чак өчен.

*1971, 26 апрель*
*Әлмәт*

* * *

Су читендә, таң тугач,
талга кунган сандугач.
Суга төшкән ак болыт —
күренә мендәр булып.
Тибрәнер шул сандугач,
талы бик зифа булгач,
җанына шифа булгач —
талга кунып канат кагу
бәхетле бер ял булгач!
Әй, өздерә сандугач,
әй, тибрәнә сандугач!

Шул сандугач искә төште
куенында төн кунгач...

*1971, 26 апрель*
*Әлмәт*

* * *

Син — бәйлелек, мескенлекнең,
түбәнлекнең дошманы.
Нинди вак җан яулый алсын
синекедәй хөр җанны!
Көчле рухлы белә булыр —
чын ireклек ни торыр!
Баш имичә, сокланучы
бер кешең бар, бер горур...
Тик ул усал. Усалланган
ятлар көнчелегеннән.
Җиңелсә ул җиңелер тик
синең кешелегеңнән.

*1971, 26—27 апрель*
*Әлмәт*

* * *

Аның җаны яралы...

Бәргәләнәме, өзгәләнәме —
син тимә,
ялгыш
кызгана күрмә, яме!
Кем белә: ул батырмы,
әллә бичарамы?..

Мәхәббәттән яраны
бары Вакыт дәвалый.

*1971, 27 апрель*
*Әлмәт*

* * *

Сары ут капкан бу кырда,
көнбагыш арасында —
мин ничектер, ә менә син —
бер зәңгәр яра сыман...
Зәңгәр яулыгың читеннән
ялварды зәңгәр күзләр!

Хәтер әле кайта-кайта
бу мизгелне мең эзләр...

Үбимче сөенечтән
мөлдерәп чыккан күз яшең!
Күктә, җирдә мең-мең Кояш
ут янсын бер көнләшеп!

Сары ут капкан бу кырда,
көнбагыш арасында,
безгә карап, бәхетсез дип,
Йә, әйтеп карасыннар!

*1971, 28 апрель*
*Әлмәт*

* * *

Мин синең җаеңа килдем.
Языңа өлгермәдем.
Син булып Син ялкынлангач,
мин нишлим йә! — дөрләдем!

Моңарчы кем дөрләмәгән!
Утыңда кем янмаган!
Алар арасында бер мин
илаһи илһамланган!

Котырынып эшлим — язам!
Таша хисем, көчем дә!
Дөрлим, янам — минсез үткән
синең язлар өчен дә...

*1977, 29 апрель*
*Әлмәт*

* * *

Яхшылыкның, диләр, әҗере күп.
Ә шулай да —
кайгылыга кушылып елый алмыйм.
«Бу да җәлли», — диеп рәнҗер күк.

Юк, үземне куймыйм яхшыга...
Ә шулай да...

бәхетлегә тыныч карый алмыйм —
сөенечтән, ахры, яшь чыга.

*1971, 3 май*
*Әлмәт*

* * *

Миннән дә алда тәрәзәңнән
Ай сиңа кергән икән!
Бүген ялгыз калганыңны
ул каян белгән икән?

Моңарчы ачык пәрдәңне
мин килгәч корма инде!
Буй-сыныңда сынган нурдан
оялып торма инде...

Һәр күзәнәк дәрткә тулган.
Миң очыңа нур кунган.
Матурлыктан кем туйган да
сөелүдән кем туйган!

Бернигә баш имәс җан да
мәхәббәткә буйсына.
Пәрдәңне теләсә нишләт,
нур сынса да, мин сынмам!

*1971, 3 май*
*Әлмәт*

* * *

Син калган аптырашта.
Мин калган аптырашта.
Уналтыдагы җилкенү
утыздан ашкан башта!

Данларгамы соң бу язны?
Каргаргамы бу таңны?
Яшьлек соңын, картлык башын
бергә китереп бутады...

Шундый халәт — әле акыл
хисне җиңалмаган чак.
Күтелми иңгән бәхеттән
аңга килалмаган чак.

*1971, 4 май*
*Әлмәт*

* * *

Бу — борынгы бабайларның
туган-үскән илләре.
Сылу Болгар кызларының
су коенган җирләре...

Монда кемнәр яшәмәгән!
Монда кемнәр тормаган!
Кемнәр дөнья кумаган да,
кемнәр шәһәр кормаган!
Заманында бу төбәктә
шанлы тормыш тынмаган.
Сарай булып таулар күчкән,
тимер, чуен чыңлаган.
Шушы Кама ярларында
кемнәр иген икмәгән дә,
кемнәр итек текмәгән!
Кемнәр яшәп китмәгән дә,
кемнәр дөнья көтмәгән!
Нәсле өчен, иле өчен
кемнәр шәһит китмәгән!
Кемнәр басып кермәгән дә,
кем идарә итмәгән!
Кемгә байлык җитмәгән дә,
кемдә күз яшь кипмәгән.

...Әй, күрмик әле дөньяның гел
хәрабәсен, аһ-зарын!
Монда мәшһүр мәркәз булган,
булган Агабазары!
Гел яшь кенә күрмәгәндер
бу мәгърур Кама яры.
Булгандыр Зөһрәләре,
булгандыр Таһирлары.

Гел-гел мескенләнмик әле!
Үткәннәр безнең яклы.
Канибызда — хезмәт сөю,
жыр-дастаннар ничаклы!

Кояштай гел шат булыйк,
ап-ачык — тулган айдай!
Таш кебек каты булыйк,
горур — төз манарадай!

*1971, 30 май*
*Әлмәт — Казан*

* * *

Бар нәрсәдә синең төсмер:
син — үләндә, яңгырда.
Сине күрәм дулкыннарда,
тургайлар тулы кырда.
Син — кәгазьдә, төнбоекта,
керфектән тамган тирдә...
Болытта да чагылышың! —
Йа Хода, бөтен җирдә —
син,
    син,
        син...

Күңелемдә шигырь таҗы.
Ачып баксам — анда да син!
Кайда да син, кайда да син!
...Тик
үзең генә юк янда.

*1977, 12 июнь*
*Әлмәт*

* * *

Мәхәббәт күзсез була, ди,
ярату сүзсез була.
...Безнең мең күзле булды,
гайбәтле, сүзле булды!

Ә барыбер хисләр, уйлар
чиста, пакь, олы булды!
Сөенүләр, сөелүләр,
шатлыклар тулы булды!
Бездән хәтта өлеш чыкты
хөсетле күзләргә дә —
форсат булды рәхәтләнеп
сөйләргә, күзләргә дә...

Мәхәббәт күзле буламы,
буламы күзсез, сүзсез —
монсы бер хәл, ә берзаман
бу таңнар булыр безсез...
Җан өшетерлек бу уй-хис
нинди ят, нинди төссез!

Тизрәк килче син яныма!..

*1971, 12 июнь*
*Әлмәт*

* * *

Беренче дә, иң соңгы да түгел,
күбәүләрнең монда берсе мин.
Бердәнберең генә булмавыма
ни гаебем? Ни дип көрсеним?..

Әйтмим — үзгәрешләр ясадым дип,
тормышыңа, димим, ямь керттем.
...Тәрәзәңә ябышып канат салган
бер күбәләк алып терелттем.
Гөлләреңне барлап иркәләдем.
Бераз яшәрттем күк, су бөркеп.
Дивардагы яшьлек рәсемеңне
турылап куйдым, тузанын сөртеп.

Бүтән, ахры, берни кылмадым мин,
яхшысыннан, ни яманыннан.
Ә барыбер чиксез бәхетле идем!
Өстен идем — нәфес, мал, даннан.
Син үзең дә якты сагышлы идең.
Разый идең сыман өлешеңнән,
һәм барсы шул. Тагын ни мөмкин соң
соңлап килгәннәрнең берсеннән...

*1971, 15 июнь*
*Төмән*

* * *

Өзгәләнмим, һич үкенмим,
«гафу итче!» дип үтенмим.
Сөю хакында булса да,
бу җырым сиңа түгел!..

Телә — аңла, телә — карга.
Яманлык кыл, хәтта алда...
Сөю хакында булса да,
бу җырым сиңа түгел!..

*1971, 16 июнь*
*Төмән*

* * *

Кояш тотылганмы? Көпә-көндез
җиргә иңгән сөрем, кара шом...
Җитәкләнешеп, безнең балалар
йөри анда илереп, адашып.
Сукырлардай ары сугылалар, бире...
Ә күзләре — зәңгәр күк кебек!
Безгә борылып та карамыйлар,
әллә инде өзгәннәр өмет?
Безгә — ак гөл, бәлки; алар өчен —
баш калкыткан кара еландыр?
Сине кочып, бәлки, сабыйларның
шатлыкларын каерам, буамдыр?
Безгә — чиста; алар өчен — пычрак;
безгә якты булган — караңгы.
Бәхеттән кан уйный, шул ук вакыт,
тере каным — балам каргаулы...

Үзебезме әллә адаштырдык?
Йөзләрендә нәфрәт, кара моң.
Мин беренче тапкыр — кылганыма
улым күзе аша карадым.

Бәгърем көйде, йөзем агарды...

...Кояш тотылганмы? Көпә-көндез
җиргә иңгән сөрем, кара шом.
Җитәкләнешеп, безнең балалар
йөри кебек каңгырып, адашып.

*1971, 17 июнь*
*Төмән*

* * *

Бар күк булган сабырлыгымны
бозмам дигән уем-тәүбәмне —
син килдең дә ваттың, таркаттың, —
бөтенлегем меңгә әйләнде...

Күпләр өчен әле күз үтмәс мин,
күпләргә — таш, калкан әле мин!
Синең алда исә, үзем теләп,
үз-үземне ваткан бәллүр мин.

Ятлар жәлләмәсен. Үзе бәхет
сөю өчен ватылу, чәчрәве!
...Ә син исә, мине янә җыйсаң,
тезең чүгеп җыймассың, яме!

*1971, 19 июнь*
*Төмән*

* * *

Тилерткән, бәхетле иткән,
сөюендә яндырган,
һәр күзәнәкнең куәтен
иҗади кабындырган,
ил алдында кызармаслык
эшләргә рухландырган —
һәр чибәргә сәҗдә кылам!
Мәдхия язам, данлыйм!
Хатын-кызның тик шундыен
чын хатын-кыз дип саныйм.

*1971, 23 июнь*
*Әлмәт*

## ЕРАКТА-ЧИТТӘ ЧАКТА

Барсы үзеңдә — эчтә. Яна...
Ни мәгънә эндәшеп тә!
Ни дошман юк, ни дус... Булмый
җан атып та, көнләшеп тә.

Бөркетме син, бер чебешме?
Беркем дә барбер тоймас.
Бар да чит шул. Танышлардан —
Зөһрә йолдыз, Ай да Кояш.
Ичмасам, кайчак аларга
җанны бушатам бераз...

*1971, 26 июнь*
*Займище*

* * *

*Без, бәләкәй чакларда*
*сикереп мендек атларга!*

Халык җыры

Без, бәләкәй чакларда,
менмәсәк тә атларга,
очрашуга чакыра идек
аулаграк чатларга...
Әй, куандык «сөю» сүзе
булган җылы хатларга!

Без бәхетле чакларда
булдык җылы кочакларда.
Көнләшүдән җан дуслар да
әйләнделәр ятларга.

Бәлки, олайган чакларда
килмәс җылы хатлар да...
Ә шулай да ант иттек без
сынатмаска ятларга.
Яшеннәргә тиң яшьлекнең
шанлы исемен акларга —
җан хөрлеген сакларга.

*1977, 29 июнь*
*Мәскәү*

* * *

Бу — сәясәт түгел.
Сөю — бер йөзле.
Бер утта янганның
барын тигезли.

Бу — хис иле. Монда
кануннар үзгә.
Монда көчсез — Акыл
көйләгән бизмән.

Монда кызганмыйлар
һәм баш имиләр.
Рөхсәт сорамыйлар,
рәхмәт димиләр.

Гамәлгә кермәгән
дәрәҗә, даннар.
Мәхәббәттә һәркем
үзенчә янган.

Бәхетлеләр алар
сүзсез дә аңлаша.
Яшәүне данлыйлар
җан һәм тән аша.

Бу — үзгә ил. Монда
ләззәт, хис — өстә.
Юк монда яз-көзләр,
юк иртә-кич тә...

Сөю — хезмәт түгел,
норма, тариф юк.
Уйлап баксаң — ансыз
җирдә Тарих юк.

Бүлеш, әйтче, дисең, —
белмәкче фикерем.
Мин шул аны үзем дә
аз беләм, энем!

Тик сиңа ярамас
минем белгәнем,
һәркем үзе ача
мәхәббәт фәнен.

*1971, июнь*
*Әлмәт*

# ЭЧТӘЛЕК

Мөхәррирдән ........ 7

Иясен тапкан бәхет. *Ф.Яруллин* ........ 8

**Кыска шигырьләр**

Берьюллыклар ........ 29
Икеюллыклар ........ 37
Өчьюллыклар ........ 54
Дүртьюллыклар ........ 72

**Үсмерчак дәфтәреннән**

Вакыт ........ 194
Яз ........ 194
Балачак тупыллары ........ 195
Авылда көз ........ 196
Капка ........ 197
Кайту ........ 198
Иртә ........ 198
Авылда кышкы төн ........ 199
Яланда каен ........ 200
Бураннан соң кышкы урманда ........ 201
Каникулга кайтыр алдыннан ........ 202
Миңа унсигез яшь ........ 203
Онытылмас бер кыш бураны ........ 204
Төш ........ 205

**Яшьлек дәфтәреннән**

Эрмитажда йөрим... ........ 207
Караңгыда берәү кар көри ........ 208
Базарда ........ 209
«Киләчәгем хыялымда...» ........ 210
Ике күпер ........ 211
Кошларга ........ 212
Диңгез ташлары түшәлгән юлга... ........ 213
Өндә ........ 214
«Галәм кораблары ясаган затларга...» ........ 214
Кадак ........ 215
Пружина ........ 216
«Үзенә үзе кул салган шул...» ........ 217
Авыл карты белән сөйләшү ........ 218
«Кар бөртеге кунды тәрәзәмә...» ........ 219
Март ахыры ........ 220
Юлсубино ........ 220
Төштә ........ 221
«Өченче көн дә инандым...» ........ 222
Мирас ........ 222
Ачык тәрәзәле яз көне ........ 223

«Аста — дулкын, өстә — Кояш!..» .......... 223
Паром чыккан чакта килгән .......... 224
«Мин нур атам...» .......... 225
Яр карлыгачы .......... 226
Җил — вакыт ул... .......... 227
Кар ява .......... 228
«Беренче кат кайчан көлдем мин?..» .......... 229
Балыкчы карт .......... 230
Метаморфоза .......... 231
«Үз көенә аксын...» .......... 232
«Давылның күзендә очармын!» .......... 233
Яңгыр .......... 234
Күпердә .......... 236
«Мич тулып шигырьләр яна...» .......... 238
«Соңгы аваз, карлыгач кебек...» .......... 240
«Ай — вакланган дулкыннарда...» .......... 241
Минем әти .......... 242
«Фикер килде миңа...» .......... 243
Яшь хатын .......... 245
Сабый санарга өйрәнә .......... 246
Кояшка атылган ядрәгә .......... 248
«Кулларымны өскә куеп...» .......... 249
«Аһ, кулларың, диден, нинди кайнар!» .......... 250
Шагыйрь өчен тиран нәрсә ул! .......... 252
«Кер чайкыйлар кызлар...» .......... 254
Самолетта. Биеклек — 8000 м .......... 255
Йомарлам кар .......... 256
«Чын дуслар очратып танышсам...» .......... 258
Хәрефләр .......... 259
«Кояш!..» .......... 260
Эмигрант .......... 262
Бухенвальд күге .......... 263
«Әй, җәйге төн!..» .......... 264
Яшьлек дәфтәреннән моңсу юллар .......... 265
Пристань .......... 266
«Бүтән килмибез дип...» .......... 267
Парикмахерскаяда .......... 268
Тол хатыннар чәер агыза .......... 270
«Үләнгә...» .......... 271
Иңемә кулларың орынгач .......... 272
Кит! .......... 273
«Ашыгыч ярдәм» машинасы бездән киткәч...» .......... 274
Күмәч пешерүчеләр җыры .......... 276
«Кил, кайгы, кил!..» .......... 278
«...Уйда җиткесез уй-хыял!..» .......... 279
Минем телем .......... 280
«Сине күптән күргәнем юк...» .......... 281
Хыялга .......... 282
Күзләр .......... 283
Аҗаган .......... 284
Җилфердәүче керләр җыры .......... 285
Ашкыну .......... 286
Рәсем .......... 287
«Вулканнар бар диңгез төбендә...» .......... 288

«Ал поездлар юллыйм мин сиңа...» ........ 289
«Күз кичәге, караш бүтән...» ........ 290
«Мин сине ничек яраттым!..» ........ 291
«Шатлыгы киләме бүген?..» ........ 292
«Изасы бар, хафасы бар...» ........ 293
«Кыз бала йөгереп үткән...» ........ 294
Алма ........ 295
«Бер күтәргәч өй булыр...» ........ 296
«Язын өмет булган икмәк...» ........ 297
«Ни бар канда, ни бар җанда...» ........ 297
«Үпкәлим...» ........ 298
«Кеше ирекле...» ........ 300
«Илгә чыксам, өн ишетәм...» ........ 301
«Ни исәп, ни гамь бар бу ярда?..» ........ 302
«Төн эченнән атлыйм сиңа, Ут...» ........ 303
«Туфрак җибәрде мине...» ........ 304
«Катмарлы икән...» ........ 305
«Чәчмим, җыймыйм...» ........ 306
«Башны салларга салып...» ........ 307
«Матурлар күп...» ........ 308
«Ярамаган сүз дисең...» ........ 309
«Җирдә төсләр, җилдә тавыш...» ........ 309

## Солдат дәфтәреннән

«Басып торам...» ........ 311
«Туган якка оча аккош...» ........ 311
Яран гөл ........ 312
«Куып тереклек итүнең...» ........ 313
«Бу дөньяны, кешеләрне...» ........ 314
«Манма сумын. Ник туктамый?..» ........ 315
«Ярлар күчәр, дулкын бәрсә...» ........ 316
Әйтте кыз казарма янында... ........ 316
«Син — гүя бер күчмә шәһәр...» ........ 317
«Телем оер...» ........ 318
«Җир җимермәк идек!..» ........ 318
«Булчы, зинһар, зәңгәре син...» ........ 319
«Алма булырга иде миңа!..» ........ 320
Нарат ........ 323
«Күкне иңдереп...» ........ 324
«Болын кебек бу маңгаем...» ........ 325
«Өшеттергеч бәсле ак кар...» ........ 326
Солдатка китү ........ 326
«Көн шыксыз дип карадым...» ........ 327
«Яз гына Рухыңнан...» ........ 328
«Офыклар — тоташканнар...» ........ 328
«Әй, гашыйк без матурлыкка!..» ........ 329
«Әй Туган җир! Туган җир!..» ........ 329
«Мәңгегә яратам, димим...» ........ 330
«Шулай туры килә...» ........ 331
«Кемгә хаҗәт шатлык-кайгың!..» ........ 332
«Очырасың, очырасың...» ........ 332
«Күпмегә тулды тәүбәләр!..» ........ 333
«Сәерсең, дисең, яши...» ........ 333
«Юк кылган батырлык...» ........ 334

«Әле алда тулы ун көн...» ........ 335
«Хәерлегә булсын...» ........ 336
«Җаныңның ваклыгын...» ........ 338
«Ятлар әйтте: олакты ла!..» ........ 339
«Азмы кирәк...» ........ 340
«Куркытмый мине...» ........ 341
«Бала чактан туры...» ........ 342
Юану ........ 344
«Күңелеңә салкын тигән...» ........ 344
«Диңгездә Ай юлы...» ........ 345
«Ут яна табаннар...» ........ 346
«Яктыга төшә күз, акка...» ........ 347
« — Кая ашкынасың, күңел?..» ........ 348
«Була минутлар...» ........ 349
«Кешеләрнең үзләредәй...» ........ 350
«Килер бер көн...» ........ 351
«Исәннәрнең күзләреннән югалуга...» ........ 352
«Теләге бәхеттә иде...» ........ 353
«Юмалады чегән карчык...» ........ 354
Әллә инде... ........ 355
Киресенчә булса әгәр... ........ 356
«Бу юлларны сагынырбыз әле!..» ........ 357
«Үлемнәре белән үлемсезлек...» ........ 358
«Гөлем идең, яктым!..» ........ 359
«Бераз үзгә, бераз бүтән...» ........ 360

**Әмәт дәфтәреннән**

«Дәшмәү — алтын...» ........ 362
«Бастырма аны...» ........ 363
«Менә без дә үсеп җиттек, әни!..» ........ 364
Карт шагыйрь ........ 365
Ул көннәрне инде даулап булмый... ........ 366
«Мин көрәшмим синең белән...» ........ 367
«Хакыйкать ул — авыр...» ........ 368
«Сөю көчле иманнан!..» ........ 369
«Кешелек язына...» ........ 370
Дәрдемәндкә тәкълидән ........ 371
«Минеке түгел сылулыгың...» ........ 372
«Яздым мәхәббәт турында...» ........ 373
Тукайларны уйлап ........ 374
«Өндәде...» ........ 376
«Аһ, аеклык!..» ........ 377
«Нәкъ минем күк кеше юктыр...» ........ 378
«Килерме...» ........ 379
« — Нигә дип килдең син, Кеше...» ........ 380
«Төн бастырып куйдымы сине...» ........ 381
«Мин, ахры, изгеләштерәм...» ........ 382
«Без, ахры, гыйбадәт кылдык...» ........ 382
«Нигә чыктың...» ........ 384
«Чакырдың да...» ........ 385
«Күргән һәр сылуга мин гашыйк...» ........ 386
Алмазга ........ 387
«Миңа бары бер җыр кирәк...» ........ 389
Нинди бетмәс ышаныч бу? ........ 390

**Әлмәт дәфтәреннән**


«Яз төсе бу көздә!..» ............ 392
«Ярсыгансың, янгансың...» ............ 392
«Юатудан узган күңел...» ............ 393
«Гөлсарларда хәмер яна...» ............ 393
«Үсә алган һәрбер нәрсә...» ............ 394
«Булдыралмыйм!..» ............ 394
«Төнге шәһәр буйлап йөрим...» ............ 395
«Эшең юк, язган чакта мин...» ............ 395
«Җанга якын җаннар китә тора...» ............ 396
«Дөньяда, һай, күп кирәк!..» ............ 397
«Монда тыныч! Монда ямь-тәм!..» ............ 397
«Сафлыкка өйрәнәм Сездән...» ............ 398
«Зинһар, кит!» — дисең...» ............ 399
«Аһ, тау юклыклар!..» ............ 400
«Имеш, күктә фәрештә!..» ............ 401
«Йоп-йомшак иреннәрне...» ............ 402
«Мөмкинлегең — чигең узып...» ............ 402
Очрашкач ............ 403
«Мин ашыккан, син соңарган...» ............ 404
«Кадер, бәя, чын хак...» ............ 404
«Төбәгән максат юлыңда...» ............ 405
«Әти эшләгән җирләр бу...» ............ 407
«Йөгереп-уйнап...» ............ 408
Хушлашыр алдыннан ............ 409
Этюд идиллия ............ 410
«Һәр табуда күпме югалтулар!..» ............ 412
«Суыр көн дә коллыгыңны!..» ............ 413
«Кызганам мин сине...» ............ 414
«Хак сүз, Тарих, гыйбрәтләр...» ............ 415
«Күктә — яшен!..» ............ 416
«Бәя җитмәс кешеләр сез...» ............ 417
«Хиссият илендә икәү...» ............ 418
«Яңа казылган кабергә...» ............ 419
«Боек дип уйлама син, төнбоек!..» ............ 419
«Тугры дусың улмы, бумы?..» ............ 420
«Курыкма, биек оч, Кошым!..» ............ 420
Соңарган шаһит ............ 421
«Алдындагын кем дә күрер...» ............ 422
«Бәхетлеләр — ачык, киң күңелле...» ............ 422
«Артык бернәрсә дә өмет итмим...» ............ 423
Бәлки, син... ............ 424
«Чыныгаммы, күнегәмме?..» ............ 425
«Сабыйлык та картлык синдә...» ............ 426
«Зәй буенда сугыш уены...» ............ 427
«Җирдә — аклык, җанда — шатлык!..» ............ 428
«Адаштык. Төн килә өскә...» ............ 429
Мөтәгалимгә ............ 430
Бу сөю ............ 431
«Хыянәткә, ялагайлыкка...» ............ 432
«Язсам гына яшәвемне раслыйм...» ............ 432
«Азмы синдә байлык, кодрәт...» ............ 433
«Сөйли. Җитди. Хак эш өчен...» ............ 434
«Җилләр уйный — триумф!..» ............ 436

«Гөмбәзләре — кояшмыни!..» .......... 437
«Дан аты — холыксыз!..» .......... 438
«Хәзинәнең сакчысы да...» .......... 439
Кышкы бер кич .......... 441
«Ни генә дә җиккесез!..» .......... 442
«Төбенә төшеп уйлап баксаң...» .......... 443
Идел ага .......... 444
Бүген — болай, ә иртәгә... .......... 445
Вакыт! .......... 446
Картлык .......... 447
Комлыкта .......... 448
«Яу-дауларны күргәннәр күп...» .......... 448
Элегия .......... 449
Кичерер димә! .......... 450
«Космополит түгел...» .......... 451
«Төзү, кору, кискен үзгәртүләрнең...» .......... 452
«Язгы дәрт белән өздерә...» .......... 453
«Яңабаштан — булмый...» .......... 454
«Һәр тамыр, һәр бөре — һәрбере...» .......... 456
«Кыз сынын ясады бер оста...» .......... 456
«Коточкыч бу! Күзләр гаҗәпләнми...» .......... 457
Урсал тавында .......... 457
«Озак көттем таңымның атуын...» .......... 458
«Дөнья — әле гел кояшлы...» .......... 459
Болгарда төн .......... 459
«Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!..» .......... 460
«Бодай кыры уртасында...» .......... 461
«Күк тулы — сер, җир тулы — сер...» .......... 462
«Гел өр-яңа бу дөньяда...» .......... 462
«Яздан аерып булмый Тукайны!..» .......... 463
Бер мәҗлестә .......... 464
«Кояш булган күзләреңнән...» .......... 465
«Шактый ук искергән дөнья...» .......... 466
«Күз алдында күпме картайдылар!..» .......... 467
«Сагыш газапка әйләнгәч...» .......... 468
«Су читендә, таң тугач...» .......... 469
«Син — бәйлелек, мескенлекнең...» .......... 470
«Аның җаны яралы...» .......... 471
«Сары ут капкан бу кырда...» .......... 472
«Мин синең җәеңә килдем...» .......... 473
«Яхшылыкның, диләр, әҗере күп...» .......... 474
«Миннән дә алда тәрәзәңнән...» .......... 475
«Син калган аптырашта...» .......... 476
«Бу — борынгы бабайларның...» .......... 477
«Бар нәрсәдә синең төсмер...» .......... 479
«Мәхәббәт күзсез була, ди...» .......... 480
«Беренче дә, иң соңгы да түгел...» .......... 481
«Өзгәләнмим, һич үкенмим...» .......... 482
«Кояш тотылганмы? Көпә-көндез...» .......... 483
«Бар күк булган сабырлыгымны...» .......... 484
«Тилерткән, бәхетле иткән...» .......... 485
Еракта-читтә чакта .......... 486
«Без, бәләкәй чакларда...» .......... 487
«Бу — сәясәт түгел...» .......... 488

Литературно-художественное издание

*Файзуллин Равиль Абдрахманович*

Избранные произведения

В шести томах

Том 1

Казань. Татарское книжное издательство. 2005

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

*Фәйзуллин Равил Габдрахманович*

Сайланма әсәрләр

Алты томда

1 том

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, С.Н.Галимуллина, Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.11.2005. Форматы 84×108 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 26,04 + вкл. 0,42 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 27,20. Нәшер-хисап табагы 13,62 + вкл.0,44 + форз. 0,36. Тиражы 3000 д. Заказ А-881.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.